КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

# ӘХЛАК – ИМАН КӨЗГЕСЕ

## Мәчетләр каршындагы курсларда әхлак дәресләре эшкәртмәләре

КАЗАН
2015

УДК 37
ББК 74
Н86

**Төзүчесе**
**А.В. Мөхәммәтшина**

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты **Р.Р. Сафиуллина-Аль Анси**

**Рецензентлар:**
тарих фәннәре кандидаты **Р.К. Адыгамов;**
педагогия фәннәре кандидаты **Г.Г. Галәвиева**

Н86 **Әхлак – иман көзгесе:** мәчетләр каршындагы курсларда әхлак дәресләре эшкәртмәләре / төз. А.В. Мөхәммәтшина. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 152 б.

**ISBN 978-5-00019-549-9**

Әлеге җыентыкка «Әхлак – иман көзгесе» дип аталган республика конкурсында катнашкан мәчетләр каршындагы курсларда укытыла торган дәрес эшкәртмәләре тупланган. Җыентык дәресләрен заманча технологияләр файдаланып үткәрүче мөгаллимнәрнең алдынгы педагогик тәҗрибәсе белән танышырга мөмкинлек бирә. Китап мәчетләр каршындагы башлангыч дини белем бирү курсларында әхлак дәресләре укыту өчен методик кулланма буларак тәкъдим ителә.

**УДК 37**
**ББК 74**

**ISBN 978-5-00019-549-9**

**© Казан университеты нәшрияты, 2015**

## КЕРЕШ

Ислам динендә күркәм әхлаклы шәхес тәрбияләү – төп максатларның берсе.

Шәригать кануннары Коръәндә әхлакый кагыйдәләр, кешенең үз-үзен тотышы, эчке дөньясы, фикерләве белән тыгыз бәйләнештә бирелгән. Коръәндә тугрылык, ихласлылык, юмартлык, сүз һәм гамәл берлеге, шәфкатьлелек, ата-ананы хөрмәт итү, сабырлык һәм башка шундый матур әхлакый сыйфатлар мактала, аларның тискәреләре төрлечә хөкем ителә. Бигрәк тә ялганчылык, кеше канын түгү, фетнә тарату, эчүчелек, зина кылу, хәрам мал туплау гаепләнә. Ислам дине тынычлык, халыклар арасында дуслык, үзара ярдәмләшү өчен көрәшә, кешеләрне бозыклык эшләүдән тыя. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мин Җир йөзенә гүзәл әхлакны тәмам итеп урнаштыру өчен килдем», – ди.

Ислам тормышның барлык өлкәләрендә дә әдәпле, тыйнак булырга чакыра.

Әдәплелек социаль киеренкелекне киметү һәм җәмгыятьтәге элемтәләрне ныгыту чарасы булып тора. Әхлаклылык – милләт көченең нигезе, ә әхлаксызлык милләтнең таркалуына, түбән тәгәрәвенә сәбәпче була.

Әхлакый тәрбия дигәндә, без бай рухи сыйфатлар, этик нормалар булдыру һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен төшендерү максатыннан, шәкертләргә системалы тәэсир итүне аңлыйбыз.

Татарстанның барлык мәчетләрендә дә Ислам дине нигезләрен өйрәнүче курслар кысаларында әхлак дәресләре укытыла. Әхлак тәрбиясе процессында укытучының роле зур. Эшнең нәтиҗәсе яхшы булсын өчен ул дәреснең эчтәлеген яхшы белү белән бергә укытуның төрле фомаларын һәм методларын да файдалана белергә тиеш. Бүгенге көндә мәчетләр каршындагы курсларда укытучылар өчен методик әдәбият, дәрес эшкәрмәләре җитешми. Әлеге проблеманы хәл итүгә өлеш кертү өчен Казан (Идел буе) федераль университетының Ислам мәгарифен үстерү буенча ресурс үзәге тарафыннан «Әхлак – иман көзгесе» дип аталган мәчетләр каршындагы курсларда әхлак дәресләре эшкәртмәләре республика конкурсы оештырылды. Конкурс эшләренә өч номинациядә бәя бирелде: «Алтыдагы – алтмышка» кече яшьтәге

мәктәп балалары өчен, «Әдәпле бала» урта яшьтәге мәктәп балалары өчен һәм «Күркәм әхлак – иман көзгесе» өлкән сыйныф укучылары һәм зурлар өчен.

Тәкъдим ителә торган җыентыкка әлеге конкурста катнашкан иң яхшы дәрес эшкәртмәләре тупланган. Беренче тугыз дәрес эшкәртмәсе – өч номинациядә җиңү яулаган авторларныкы.

Җыентык дәресләрен заманча технологияләр файдаланып үткәрүче мөгаллимнәрнең алдынгы педагогик тәҗрибәсе белән танышырга мөмкинлек бирә, мәчетләр каршындагы башлангыч дини белем бирү курсларында әхлак дәресләре укыту өчен методик кулланма буларак тәкъдим ителә.

***Әхмәтҗанова Разия,***
*Балтач районы Шубан авылы*
*мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

# ШӨГЫЛЬ КОНСПЕКТЛАРЫ

(Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен)

## 1 нче шөгыль
## Тема: Җирләр, күкләр кемнеке?

*Максат:* балаларны бар тереклекне һәм галәмне, күк, җирләрне барлыкка китерүче зат Аллаһ икәнлегенә, җирдә бар әйбер дә Аллаһ рәхмәте белән барлыкка килүенә төшендерү. «Аллаһу әкбәр», «Сөбханаллаһ», «Әлхәмделилләһ» сүзләренең мәгънәләрен аңлату, сүзлекләрен шул сүзләр белән баету. Аллаһ тудырган тирәлеккә сак караш, Аллаһка мәхәббәт тәрбияләү.

*Җиһазлар:* дисбе, тау, елгалар, күлләр, табигатьнең төрле мизгелләрен, күренешләрен сурәтләгән рәсемнәр.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, карагыз әле, мин сезгә нинди матур рәсемнәр алып килдем. (Рәсемнәр балаларга бирелә, карау мөмкинлеге тудырыла, аннан соң тәэсирләре белән уртаклашалар).

– Балалар, мондый матур елга, күлләр, тауларны кем ясады икән?

– Үзе булган ул, аны табигать ясаган.

– Әйбер үзеннән-үзе була аламы соң ул? Сезнең өстегездәге күлмәккә дигән җеп, тукыманы өеп куеп күлмәк барлыкка киләме? Яисә, машина ясыйсы тимер-томырны өеп куеп машина булсын дисәк, машина барлыкка киләме?

– Юк. Күлмәкне тегүчеләр теккән, ә машинаны заводта абыйлар ясаганнар.

– Дөрес, балалар, һәрбер әйберне ясаучы бар. Менә безнең Шушма елгасын да, Бай тавын да, сез рәсемдә караган таулар, агач, үләннәр, кошларны һәм кешеләрне дә, бар җиһанны Аллаһ бар иткән, ясаган.

Шундый зур дөньяны, бар нәрсәне ясагач, ул бик куәтледер инде, әйеме?

– Әйе.

Балалар, шуңа күрә дә без «Аллаһу әкбәр!» дип әйтәбез.

– Сезнең бу сүзне ишеткәнегез бар идеме?

(Балаларның фикерләрен тыңлау.)

– Аллаһу әкбәр! Аллаһ бөек дигән сүз. Җирдәге, судагы, һавадагы бар әйбер, бар тереклек, үләннәр, балыклар, барысы да шушы тәсбихны әйтә икән. Ләкин аны без генә ишетмибез. Ә Аллаһ ишетә, шуңа күрә Кеше дә үзен булдыручыны мактап, Аллаһу әкбәр! – дип әйтә. Йокыдан торгач та, ашагач та, берәр эше уңай булса да. Мин тәсбих әйтә дидем, тәсбих – мактау дигән сүз. Сезнең дә Аллаһны мактыйсыгыз киләме? Ягъни тәсбих әйтәсегез киләме?

– Килә.

– Димәк, нәрсә дип мактыйбыз инде?

– «Аллаһу әкбәр!» – дип.

(Һәрбер баладан әйттереп карау һәм бергә кабатлау.)

– Сөбханаллаһ! Балалар, бик матур итеп әйттегез. Балалар, мин сезне нәрсә дип мактадым. Әйе, Сөбханаллаһ! дип. Мин сезне Аллаһка сокланып мактадым. Чөнки сезгә акыл бирүче дә, тел бирүче дә, сөйләшү мөмкинлеге бирүче дә Аллаһ. Сөбханаллаһ – Аллаһ бар кимчелекләрдән дә пакь дигән сүз.

Сез матур рәсем ясасагыз да, әниегез тәмле бәлеш пешерсә дә, этиләрегез матур капка ясаса да аңа карап сокланабыз, «ай матур булган» – дибез, шулаймы? Аллаһ безгә кул бирмәсә, яисә яңгырлар бирмичә ашлыклар бирмәсә, он булмас иде, бәлеш тә пешмәс иде, этигә дә Аллаһ саулык бирмәсә капка да ясалмас иде, шуңа да беренче без Аллаһ исемен телгә алып, Сөбханаллаһ, ничек матур булган дип әйтик.

Әйдәгез һәрберебез әйтеп чыгыйк әле. Һәм бергәләп кабатлыйк. (Бергәләп Сөбханаллаһ сүзен кабатлау.)

Ә бүлмәдә сезне сокландыра торган әйберләр бармы? Карагыз әле һәм Сөбханаллаһ тәсбихе белән җөмлә төзик.

(Балалар бүлмәдә йөреп киләләр. Җөмлә төзиләр. Сөбханаллаһ, нинди матур гөл һ. б.)

Тәрбияче: Әлхәмделилләһ, сез бик зирәк балалар. Ишеттегезме мин тагын янә Аллаһны мактау сүзе әйттем.

– Әйе.

– Әйдәгез, бергәләп кабатлап карыйк әле. Әлхәмделилләһ. (Балалардан кабатлату.)

Әлхәмделилләһ – барлык мактаулар Аллаһка булсын дигән сүз.

Җирне, күкне, безне бар иткән Аллаһны без бүген өч төрле итеп мактау өйрәндек. Кайсыларыгызның исендә калды? (Балалардан кабатлату.)

Балалар, Әлхәмделилләһ, миңа сезнең белән бик рәхәт булды. Шуңа мин сезгә дисбе бүләк итәм. Аллаһка тәсбих әйткәндә, сез шул дис-

бе белән санап барырсыз. Ул өч өлешкә бүленгән. Беренче өлешендә Сөбханаллаһ дип, икенче өлешендә Әлхәмделилләһ дип, өченче өлешендә Аллаһу әкбәр дип әйтерсез. Бүген өйгә кайтканда да, Аллаһ бар иткән дөньяны карап сокланганда һәрдаим Аллаһка тәсбих әйтергә тырышыгыз, ярыймы? Шулай итсәгез, Аллаһ сезне яратыр.

**2 нче шөгыль**
**Тема: Әйбәт сүз эшне хәерле итә.**

*Максат:* балаларны «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим», «Ләә иләһә иләАллаһ» тәсбихлары белән таныштыру, мәгънәсен аңлату. Сөйләмнәрен матур, күркәм итәргә өйрәтү. Яңа өйрәнгән һәм үткән шөгыльдә өйрәнгән тәсбихларны сөйләмнәрендә кулланырга өйрәтү. Иң гади әдәплелек кагыйдәләрен өйрәтү. Сөйләмне күркәм, мәгънәле сүзләр белән баету күнекмәләре бирү.

*Җиһазлар:* кисеп ясалган зур чәчәк. (Таҗ бөртекләре артына сораулар язылган.)

– Балалар, минем яныма килегез әле, мин сезгә бүген бер серле сүз алып килдем.

Балаларны ярымтүгәрәк ясап утырту. «Ватык телефон» уены оештыру. «Бисмилләһ» сүзен әйтү.

Безнен телефон аша нинди сүз йөрде?

– «Бисмилләһ» сүзе.

– Балалар, сез бу сүзне беләсезме? Ишеткәнегез бар идеме? (Балалар фикерен тыңлау.)

– Әйе, балалар. Бу сүзне сезнең әбиләрегез әйтә, әниләрегез әйтә. Ни өчен әйтәләр икән соң аны?

– Без яшәгән җирне, кешеләрне кем бар иткән?

– Аллаһ бар иткән.

– Бик дөрес әйттегез, балалар, бу җиһанны Аллаһ бар иткән. Һәм шуңа да нәрсә генә эшләсәң дә Аллаһ исеме белән башларга кирәк. Менә Бисмилләһ сүзе Аллаһ исеме белән дигәнне аңлата.

Кешеләр ясаган машиналар, әниләр теккән күлмәкләр – барысы да Аллаһ рәхмәте белән эшләнә дидек. Кешеләрне шундый акыллы итеп яраткан Аллаһ рәхмәтле, ягъни шәфкатьле, мөмкинлек бирүче. Шуңа да без Бисмилләһ сүзе янына шушы ике сүзне дә өстәп Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим дип әйтәбез. Эшебез, көнебез шушы сүз белән баш-

ланса гына хәерле була, ягъни нәтиҗәсе әйбәт була, безгә, кешеләргә шатлык китерә.

Әйдәгез шушы сүзне кабатлап әйтик әле. (Балалар белән аерым-аерым һәм бергәләп Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим сүзен кабатлау.)

Тәрбияче балаларга бик матур итеп ясалган чәчәк күрсәтә.

– Балалар, Сөбханаллаһ, карагыз әле, нинди матур чәчәк. Бу чәчәк таҗлары артына сораулар язылган. Сез шул сорауларга җавап бирә белерсезме икән?

Карап карыйк әле. Белсәгез, бу матур чәчәк безнең бүлмәдә калыр.

Тәрбияче сорауларны укый.

– Йокыдан торганда нинди сүз белән торабыз?

(Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Хәерле көн).

– Нинди матур күлмәк дип сокланганчы нинди сүз әйтәбез?

(Сүбхәналлаһ.)

– Ашый башлаганда нинди сүз белән башлыйбыз, башкаларга нәрсә дип әйтәбез?

(Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Тәмле булсын.)

– Ашаганда сиңа тәмле булсын дисәләр?

(Рәхмәт.)

– Ашап бетергәч нәрсә дип әйтәбез?

(Аллаһу әкбәр, Әлхәмделилләһ дип һәм ризык әзерләүчеләргә Аллаһның рәхмәте булсын дибез.)

– Сезнең хәлегез ничек?

(Әлһәмделилләһ. Бик әйбәт.)

– Йокларга ятканда нәрсә дип әйтәбез?

(Бисмилләһ. Тыныч йокы.)

– Аллаһны мактау ничек дип атала?

(Тәсбих.)

– Иптәшеңнең аягына ялгыш баскач нәрсә дип әйтергә?

(Гафу ит, ялгыш булды.)

– Кеше өенә кергәндә нәрсә дип әйтергә?

(Керергә ярыймы? Исәнмесез. Белсәләр, Әссәләмегаләйкем.)

– Өйдән чыгып киткәндә?

(Бисмилләһ. Сау булыгыз.)

– Әниләр эшкә киткәндә?

(Исән-сау йөрегез, Аллаһ ярдәм итсен. Хәерле юл.)

– Әнидән шарф бәйләүне ничек итеп сорыйбыз?

(Миңа шарф бәйләргә булыша алмассызмы?)

– Шарф бәйләгәч нәрсә дип әйтәбез?

(Рәхмәт!)

– Ләә иләһә илә Аллаһ сүзе нәрсәне аңлата?

Балалар, сез әле бу сүзне белмисез, бу яңа сүз, ул Аллаһ бер генә дигәнне аңлата. Һәм бу Аллаһка иң зур мактау. Бу сүзне әйткән кеше бөтен җиһанны ягъни җир, суларны, күкләр, болытларны – гомумән бөтен нәрсәне дә Аллаһ бар иткәнгә ышана.

Сез дә ышанасызмы?

– Әйе, ышанабыз.

Әйдәгез, алайса дисбеләребезне алыйк та Ләә иләһә илә Аллаһ тәсбихын бергәләп әйтик әле.

(Дисбе белән 99 мәртәбә Ләә иләһә илә Аллаһ тәсбихен әйтү.)

## 3 нче шөгыль
## Тема: «Коръән – Аллаһ Китабы»

*Максат:* балаларны Аллаһ китабы – Коръән белән таныштыру, анда нәрсә язылуы хакында аңлаешлы итеп мәгълүмат бирү. Башка китаплар, аларда ниләр язылуы турында искә төшерү. Коръәннең иң изге Китап булуына инандыру һәм хөрмәт тәрбияләү.

*Шөгыльгә кадәр эшләнәсе эшләр:* төркем бүлмәсендәге китапларны карап чыгу, ертык булганнарын төзәтү, ябыштыру, ремонтлау.

*Җиһазлау:* Коръән китабы.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, бүген без китапларны тәртипкә китереп куйдык, шулаймы?

Сез бик булдырдыгыз, тырыштыгыз. Аллаһның рәхмәте булсын сезгә. Сез китапларны яратасызмы? Аларда нәрсәләр язылган? Иң яраткан шигырегез кайсысы? Шигырь язучыны кем дип атыйлар? Сез кайсы шагыйрьләрне беләсез?

Ә иң яраткан әкиятегез кайсысы? Шүрәле әкиятендәге батыр егет кебек буласыгыз киләме?

Ә, өч кыз әкиятендәге «олы» кыз кебек буласыгыз киләме?

Балалар, китаплар кеше тормышын ямьләндерә, матурлый, әйбәт геройларга карап әйбәт буласы килә һәм начарларына карап та әйбәт буласы килә, чөнки начар кешеләрне яратмыйлар. Китапларны ертмыйча карарга һәм саклап тотарга кирәк.

Менә бүген мин сезгә бик зур бүләк алып килдем. Аны әнә анда, бездән еракта торган матур тартмага салып куйдым. Хәзер без аны ачып

карарбыз. Тик ул тартмага барып җитү өчен безгә сынаулар аша үтәргә кирәк. Әйдәгез, бер рәткә тезелеп басыйк әле.

Тәрбияче балаларга сораулар бирә. Сорауларга җавап биргән бала бер адым алга атлый, кем иң беренче шул тартма янына барып җитә, тартманы шул ала.

Алдагы шөгыльләрдә үткәнне кабатлау өчен сораулар бирелә:

1. Җирне, суларны, күкне кем булдырган?
2. Кешене кем бар иткән?
3. Тәсбих – нәрсә дигән сүз ул?
4. Нинди тәсбихләр беләсез?
5. Иң матур тәсбих?
6. Ашый башлаганда нәрсә дип әйтәбез?

Серле тартмага килеп җиттек, я, ачып карыйк инде? Нәрсә бар микән?

– Китап.

– Әйе, балалар, китап. Ләкин бу китап изге китап. Ул – Аллаһ китабы.

Кешеләр хөкүмәт төзиләр, ил булып яшиләр! Һәр ил, шул ил башлыклары үз илләрендә яшәүчеләр өчен законнар язганнар. Ул законнарны үтәмәсәң, аңа җәза бирәләр, шулаймы?

Аллаһ үзе ясаган җиргә яшәү законнары иңдергән. Ул законнар менә шушы китапта. Ул иң изге китап, чөнки кешеләрне яшәргә өйрәтә. Нәрсә эшләргә ярый, нәрсә ярамый – кешеләргә барысы да шушы китапта аңлатылган. Ул бүлекләр – сүрәләрдән һәм аерым җөмлә-дәлилләр – аятьләрдән тора. Анда төрле гыйбрәтле хәлләр – кыйссалар язылган, җирдә, күкләрдә тагын без күрмәгән белмәгән нәрсәләр бар, шулар турында язылган. Һәм Аллаһ турында язылган. Бу китап – Коръән. Ишеткәнегез бар идеме?

(Балалар фикерен тыңлау.)

Мин сезгә Коръән китабын укып күрсәтәм. (Фатиха сүрәсен уку.)

Әйе, балалар, әбиләрегез, бабайларыгыз да Коръән укыйлардыр, Коръән уку мәҗлесләре оештыралардыр. Балалар, Коръән кадерлеме? Кирәклеме? Аны башка китаплар янына куйыйммы? (Балалар фикерен тыңлау.)

Юк, балалар, башка китаплар да кадерле, билгеле, ләкин Коръән иң бөеге, чөнки ул – Аллаһ китабы, шуңа да аны чиста кеше генә тота ала һәм аны иң кадерле урында башка китаплардан биегрәк урынга куеп саклыйлар. Чөнки ул иң дөрес китап. Ә сезнең өйдә Коръән китабы бармы? Кайда саклана? Сезнең өйдә ул китапны укучылар бармы? Киләсе дәрескә шушы сорауларга җавап әзерләп килегез. Дәрес тәмам.

## 4 нче шөгыль
## Тема: Безнең күзләр бар нәрсәне дә күрәме?

*Максат:* Аллаһның кодрәтенә, Коръәндәге дәлилләргә ышандыру. Фәрештәләр, шайтан турында мәгълүмат бирү. Үз эшләреңне, гамәлләреңне бәяләргә өйрәтү, ярамаган эшләрдән тыелу, тәрбияләү. «Әгүүзү билләһи миннәш шайтаан ир раҗиим» сүзен өйрәтү.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, бирегә килегез әле, мин сезгә бер тартма алып килдем, ачып карыйк әле, анда ниләр бар икән? (Анда балаларның төрле гамәлләрен сурәтләгән рәсемнәр яисә язып куелган карточкалар чыга.)

Балалар, сез карточкаларны күрдегезме? Ә бүлмәдә тагын нәрсәләр күрәсез? Тәрәзәдән карыйк әле, анда нәрсәләр бар? (Балаларны тыңлау.) Ә хәзер күзне йомыгыз әле. Сез нәрсәдә булса күрәсезме? Әйе, балалар, Аллаһның кодрәте, безгә рәхмәте, ул безгә күзләр биргән. Аллаһка мактау әйтик әле.

– Әлхәмделлиләһ.

– Ә дөньяда күзләре күрмәгән кешеләр бармы?

– Аларны ни өчен Аллаһ сукыр иткән?

– Менә без күзле кешеләр өчен Аллаһ аларны гыйбрәт итеп яралткан. Без аларга карап гыйбрәт алырга һәм күзебезне күрә торган итеп яралткан өчен һәрдаим Аллаһка рәхмәтле булырга тиешбез.

– Балалар, ничек уйлыйсыз, ә безнең күзләр күрмәгән нәрсәләр бар микән бу дөньяда?

(Балалар фикерен тыңлау.)

– Бар икән. Бу дөньяда безнең күзләр фәрештәләрне, шайтанны, җенне күрми икән. Күрмәгәч, аларның барлыгын кайдан белгәннәр икән кешеләр?

– Белмәгән әйберне кайдан белеп була?

– Китаптан укып, телевизордан карап.

– Ә менә фәрештәләр, җеннәр, шайтан хакында кешеләр Коръәннән укып белгәннәр. Ул хакта бары Аллаһ кына белә һәм кешеләр дә белсеннәр дип, алар турында үзенең китабына язган.

Фәрештәләр канатлы, нурдан яратылганнар һәм берсүзсез Аллаһның әмерен үтәүчеләр. Алар бик тиз очалар, һәрдаим Аллаһка тәсбих әйтеп торалар. Әйдәгез без дә тәсбихләрне кабатлыйк әле. (Балалар тәсбихләрне кабатлыйлар.) Аллаһның кодрәте белән аларны кеше күзе күрми. Бихисап күп фәрештәләр арасыннан Коръәндә 4 төрле фәрештә

аерып тасвирлана. Бу Җәбраил фәрештә, Микаил фәрештә, Газраил фәрештә, Исрафил фәрештә. Аларның үзләренең җаваплы эшләре бар. Безнең һәркайсыбызның да янында фәрештәләр бар. Алар безнең ике җилкәбездә. Без нәрсә эшләсәк тә, алар безнең эшне язып баралар. Һәм шулай ук безгә күренми торган мәхлуклар арасында җеннәр дә бар. Җеннәр нәкъ кешеләр кебек яшиләр, ашыйлар, гаилә коралар, Аллаһ барлыгын беләләр. Бу хакта кешеләр Коръәннән укып беләләр.

Тагын бер мәхлук, безгә күренмәүче – ул шайтан. Аны Аллаһ уттан бар иткән, ягъни ясаган. Шайтан – тәкәббер, ул үзен барлык мәхлуклардан фәрештәдән дә, кешеләрдән дә, җеннәрдән дә өстен дип саный һәм берәүгә дә баш ими, буйсынмый. Аллаһ әмеренә дә буйсынмый. Ул кешеләрнең дошманы. Кешеләрне начар гамәлләр кылырга өндәүче, вәсвәсә салып котыртып торучы ул шайтан.

Ә хәзер тартмадан чыккан рәсемнәр буенча гамәлләргә бәя бирик әле. Кайсылыры яхшы гамәл, ә кайсылары начар шайтанга ияреп эшләнгән гамәл. (Түбәндәге биремнәр бирелә.)

1. Азат йокысыннан торды да әнисенә: «Хәерле иртә, әнием» – диде.

2. Азат күршеләре бакчасында үсеп утыручы алманы күрде һәм сорамыйча өзеп ашады.

3. Алисәгә әнисе күрше апага сөт кертергә кушты. Алисә күрше апаның ишеген шакыды да: «Керергә ярыймы?» – дип эндәште.

4. Рәиснең уенчык машинасын энесе алгач ул сүгенеп энесенә сукты.

Балалар начар сүзләр, сүгенү сүзләре әйтсәң шайтан дус таптым дип, сезнең янга йөгереп килеп җитә. Һәм син тагын да начар гамәлләр эшлисең. Шуңа да шайтаннан сакланырга кирәк.

«Әгүүзү билләһи минәш-шайтаанир-ражиим» сүзләре безне шайтаннан саклый.

Ягъни шайтанның әшәкелегеннән Аллаһка сыенам дигән сүз бу. (Шушы сүзтезмәне балалардан кабатлату.)

Балалар, ә фәрештәләр нинди кешеләр яныныда күп булалар икән?

– Кемнәр яхшы, әйбәт, кешеләрне шатландыра торган эшләр эшли, Коръән укый, алар шундый кешеләр янында булалар һәм аны начар эшләрдән саклыйлар икән.

Бездән, шайтан ерак йөрсен һәм яныгызда фәрештәләр йөрсен, дип телим мин сезгә.

## 5 нче шөгыль
## Тема: Дус булыйк

*Максат:* балаларга милләт төшенчәсен бирү. Халыкларның төрле телдә сөйләшүләре Аллаһның кодрәтеннән икәнен аңлату. Безнең районда яшәүче мари, удмурд, рус милләтләре, дөньяда гарәп, инглиз, япон, кытай кебек милләтләр булуы хакында мәгълүмат бирү. Башка милләтләргә хөрмәт һәм үз милләтең белән горурлану хисләре тәрбияләү.

*Җиһазлау:* төрле милләтләрнең сөйләмнәре язылган диск, төрле милләт вәкилләре төшерелгән рәсемнәр.

*Шөгыль барышы:*

Шөгыль төрле милләт вәкилләренең сөйләме язылган диск тыңлаудан башлана.

– Балалар нинди телләрдә сөйләштеләр бу язмада? Кайсыларын аңладыгыз?

(Балалар фикере тыңлана.)

– Әйе, балалар, бу язмада безнең ана телебез – татар телендә сөйләшү бар. Сез аңлаганы тагын рус телендәге сөйләшү булды, әйеме. Күрәсез, кешеләрнең телләре төрле-төрле. Безнең күрше авылда удмурдча сөйләшүчеләр яши, аларны удмуртлар, диләр. Безнең Балтач районында тагын марича сөйләшүче халык бар, аларны марилар, диләр. Балалар, ә кайсы тел сезгә бик ошады?

– Татар теле. Чөнки ул үзебезнең туган тел. Шуңа ул безгә бик матур һәм якын. Бик күп шагыйрьләр туган телне зурлап шигырьләр язганнар. Әйдәгез, Г. Тукайның «Туган тел» шигырен укып китим әле. (Тәрбияче Туган тел шигырен укый.)

– Балалар, сез татар теле матур, дидегез. Ә мари, удмурт, рус телләре хакында без ямьсез, дип әйтә алабызмы? Юк, балалар, чөнки без алай әйтсәк, кешеләрне кимсетәбез, рәнҗетәбез.

Аллаһ безне шулай төрле милләт итеп яраткан, бар иткән һәм Коръәндә: «Сезне төрле милләт итеп яраттым, минем алда сез, барыгыз да тигез» – ди. Шуңа да, без башка милләтләрне яратырга тиеш.

Ә хәзер экраннарга карыйк әле, кешеләр сөйләшүләре белән генә аерылалар микән? (Экрандагы кешеләрнең кием-салымнарына игътибар итү, балаларның фикерләрен тыңлау.)

Дөрес әйтәсез, балалар, кешеләр әле ничек киенүләре белән дә аерылып торалар. Экранда без гарәпләрне, японнарны, инглизләрне күрдек.

Алар һәрберсе үз илләрендә яшиләр һәм һәркайсының үзенә хас милли кияме бар.

Без дә шулай киеникме? Кирәкме шулай киенергә? Юк, шулаймы? Безнең үзебезнең милли татар киемнәребез бар. Алар бик матур һәм без шул матурлыкны сакларга тиеш, чөнки Аллаһ безне татар итеп яраткан.

Шөгыль милли татар киемнәрен карап тәмамлана.

### 6 нчы шөгыль
### Тема: Гөнаһ. Оят. Оятсызлыкның киемдә чагылышы

*Максат:* балаларны оят, гөнаһ төшенчәләре белән таныштыру. Коръәндә киемгә куелган таләпләрне җиткерү, аларны үтәү теләге тудыру һәм кием үрнәкләре сайлап, бизәргә өйрәтү. Гаурәт сүзенең мәгънәсен аңлату, килешле кием кию теләге булдыру.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, без бүген оятсызлык турында сөйләшербез. Сезнең кемне дә булса оятсыз дип орышканын ишеткәнегез бармы? (Балалар фикерен тыңлау.)

Әйе, оятсыз дип әшәке сүзләр сөйләүчегә, яла ягучыга, оят урыннарын күрсәтеп йөрүчегә әйтәләр. Кешеләр андый кешене оятсыз дисәләр, Аллаһ каршында андый кеше гөнаһлы була, ягъни ярамаган эш эшләүче була. Аллаһ кушканны үтәмәүче була.

Балалар, кеше тәнендә оят җирләр бар, аларны кешеләргә күрсәтергә ярамый, без кеше күрмәгәндә генә чишенеп, кием алыштырабыз, мунчага да бөтен кеше бергә кермибез шулаймы? Чөнки тәнебезне күрсәтү – оятсызлык. Коръәндә дә Аллаһ тәннең гаурәт өлешен капламыйча йөрмәскә куша. Гаурәт – ул тәннең барлык кешегә дә күрсәтергә ярамаган өлеше. Кызларның кул чуклары, йөзе һәм аякның тубыктан аскы өлеше генә гаурәт түгел, ә ир малайларның билдән алып тезгә кадәр арасы гаурәт, ягъни күрсәтергә ярамый.

Ә хәзер рәхим итеп өстәлләрегез янына килегез әле, мин, һәрберегезгә кәгазьдән кисеп ясалган курчак алып килдем. Аның киемнәре дә бар. Карыйк әле, шуларны. Алар матурмы? Кайсы ягы ошый, кайсысы ошамый?

Тәрбияче ике тартма куя һәм киемнең ошаган, ошамаган якларын санаганда һәр билге саен 1 фишка салып бара.

Күрәсезме, балалар, ошамаган яклары күп булды. Әйдә, курчакларыбыз оятсыз булып гаурәтләрен күрсәтеп йөрмәсеннәр, матур күлмәкләр ясыйк әле. Курчакларга яулык, озын күлмәк ясау өчен шаблоннар бирү, аны кисеп ясау һәм милли бизәкләр белән бизәү.

## 7 нче шөгыль
## Тема: Пәйгамбәрләр

*Максат:* пәйгамбәрләр, аларга хас сыйфатлар хакында төшенчә бирү. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. аның тормышының кайбер өлешләре белән таныштыру. Сөннәт төшенчәсен аңлату. Пәйгамбәребезгә иярүчеләрне мөселманнар булуын аңлату һәм пәйгамбәребезгә, башка пәйгамбәрләргә хөрмәт тәрбияләү, аңа иярү теләге булдыру. «Мөхәммәдрәсүл Аллаһ», «Сәлләлаһу галәйһи вәссәламу» сүзтезмәләре белән сүзлекләрен баету.

*Шөгыль барышы:*

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

– Балалар, әйдәгез дисбеләрне алыгыз да беренче шөгыльдә өйрәнгән тәсбихләрне әйтүдән башлыйк әле. (Иң матур тәсбихләрнең берсе Ләәиләһш илә Аллаһ әйтү). 99 тапкыр әйткәннән соң, тәрбияче, Мөхәммәд рәсүл Аллаһ дип куя.

– Әйдәгез, бергәләп кабатлыйк әле.

– Балалар, сез Мөхәммәднең кем икәнен беләсезме?

– Аллаһ безгә Коръән биргән дибез, кемгә биргән, ничек биргән икән ул аны?

– Балалар, Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе булсын) безнең пәйгамбәребез. Пәйгамбәрләр – Аллаһ кешеләр арасыннан үзенең хәбәрен, сүзләрен, яшәү кагыйдәләрен башкаларга да җиткерү өчен сайлап алган кешеләр. Аллаһ нинди кешеләрне пәйгамбәр итеп сайлый? Дөресен сөйләүче, беркайчан да яманламаучы, кешеләр арасында гадел булган, кешеләрне рәнҗетмәүчеләрне пәйгамбәр итеп сайлый һәм аңа хәбәрләр җиткерә. Мөхәммәд пәйгамбәр дә шундый сыйфатларга ия була. Гадел, дөресен әйтүче булганга аны кешеләр Әмин дип тә йөртәләр. Ул гарәп милләтеннән. Шуңа да Коръәнне Аллаһ гарәп телендә иңдерә һәм без өйрәнә торган тәсбихләр дә гарәпчә.

Аның әтисе Габдулла исемле, ул пәйгамбәребез Мөхәммәд туганчы ук үлеп китә, ә әнисе Әминә исемле. Ул да пәйгамбәргә 6 яшь тулгач үлеп китә. Кечкенә Мөхәммәд бабасы тәрбиясендә 8 яшькә кадәр тәрбияләнә. Бабасы да үлеп киткәч 8 яшьтән агасы Әбү Талиб тәрбиясендә үсә.

Гарәпләр, бала таза, авырлыкларны җиңәргә күнегеп үссен дип аны чүлдә яшәүчеләргә бирә торган булалар.

Мөхәммәдне дә Хәлимә һәм Харрас дигән кешеләргә тәрбиягә бирәләр. Хәлимә – Пәйгамбәребезнең сөт анасы.

25 яшендә Мөхәммәд Хәдичә исемле хатынга өйләнә, ә 40 яшендә аңа пәйгамбәрлек килә. Ягъни аңа Аллаһ үзенең хәбәрләрен – Коръәнне иңдерә башлый. Бу хәл Хира тавында була һәм хәбәрне аңа Җәбраил фәрештә алып килә. Пәйгамбәребезгә әйтелгән Аллаһның беренче сүзе «Укы!» була. Мөхәммәд мин укый белмим ди. Чыннан да ул бер хәреф тә белми, Коръәнне укый-яза белмәгән кешегә иңдерү ул Аллаһның хикмәте. «Укы!» сүзе өч тапкыр кабатлана һәм Коръәннең «Галәк» сүрәсенә иңә. Аллаһ кодрәте белән Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәтерендә калдырыла бу сүрә. Сез дә әле укый белмәсәгез дә шигырьләрне ятлар сөйлисез, шулаймы? Ә пәйгамбәребез хәтерендә бер әйтү белән кала. Чөнки ул – пәйгамбәр. Аңа Аллаһ кешеләргә хас булмаган сыйфатлар да бирә. Пәйгамбәрләр фәрештәләрне, җеннәрне дә күрәләр, алар хакында Коръәндә күп әйтелә.

Җирне барлыкка китергәннән бирле Аллаһ күп пәйгамбәрләр җибәргән, кешеләргә аларга ияргәргә кушкан. Аларга изге китаплар җибәргән. Коръәндә Адәм, Муса, Гайсә, Ибраһим, Нух һ.б. бик күп пәйгамбәрләр хакында сөйләнә.

Пәйгамбәрләрнең исеме телгә алынганда Аллаһның аңа мактавы һәм сәламе булсын диелә. Ул гарәпчә болай яңгырый. «Салләллаһу галәйһи вәссәлам» (Әйдәгез кабатлап карыйк әле.) (Балалар бергәләп кабатлыйлар, аннан тәрбияче пәйгамбәрләрнең исемен әйтеп тора, ә балалар чираттан «Салләллаһу галәйһи вәссәләм» дип кабатлыйлар.)

Коръәндә җиргә башка пәйгамбәр килмәс диелә. Димәк, Мөхәммәд с.г.в. ул ахыргы пәйгамбәр.

Пәйгамбәребез инде күптән 63 яшендә үлгән, аның 7 баласы булган, алар да үлгәннәр.

Пәйгамбәребез кебек яшәүчене, аңа иярүчене мөселман, диләр.

Пәйгамбәребез мөселманнарга яшәү өчен бик күп эш, гамәлләрнең үрнәген калдырган. Ягъни пәйгамбәребез шулай эшләгән, без дә шулай эшлибез. Аларны сөннәт диләр. Һәм Аллаһ китабы Коръәнне калдырган. Мөселманнар шул китап буенча яшиләр. Безгә дә шулай яшәргә язсын!

Сезнең белән миңа бүген бик рәхәт булды. Барыбызга да, сезгә дә, миңа да мөселман булып яшәргә язсын. АӘмин!

**8 нче шөгыль**
**Тема: Кечкенә Мөхәммәднең олы могҗизалары хикәясен уку, эчтәлеге буенча эш.**

*Максат:* пәйгамбәребезгә бирелгән могҗизалар, аңа бирелгән Аллаһ рәхмәтенең кайбер чагылышлары белән танышу. Хикәянең эчтәлеген аңларга һәм анализларга өйрәтү.

*Җиһазлау:* көмеш кыңгырау гәҗите Фатиха кушымтасы 27 сентябрь 2008 ел.

*Шөгыль барышы:*

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Балалар, без бүген пәйгамбәребезнең кечкенә вакыты турында бер хикәя укырбыз.

Кечкенә вакытында ук аның башкалардан аермалы яклары булдымы икән? Игътибар белән тыңлагыз әле.

Тәрбияче хикәяне укый.

Укып бетергәч, түбәндәге схема буенча эчтәлеге өстендә эшлиләр.

Нинди матур йорт шулаймы? Әйдәгез, йортның түбәсен тотып торучы баганаларга Хәлимә белән Харисның тормышларына кагылышлы мәсьәләләрне куйыйк әле.

Аларның ишәкләре нинди була?

Карт һәм зәгыйфь, әкрен йөри торган була.

Ә бала алып, аны ишәккә утырткач ниндигә әйләнә?

Көчле һәм кызу йөри торганга әйләнә.

Бала алырга килгәндә ишәк шәһәргә ничәнче булып керә?

Ишәк шәһәргә иң соңыннан керә.

Ә бала алгач, авылга ничәнче булып кайта?

Булачак пәйгамбәребезне утырткач, ул авылга беренче булып кайтып керә.

Хәлимәләрнең сарыклары бала алганчы таза, сөтле буламы?

Юк, алар арык булалар, сөтсез булалар.

Ә булачак пәйгамбәребез нәни Мөхәммәд йортта тора башлагач, сарыклар ниндигә әйләнә?

Алар сөтлегә әйләнәләр.

Нәни Мөхәммәдне урамга алып чыкканда кояштан капларга кирәк буламы?

Юк. Аны урамга алып чыкканда баш өстендә кечкенә болыт барлыкка килеп кояштан саклап тора.

Кешеләр, Аллаһтан яңгыр сорар өчен кемне алып чыгалар?

Аллаһтан яңгыр сорар өчен нәни Мөхәммәдне үз яннарында тоталар.

Менә күрәсезме баганаларны тутырып бетердек. Ә ни өчен шулай була? Без баганаларның нигезенә нәрсә языйк, ул баганаларны нәрсә тота? Аллаһ рәхмәте, шулаймы? (Димәк, бу үзгәрешләр, вакыйгалар барысы да Аллаһ рәхмәте белән була, дип, тәрбияче нигезгә «Аллаһ рәхмәте» сүзен язып куя.)

Һәм бу могҗизалы вакыйгалар барысы да Мөхәммәднең гади генә бала түгел, ә булачак пәйгамбәр икәнлеген раслый, дип түбәгә Мөхәммәд с.г.в. пәйгамбәр дип язып куя.

## 9 нчы шөгыль
## Тема: Әти кирәк! Әти безгә терәк!

*Максат:* балаларны әти кешенең гаиләдә иң әһәмиятле хезмәт һәм вазифалар башкаруына төшендерү, әтиләргә карата хөрмәт тәрбияләү. Коръәндә әти-әниләргә карата мөнәсәбәткә нинди таләпләр куелуы белән таныштыру.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, сезнең өйдә урындык ватылса, кем төзәтә?

– Койма ишелсә, кем төзәтә?

– Ә капчык белән онны кем күтәреп керә?

– Машинагыз ватылса, кем төзәтә?

Күрәсез, балалар, өйдә бөтен көч, куәт кирәк эшләрне әти эшли икән. Чөнки ул ир-ат, көчле, ул һәрвакыт гаиләдәге һәрбер кеше өчен кайгыртып тора.

– Ә ни өчен алар эшкә баралар?

Эшкә баруы да аның гаилә өчен ризык һәм кием-салымнар алу өчен акча кирәк булганга. Чөнки әти кешегә бик зур вазифа гаиләсен, өй, кием-салым, ризык белән тәэмин итеп тору йөкләнгән. Аллаһ ир-егетләрне әти булсыннар өчен һәм гаилә, бала турында кайгыртып торсын өчен бар иткән.

Ә без, балалар, әтигә нинди мөнәсәбәттә булсак, әйбәт булыр икән? (Балалар фикере тыңлана.)

Әйе, балалар, әтине яратырга, аның сүзен тыңларга, белмәгән, аңламаган әйберләрне әтидән сорап белергә һәм әти кушканны тыңларга, әти эшләргә өйрәткән эшләрне эшләргә өйрәнергә тиешбез. Әтидән сорамыйча йорттагы әйберне кешегә биреп торырга да ярамый, әтидән

рөхсәт сорарга кирәк, әтидән рөхсәт сорамыйча кая да булса барырга да ярамый, бары әти рөхсәте белән генә барырга була.

Тыңлагыз әле Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа рәхмәте булсын) әти-әниләргә хөрмәт турында «Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр», – диде. Коръәндә «Аллаһ Раббың ата-анага игелек эшләргә боерды», – диелә.

Ә Коръәндә без үтәргә тиешле законнар, кагыйдәләр язылган.

## 10 нчы шөгыль
## Тема: Туганлык.

*Максат:* балаларга туганлык төшенчәсен аңларга өйрәтү. Коръәнгә нигезләнгән туганнарга карата булган әдәпләрне җиткерү.

*Шөгыль барышы:*

– Балалар, әйдәгез бүген гаиләдәге кешеләр хакында сөйләшик әле. Сезнең гаиләгездә кемнәр бар?

(Балаларның үз гаиләләре турында сөйләүләре тыңлана.)

Бер гаиләдә яшәүче апалар, абый, энем, сеңлемнәр туганнар була.

Гаиләдә олы кешеләргә хөрмәт була, аларның сүзләре өстенрәк була, димәк, олыларның сүзләрен тыңлыйлар, ә кечеләргә булышалар, ярамаган эшләрдән «Алай эшләргә ярамый», – дип тыялар.

Туганнар бер-берләренә изге, яхшы эшләрдә булышалар.

Мөхәммәд пәйгамбәребез: «Кечкенәләргә рәхим-шәфкатьле булмаган, олыларыбызның кадерен белмәгән кеше безнең арадан түгел»,– дигән. Әйдәгез төрле хәлләргә бәя бирик әле. Тәрбияче, балаларга төрле хәлләр укый, ә балалар бәя бирәләр.

Әнисе чакыргач та аның янына килмичә йөгереп йөргән малай, әнисенә кадер күрсәткән буламы.?

Яисә апасы: «Мин идән юганда йөгермичә утырып китап кара, алайса оекбашларың юешләнә», – дип әйткәч, тыңламыйча йөреп торган кыз апасына хөрмәт күрсәткән буламы?

Сезнең өйдә тормаган кешеләр дә сезгә туган була аламы? Сезнең андый туганнарыгыз да бармы? (Балалар фикере тыңлана.)

Әйе, балалар, алар башка өйдә торсалар да сезнең туганнар, чөнки алар кайчандыр сезнең әниләр яки әтиләр белән сез апа, энеләрегез белән бергә үскән күк бергә үскәннәр, алар да сезнең туганнар. Шуңа аларга да хөрмәт белән карарга, дус булырга, кунакка барып хәлләрен белеп торырга кирәк. Чөнки Аллаһ Коръәндә «Туганнарның хакларын үтә», – ди.

Ә хәзер, әйдәгез, бер хикәя укып китик әле. «Галимәләр гаиләдә җиде кеше. Әтисе, әнисе һәм 5 бала: абыйлары Азат белән Ирек, апасы Кадрия, Галимә һәм энесе Йосыф. Алар бик тату яшиләр. Бүген әнисе һәрбер гаилә әгъзасына берәр шоколад алып кайтты һәм үзе абзарга хайваннар карарга чыгып китте. Абый-апалары әле мәктәптән кайтмаганнар иде. Галимә белән энесе үзләренә дигән шоколадны ашарга уйладылар. Энесенә конфет ошап китте ул тагын берне алып ашады. Ә кичке чәйдә әниләренә шоколад җитмәде.

– Аны энем ашады, – диде Галимә. Ә энесе елый ук башлады. Әнисе инде Галимәнең энесе өчен генә түгел, ә Галимә өчен дә борчыла иде. Галимәнең әнисе нәрсә өчен борчылган? Сез ничек уйлыйсыз, балалар? (Балалар фикере тыңлана.) Әйе, энесе сорамыйча шоколадны алып ашаган. Гаиләдә һәркемгә дип алынган ризык тигез итеп бүленергә тиеш. Яисә аны алганда әти-әнидән рөхсәт сорарга кирәк.

– Ә Галимә энесе ашаганны әйтмәскә тиеш иде. Ул аны әләкләде. Энесе үзе әйткәнне көтәргә иде. Үзе әйтмәсә, соңыннан әти-әниләре юкта энесенә үзеңнең гаепле икәнлегеңне үзең әйтергә кирәк, дип энесен өйрәтергә була. Чөнки Галимә өлкәнрәк, апа кеше. Ә апа кеше энесен өйрәтергә тиеш. Туганнар өстеннән әләкләргә ярамый.

Әйдәгез бүген өйрәнгән кагыйдәләрне кабатлап чыгыйк әле.

1. Туганнарга хөрмәт белән кара.
2. Олы туганнарның сүзен тыңла.
3. Кече туганнарга ярдәм ит.
4. Туганнарны әләкләмә.
5. Туганнарның изге эшләрендә ярдәм итәргә тырыш.
6. Башка йортта яшәүче туганнарның хәлләрен белеш.
7. Туганнарга карата яхшы теләктә бул, үзеңә теләгәнне аларга да телә.

## 11 нче шөгыль
## Тема: Чисталык әдәпләре.

*Максат:* мөселманның төп билгеләреннән берсе чисталык булу хакында төшенчә бирү. Тәһарәт сүзенең мәгънәсен аңлату һәм тәһарәтләнү күнекмәсе тәрбияләү.

*Җиһазлау:* әби киеме, тәһарәтләнү тәртибе күрсәтелгән рәсем, курчак, һәр балага чисталык кагыйдәләре язылган истәлекләр.

*Шөгыль барышы:*

Балалар, менә бүген конфет белән чәй эчкәч, кулларыгыз балланды һәм сез: «Кул юып килим әле», – дип сорадыгыз. Ә юмасак, нәрсә булыр иде? Безгә бик читен булыр иде, шулаймы? Аллаһ рәхмәте – җирдә су бар. Бу Аллаһның кешеләргә биргән байлыгы һәм Аллаһ безгә һәрвакыт чиста йөрергә куша.

Юынмаган көе ашарга, Коръән укырга, намаз укырга, дога кылырга да ярамый.

Һәркөн иртән юынудан башлана. Бәдрәфкә кереп, олы һәм кече йомышларны үтәгәч, оят урыннарны су белән юарга кирәк. Без бәдрәфтә кәгазь кулланырга күнеккән. Кәгазь белән чистарынып бетеп буламы? Менә карагыз әле. (Тәрбияче балчык белән су измәсенә таяк тыга һәм кәгазь белән сөртә, аннан соң су белән югач кына чистаруын күрсәтә.) Димәк, бәдрәфтә һәрвакыт су белән юынырга кирәк. Оят урыннарны сул кул белән юабыз. Бәдрәфкә кергәндә сул аяк белән атлап «Бисмилләһ», дип керәбез, «Гафу ит, мине», – дип уң аяк белән атлап чыгабыз.

Һәм юынуның да үз тәртибе бар. Сез еш кына әбиләрегездән тәһарәтләндем, тәһарәт алдым, дигән сүзне ишеткәнсездер. Тәһарәт ул чистарыну дигән сүз. Гади генә чистарыну түгел, ә Аллаһ кушкан тәртип белән чистарыну. Ничек дип аталды инде, чистарыну, тәртип белән юыну?

Әйе, тәһарәт дип атала.

Әйдәгез, аның тәртибен аңлап китик инде.

– И, балалар, мин үзем дә онытып җибәрдем әле ничек итеп тәһарәт аласын. Асия әбине генә чакырып керим әле.

Асия әби булып киенеп тәрбияче керә һәм тәһарәт тәртибен өйрәтә.

Беренче «Бисмилләһ» дибез, аннан соң өч мәртәбә куллар юабыз, өч мәртәбә авыз чайкыйбыз, аннан өч мәртәбә борынга су алып борын юабыз, аннан өч мәртәбә йөзебезне югач, кулларыбызны терсәккә кадәр өч мәртәбә юабыз да, кулларны чылатып колакны ышкыйбыз, башны һәм муенны сыйпагач, өч мәртәбә аякларны юабыз.

Балалар, исегездә калдымы? Юкмы, әйдәгез, минем белән кабатлыйк алайса. (Балалар әби артыннан тәһарәтне имитациялиләр.)

Әби-тәрбияче курчакка мөрәҗәгать итә: «Әйдәле, кызым Сылу, син түгәрәккә бас та балаларга тәһарәт алып күрсәт, ә алар дөрес эшлисеңме, ялгышасыңмы, карап торсыннар.

Курчак, ялгышлар җибәреп тәһарәт тәртибен кабатлый, ә балалар аны төзәтәләр.

Инде хәзер өйрәнеп беттек, я кайсыгыз тәһарәтләнеп күрсәтә? (Аерым балалардан тәһарәтләнү тәртибен кабатлату.

Ә хәзер, әйдәгез, кайчан тәһарәтләнергә кирәк икәнен искә төшерик. (Балалар фикере тыңлана.)

Ашар алдыннан тәһарәтләнү мәҗбүриме? Юк. Ашар алдыннан кул юу һәм ашап бетергәч кул юып авыз чайкау мәҗбүри.

Ә йокларга ятканда тәһарәтләнү мәҗбүриме? Юк. Ләкин йокларга ятканда тәһарәтләнү хәерле, матур гамәл.

Балалар, бүген миңа сезнең белән бик рәхәт булды, шуңа да сезгә чиста булу кагыйдәләре язылган истәлек таратам. Сез аны кайткач, әниләрегез белән укып чыгыгыз һәм гаиләгездә һәрвакыт шул кагыйдәләрне үтәгез.

## 12 нче шөгыль
## Тема: Дога.

*Максат:* балаларны матур теләк теләргә өйрәтү. Теләкләрне тормышка ашыручы бер Аллаһ икәнлегенә төшендерү. Дога төшенчәсен бирү. Дога кабул булу өчен нинди шартлар булырга кирәклеген аңлату. Башка кешеләргә дә матур теләктә, догада булу хисләре тәрбияләү.

*Шөгыль барышы:*

Балалар, әйдәгез Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыренең ахыргы куплетын искә төшерик әле.

И туган тел,
Синдә булган
Иң элек кылган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, Ходам!

Балалар, Г. Тукай кылган догам, ди. Нәрсә соң ул дога? Сезнең дога кылган кешене күргәнегез бармы? (Балаларның фикерләре тыңлана.)

Әйе, әбиләр, күп дога кылалар. Нәрсәләр дип дога кылалар соң алар?

Балам сау-сәламәт булсын, дип,
Илләр тыныч булсын, дип,
Табыннар мул булсын, дип һ.б.

Күрәсезме, нинди матур теләкләр. Балалар, дога ул матур теләк, сорау дигән сүз, ә кемнән сорыйлар соң сезнең әбиләрегез, бабаларыгыз?

Балалар, алар Аллаһтан сорыйлар. Чөнки бар әйберне бирүче, безне сәламәт итүче дә, игеннәрне мул итүче дә Аллаһ. Бары Аллаһтан сорасаң гына безнең дога кабул була.

Без, бәйрәмнәрдә бер-беребезгә матур теләкләр телибез, ләкин Аллаһ сүзен әйтергә онытабыз. Шуңа да теләк теләгәндә дә Аллаһ сиңа сәламәтлек, байлык бирсен дип теләргә кирәк. Шул вакытта безнең теләкләр тормышка ашар.

Тагын шигырьне искә төшерик әле. Г. Тукай нәрсә сорап дога кылган?

Ярлыкагыл, (ягъни ярлыка, кичер, гафу ит дигән) дип, үземне һәм әткәм-әнкәмне, Ходам! Г.Тукай үземне генә кичер дип теләгәнме? (Балалар фикере тыңлана.) Әйе, ул әти-әнисен дә кичерүне теләгән.

Сез дә дога кылганда үзегез өчен генә түгел туганнарыгыз өчен дә, әти-әниегез, дусларыгыз өчен дә сорагыз. Шулай итсәң генә дога кабул булыр, Аллаһ теләсә.

Дога кылучы чиста, пакь киемнән һәм үзе дә тәһарәтле булырга тиеш. Дога кылганда әбиләребез ничек итеп утыралар? (Балалар фикере тыңлана.)

Әйе, алар кыйблага карап баш иеп, түбәнчелек белән кулларын күтәреп дога кылалар. Ә сез, ул вакытта нишлисез? (Балалар җавабы.) Ә менә пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. : «Берәр кешенең догага куллары күтәрелгәнен күрсәгез, сезнең дә догага кулларыгыз күтәрелсен!», – дигән. Димәк, әбиләр дога кылганда без дә кулларны догага күтәрү әйбәт гадәт, саваплы. Әбиләр, дога кылыр алдыннан нәрсә эшлиләр?

– Коръән укыйлар, садака бирәләр, намаз укыйлар.

– Әйе, балалар, алар изге эшләр эшлиләр. Изге эшләр эшләгән кешеләрнең догалары һәрвакыт кабул була. Әйдәгез, без дә, дога кылыйкмы? Тәрбияче Коръәннең «Фатиха» сүрәсен укый һәм дога кыла:

Я, Раббым бер Аллаһ, бары үзеңә сыенып үзеңнән сорыйбыз, кулларын догага күтәрүче балаларның догаларын кабул итеп, һәркайсына саулык, сәламәтлек, иман байлыгы биреп, әти-әнинең күркәм тәрбиясендә үсеп, миһербанлы, шәфкатьле, илгә, кешеләргә файдалы гыйлем алып хезмәт итәргә, үзеңнең ризалыгыңны алырга насыйп итсәң иде. Амин!

Әдәбият

1. Коръән.
2. Габдрахман Кайа. «Исламда әхлак».
3. «Пророк Мухаммад и дети». Издательство «Диля».
4. Ибн Мирзакарим ал-Карнаки «Притчи из Корана».
5. Ризаэддин Фәхретдин «Җәвамигъ әл-кәлим шәрехе».

***Сәхәбиева Люция,***
*Теләче районы балалар иҗат үзәге*

## «ИЛЛӘР ГИЗИК, ГЫЙЛЕМ ЭЗЛИК» СӘЯХӘТ ДӘРЕС

(Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Дәреснең максаты:*

1. Гарәп телендә гыйлемлелеккә кагылышлы яңа әдәпле сүзләр, хәдисләр өйрәнү.

2. Хәдис – нәсыйхәтләрдә язылган акыллы һәм төпле киңәшләрне тормыш-көнкүрештә куллану.

3. Гарәп теленә, диненә мәхәббәт тәрбияләү, яшь буында әхлаклылык сыйфатларын арттыру.

*Җиһазлау:* компьютер, диск (Гарәбстандагы күренешләр төшерелгән слайд), карточкалар.

*Дәрес барышы:*

I. Оештыру.

Исәнләшү.

– Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

– Вәгаләйкемәссәләм.

– Иҗлиснә.

Дәрескә йөрешне тикшерү.

II.Үткән материалны кабатлау.

Укучылар, сез татар, рус, инглиз телен өйрәнүләргә өстәп, гарәп телен дә үз теләкләрегез белән өйрәнәсез, шулай бит. Дәрдмәнднең дә шундый сүзләре бар: «Бер тел белгән, бер ил күргән, күп тел белгән, күп ил күргән». Менә без дә шушы сүздәге кебек хыялыбызда гарәп теленең ватаны булган Гарәбстанга сәяхәткә кузгалырбыз.Сәяхәтебездә әхлаклылык кагыйдәләрен искә төшерербез, тагы да күбрәк гыйлемнәр эзләрбез.

(Слайд ачыла:

يَوْمَ وَحِد فِى الْعَرَبِيَةِ


– сәфәр әдәпләренә кадәр)

Һәр кеше юлга чыкканда, нинди кагыйдәләрне истә тотарга тиеш әле?

*– Өйдән уң аяк белән атлап чыгарга.*

*– Юлыбыз хәерле булсын өчен Аллаһы Раббыбызга тапшырырга, ягъни Бисмилләһ әйтергә.һ.б.*


Хәзер безгә билетлар кирәк. Билет бушка гына бирелми. Һәрберебез дә карточкалар алабыз. Анда мисаллар язылган. Гарәпчә саннар белән аларны чишәбез.



*(Мисаллар дәфтәрләрдә эшләнә, карточкалар таратыла, берәү тактада эшли.)*

Иптәшләрегез белән алмаштырып дөреслеген тикшереп чыгабыз. Җаваплар дөрес булмаган очракта үзем сораулар бирәм. *(Тикшерелә.)*

Әйдәгез, укучылар, билетларның икенче ягын әйләндерик, анда безгә могҗизалы самолетта очар өчен вакытлары күрсәтелмәгән, ә без эшләгән мисаллар аша аларны тутырырбыз.(Вакыт, урын, бәя, сәгать.)




– Билетларга үзегезнең исем фамилиягезне гарәпчә языгыз. Самолетның могҗизалыгы шунда, бу шарларда кешедә булырга тиешле әхлаклылык сыйфатлары язылган, ул сезгә юлда һәм һәр очракта һәрчак кирәк.

**III. Яңа материал өйрәнү.**

– Хәзер безгә түгәрәкнең иң актив әйдаманы, ягъни стюардесса кирәк булачак. Әйдәгез, аны Илүсә итик.

*– Хәерле көн, хөрмәтле пассажирлар! Хәзерге вакытта без кузгалып киттек, безнең биеклек 800 метр.Тышта температура – 10, терекөмеш баганасы буенча, атмосфера басымы 730. Безнең маршрут Казан аэропортыннан башлап, Мәккә шәһәренә кадәр. Хәерле юл, сезгә!*

(Слайд ачыла. 4-музыка гарәпчә.)

Рәсемнәр өстендәге гарәпчә язуларны уку.

*– Бу нәрсә?* مَاهَذِهِ

*Бу Мәккә шәһәре* هَذِهِ مَدِينَةِ الْمَكَّ

*Бу Мәдинә шәһәре* هَذِهِ مَدِينَةِ المَدِينَ

*Бу аэропорт* هَذَا مَطَارٌ

– Менә без чит илгә килеп кердек. Пәйгамбәребезнең шундый хәдисе бар: «Әссәләмү вәһид кәтәбти» – «Сәлам сүздән әүвәлдер» дигән. Үткән дәресләрдә сәламләшүгә кагылышлы күп кенә хәдисләрне өйрәнгән идек. Искә төшерик әле:

*1) Пәйгамбәребез: «Сөйләшкәндә, сәламләшкәндә һәрвакытта да уртача тавышта бул», – дигән.*

*2) Пәйгамбәребез: «Нихәл» диеп исәнләшүгә караганда, «Әссәләмегаләйкем!» – дисәгез 10 савап, «вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ», дисәгез 30 савап була», – дигән.*

– Дөрес укучылар хәзер инде гарәпчә хәл белү сүзләрен искә төшерик.

*– Әссәләмегаләйкем – Вәгаләйкемәссәләм!*

*– Кәйфә халәкә? – Әнә бихәйри шүкрән! Хәлең ничек? Әйбәт, рәхмәт.*

*– Мәрхәбән! Сәлам!*

*– Мәсәил -хәир! Мәсәин-нур! Хәерле кич!*

*<u>Яңа сүзләр</u>*

*Сабәхәл-хәйр! Сабәхән-нур!* – Хәерле көн!

*Әхлән вә сәхлән!* – Рәхим итегез!

Укучыларга илнең визит карточкасы, акчалары күрсәтелә. Таможня тикшеренүе үткәндә һәммә кешегә дә кечкенә генә белешмәлек бирелә. Хаж вакытында тел белмәүче чит илләрдән килгән хаҗиларга адашмас өчен беләзек таратыла.

Чит илгә киткәндә, әлбәттә, иң кирәк нәрсә – ул гыйлем. Пәйгамбәребез (с.г.в.) нең дә шундый бер хәдисе бар, йәгез әле аны тактадан укыйк.

اَلْعِلْمُ فِى الْصِغرِ كَنَقْشِ فِى الْحَجَرِ

Мәгънәсе: «Яшь вакытта алган белем таштагы нәкышкә (язуга) бәрабәрдер», ягъни яшь вакытта алган белем тиз генә онытылмый.

Әйдәгез, бу әһәмиятле хәдисне дәфтәрләребезгә күчереп языйк әле.

(*Дәфтәрләргә күчереп языла.)*

Гыйлемлеккә тагы берничә хәдисне китереп китәсем килә:

1. «Гыйлем эзләү һәр мөселманга фарыз».

2. «Гыйлемне өйрәнүче, йә булмаса яратучы бул, әмма гыйлемне яратмаучы, галимне хөрмәт итмәүче булма!», – диде.

Бу хәдиснең мәгънәсе нәрсәдә?

Белем алу өчен безгә тырышырга кирәк, ә безне өйрәтүчеләрне, укытучыларны без хөрмәтләргә тиеш.

– Гыйлем 2 төрле: дөньяви гыйлем һәм дини гыйлем. Мөхәммәд (с.г.в.) безгә шушы 2 гыйлемне дә тигез өйрәнергә кушты.

– Укучылар, Аллаһы Тәгалә кешеләрне бертөрле генә итеп яратмаган. Төрлебездә төрле характер. Бер көн, икенче көнгә, бер төн икенче төнгә ошамаган кебек, табигать тә төрле илдә төрлечә.

Әйдәгез, Гарәбстанның табигатен күзәтик әле. Ул безнең табигатькә ошаганмы?

(Слайдтан күренешләр күрсәтелә. 4 кадр. Сорауларга – җаваплар бирелә.)

*– Таулар күп, температура +35 +40 С. Анда комлыклар, чүлләр күп. Бездән аермалы буларак анда пальмалар үсә.*

– Менә бу класста да пальма агачы бар, анда тылсымлы сүзләр язылган, ләкин ул сүзләрне табар өчен җиләк-җимешләрнең исемнәрен әйтергә кирәк. Яле, кайсыларыгыз? (Һәр укучы җиләк-җимеш ясалган рәсемнәргә карап, гарәпчә әйтелешен әйтеп ала һәм алда басып тора, соңыннан алфавит тәртибендә басалар. Ә һәр җиләк-җимешнең арткы ягына гарәпчә сүзләр язылган.)

Алгы якта рәсемнәр, арткы якта гарәпчә сүзләр:

*Бүртүкалүн-апельсин* أَلْهاجَلُ

*Түффәхүн-алма* يَطْلُبُ

*Ганәбүн-йөзем* أَلْمَالُ

*Рутабүн-хөрмә* وَالْعَاقِلُ

*Ләймун-лимон* يَطْلُبُ

*Ә хәзер гарәпчә алфавит тәртибендә басабыз. Арткы якта язылган сүзләрне укып чыгыгыз әле.*

أَلْهاجَلُ يَطْلُبُ أَلْمَالُ وَالْعَاقِلُ يَطْلُبُ

*Бу мәкальнең тәрҗемәсе:*

– Эш акчада түгел, ә акылда. Бу мәкальне ничек аңлыйсыз?

*– Акча белән генә бөтен нәрсәне дә эшләп булмый, ә күп очракта акыл кирәк.*

*(Дәфтәрләргә язылa.)*

Табигатьне күзәттек шулай бит, бездәге кебек түгел. Гарәпләрнең тормыш итү рәвеше дә үзгәрәк. Бу илләр турында сөйләшкәндә андагы мәчетләргә тукталмасак, аларның тормышын тулы итеп күз алдына китерә алмас идек.

Гарәпләр һәм мәчетләр аерылгысыз.

(Слайдта мәчетләр күренеше карала.)

– Ак мәчет бизәлеше белән матур. Пәйгамбәребез мәчетенең эчке һәм тышкы күренешләре.

– Кәгъбәтулла җирнең үзәге.

Әлхәрам мәчете иң зур мәчет. Анда ел саен миллионлаган кеше хаҗ кыла. Бу – Кәгъбәтулла. Әлхәрам мәчетенең уртасында урнашкан кара төстә, алтын хәрефләр белән сүрәләр язылган. Бөтен ил мөселманнары шушы Кәгъбәтуллага карап намаз укый.

Ел саен бу Мәккә шәһәрендә миллионлаган кеше хаҗ кыла. Хаҗ кылуны беләбез шулай бит, ул мөселманнарның мөмкинлеге булса, үтәлергә тиешле шартлары. Быел Татарстаннан бик күп кеше хаҗ кылды. Бу өстәлдә хаҗилар Гарәбстаннан алып кайткан күрсәтмәлекләр. (Таш, кара тмин, фотолар күрсәтелә.)

Аларда дин дәүләт югарылыгында, ә бездә, дин дәүләттән аерылган, ләкин без аерылган диеп күпме генә кабатласак та, ул безнең җәмгыятьтән аерылмаган. Ул безнең күңелебездә. Хәзер инде дингә карашлар яхшы.

Без дә онытмыйбыз, өйрәнәбез, белергә тырышабыз. Яле, Айтуган, берәр сүрә укы.

*(Айтуган «Вәлгаср» сүрәсен укый.)*

– Бу сүрә нинди мәгънәгә ия?

*– Монда сабыр булырга, һәр эшне уйлап эшләргә кирәклек турында әйтелә.*

Әйе, укучылар, сәяхәт вакытларында бу дога безне сабыр булырга өйрәтә. Ләкин болар белән беррәттән без тырышлык, сабырлык һ.б. сыйфатларны да онытмаска тиешбез.Сәяхәтебезне йомгаклап, кире илебезгә кайтыйк. Безне ерак илләрдә озатып йөрүче әхлаклылык сыйфатларын хәзер сезгә өләшәм, ул алдагы көннәрегездә һәрчак яныгызда булсын.

Бу матур шар төркеме кебек сездә дә әхлаклылык сыйфатлары күп булсын. (Гарәпчә әхлаклылык сыйфатлары әйтелә, ә укучылар татарчасын әйтеп үзләренә алалар.)

*(Мүҗтәхидәтүн – тырыш, дәртле; таиибүн – яхшы, күркәм; сабирун – сабыр; әдәбин – әдәпле; җәмиләтүн – матур.)*

Дәрес тәмам.

Әдәбият


1. Харисова Г.А. Гарәп теле әлифбасы.Алабуга, 2003.
2. Харисова Г.А. Үсемлекләр дөньясы. Алабуга, 2004.
3. Рәхимов М. Гарәп теле дәресләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994.
4. Арабско-русский словарь.
5. Көч һәм рух тамырлары. (Әдәплелек дәресләре) хрестоматия. Казан. «Мәгариф» нәшр., 2000. 1, 2 кисәк.
6. Балаларга үгет-нәсыйхәт. Казан: «Дом печати» нәшр., 2002.
7. Фәхреддин Р. Нәсыйхәт. (Әхлак гыйлеменнән.) Казан: «Мәгариф» нәшр., 2005.



***Хөсәенова Венера,***
*Балтач районы БӨБ «Мәктәптән тыш*
*эшләр үзәге» мөгаллимәсе*


## БАЛ КОРТЛАРЫ – ЭШЧӘН ХАЛЫК

(Кече яштәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

– бал кортлары тормышы белән таныштыру;
– кеше тормышында хезмәтнен мөһимлеген раслау;
– хезмәт төбе – хөрмәт икәнлеген исбатлау;
– балада уку хезмәтенә уңай халәт тәрбияләү;
– гаиләләр белән танышуны, аларны өйрәнүне дәвам итү.

Материал: Балачак әдипләре. «Балалар әдәбияты» хрестоматия. «Тәрбиядән яраладыр тәрбия», Китаплар күргәзмәсе. «Божественные чудеса». Балтач энциклопедиясе. Габдулла Тукай шигырьләре.

*Җиһазлау:* проектор, компьютер, Г. Тукай рәсеме.

*Шөгыль барышы:*

***1. Психологик уңай халәт тудыру.***

– Әссәләмегаләйкем!

– Вәгаләйкемәссәләм!

– Ягез әле, укучылар, без дә кул биреп күрешик әле. Күрешү ул – җылы сүз, кешенең хәлен, кәефен, тазалыгын сорашу, аңа сәламәтлек теләү. Ә кул биреп күрешү – кулынның, күңелеңнең җылысын иптәшен белән бүлешү ул. Ягез, тагын бер кат кул биреп күрешик әле. Адилә, синең җылың миңа күчсен, минем җылым сиңа күчсен. Дуслар булыйк.

Биссмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмделилләһи раббил галәмин.

Хәерле көн, кадерле балалар! Мөхтәрәм җәмәгать! Барчабызга да Аллаһы Тәгалә хәерле эш көннәре, файдалы гыйлем насыйп итсен. Бүгенге дәресебездә Казаннан килгән кунаклар, район мәктәпләренең әхлак укытучылары, авылыбызның өлкәннәре катнаша. Мөселманнар җыелган җирдә эш Коръән укудан башлана. Бездә дәресебезне Коръән укып башлыйк.

– Укучылар, күзегезне йомыгыз әле. Менә табигать кышкы йокыдан уянды. Бар тереклек җанланды. Тиздән сез җәйге табигать кочагына чыгарсыз. Бөтен тирә-якта кыр чәчәкләре. Чикерткәләр җыры, сандугачлар сайравы ишетелә. Ниндидер сайрар кош тал-тирәкләргә серен сөйли, ахырысы. Елмаеп чыккан кояшның нурларын без дә үзебезгә күчерик әле, ул нурларны бер-беребезгә бүләк итик. Әнә ерак та түгел, умарта оялары күренә. Бал кортларының гөжләвен туктап тыңлап торабыз.

***2. Уку мәсьәләсен кую.***

Кадерле балалар, сез, бал кортлары дигән бөҗәкләр белән яхшы таныш, шулай бит? Сез аларны телевизордан, мультфильмнардан карап беләсез. Кайберләрегез урманга, болынга, кырларга чыкканда, авылга кайткач умарта кортларының ничек итеп чәчәктән бал җыйганын күзәткәне бардыр. Шулай да, бал кортларының тормышыннан бар нәрсәне дә белеп бетермисез әле сез. Менә Фидаил җәй көне урманга барган. Көн бик матур, кояшлы, җылы булган. Фидаил дуслары белән урманда рәхәтләнеп куышлы уйнаган, йөгергән, шатланган. Тагын ул урманда яңа дус тапкан. Ул үзе бәп-бәләкәй икән, әмма бик-бик акыллы, ди. Фидаил аның белән җан дусларга әйләнгән. Ул аны беркайчан да онытмас, әйе бит, чөнки ул дустыннан җирдәге тормыш турында бик күп кызыклы нәрсәләр белгән. (Малай белән бал корты сөйләшә.)

Абдулла Алишның «Нечкәбил», «Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык» әкиятләрен искә төшерү.

Бал корты рәсеме (сөйлим).

«Балалар, Фидаил белән бал кортының сөйләшүеннән сез күп нәрсәләр белдегез. Шуларга өстәп мин бал кортлары турында бераз

сөйләп китим. Бал кортларын «канатлы хезмәткәрләр» дип атыйлар. Аның алты аягы була. Бу аяклар аңа йөрер өчен генә түгел, төрле эшләр башкару өчен дә кирәк, аяклары белән никтар җыя, кәрәз ясый, үзенең тәнен чистарта. Чәчәк серкәсе җыю өчен – алгы аякларында кечкенә генә каурыйлар, ә серкәне җыеп бару өчен арткы аякларында кәрзинкәләр бар. Кортларның 4 канаты була. Алар шуның белән бик яхшы очалар. Умарта чәчәк серкәсенә бер минутка бер километр тизлек белән оча. Кортлар бик яхшы күрәләр. Аларда 5 күз була. Кортларның бөтен тәне йон белән капланган. Мыеклары хәрәкәтләнүчән, сизгер, тиз ис сизүчән. Шушы төгәл приборлары белән яңгыр киләсен алдан белеп, өйләренә кайталар.

Бал кортлары балалар бакчасына да, мәктәпкә дә йөрмиләр, укый-яза да белмиләр, ә үзләре күпме төрле һөнәрләргә өйрәнгәннәр. Аларны бу һөнәрләргә кем өйрәтә икән соң, балалар?

Беләсезме, балалар, бу һөнәрләргә умарта кортларын, аларны гына түгел, кырмыскаларны, үрмәкүчләрне, кошларны, балыкларны, куяннарны, бүреләрне, төлкеләрне Аллаһы Тәгалә өйрәтә. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте киң: ул бал кортларына оя ясарга, кәрәз корырга, чәчәкләрдән бал җыярга һәм кешеләргә бал ясарга куша, аларны шушы һөнәрләргә өйрәтә. Бал кешеләргә дару өчен дә кирәк. Әгәр без чирләсәк, баллы чәй эчеп дәваланабыз. Тир белән чир-сырхаулар чыга. Без яратып ашый торган балны ясау өчен, бал кортларына бик күп тырышырга, бик күп очарга туры килә. Ярты кг ширбәт балы җыю өчен 900 бал кортына көн буена оядан чәчәккә, чәчәктән ояга очарга туры килә. 450 г чиста бал алу өчен якынча мең бал корты 10 млн чәчәктән нектар җыя.

Күрәсезме, балалар, эшчән, тырыш бал кортлары безгә никадәр файда китерәләр. Ә хәзер мин сезгә Коръән дигән изге китаптан «Бал кортлары» сүрәсеннән 68–69 нчы аятьләрне укып китәм. Раббың бал кортына әйтте: «Тауларда, кыяларда, агач куышларында вә кешеләр корган каралты-кураларда үзеңә оялар – умарталар яса. Аннан соң җимешләрнең һәрбереннән авыз ит, Аллаһ күрсәткән юллар буйлап оч», – диде. Аларның эченнән кешеләр өчен шифа булырлык төрле төстәге ширбәт (бал) чыга.Бу эшләрдә уйлый белгәннәр өчен бөек гыйбрәтләр – дәлилләр бардыр.

Афзал «Бал кортлары» сүрәсенең 125–128 нче аятьләрен укый.

Аллаһ тугры юлдан язганнарны бик яхшы белеп тора, Ул тугры юлга басканнарны да бик яхшы белә. Аллаһ (гөнаһ кылудан) курыкканнар һәм игелек кылганнар янында.

Бал кортлары арасында нинди татулык, төгәллек, тырышлык. Адәм баласы меңәрләгән елларда да бал кортларын алыштырырлык фабрика уйлап таба алмаган, алмас та. Тирә-ягыбызда Аллаһы Тәгаләнең андый камил фабрикалары бик күп, аларны күрә белергә генә кирәк. Раббыбыз һәрбер үсемлекне, һәрбер җан иясен тигезлек үлчәве белән, үз вазифасы белән яралткан. Иң камил итеп адәм баласы яралтылган.

– Аллаһы Тәгалә сиңа нәрсәләр биргән?

– Акыл биргән – яхшылыкны яманнан аерырга.

– Аяклар биргән – барасы җиреңә барып җитәргә.

– Күзләр биргән – матурлыкны күрергә.

– Ике колак биргән – бар нәрсәне ишетеп, белеп торырга.

– Куллар биргән – хәләл көчен белән теләгән нәрсәләрне эшләргә.

***3. Г. Тукай «Һәркем эштә» хикәясен уку.***

– Борһанетдинга ат нәрсә дип җавап кайтарды?

– Умарта корты, кош ничек дип җавап бирделәр?

– Нәрсә соң ул эш яки хезмәт?

***4. Г. Тукай «Таян Аллага» шигыре.***

«Бәхетле бала», «Эш» шигырьләрен уку.

Тырышып эшләсәң, ялкауланмасаң, син бәхетеңне табарсың. Әйе, балалар, бәхет – хезмәттә, тырышып эшләүдә, укуда.

Без барыбыз да тырыш укучы булырга хыялланабыз.Әгәр дә балалар, сез зур үскәч тә, һәр йөргән җирегездә тәүфыйклы, кешелекле, тырыш, хезмәт сөючән, шәфкатьле булсагыз, сездән әти-әниләрегезгә, мәктәпкә яхшы, шатлыклы хәбәрләр генә килеп торса, без тагын да бәхетлерәк булырбыз.

***Нәтиҗә ясау.***

Ислам диненең 5 терәген кабатлап узыйк.

Иман китерү (Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһ юк, Мөхәммәд пәйгамбәр аның илчесе).

Намаз уку.

Руза.

Зәкят түләү.

Хаҗ кылу (мөмкинлегең булса).

***Өйгә эш:*** Бүгенге дәрес турында сөйләшүне өйләрдә дәвам итегез. Барчагызга да Аллаһың рәхмәте булсын.

***Вагизова Әлфия,***
*Мамадыш шәһәре мәчете*
*каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## ШӘФКАТЬЛЕЛЕК БИЗИ КЕШЕНЕ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Дәреснең максаты һәм бурычлары:*

1. Кешелеклелек, шәфкатьлелек сыйфатлары тәрбияләү.

2. Шәфкатьле кешеләрнең эшләре белән танышу, аларны үзеңә өлге итеп алу.

3. Киләчәктә үз балаларын шәфкатьле итеп тәрбияләү юнәлешен бирү.

4. Укучыларда кешелеклелек, шәфкатьлелек, ярдәмчеллек, изгелек сыйфатлары тәрбияләү.

*Җиһаз:* видеороликлар – «Социаль эксперимент», «Бар әле ул шәфкатьлелек!» («Восстановление веры в человечность»)

*Эпиграф:* «Кем дә кем тузан бөртеге генә изгелек кылса, ул күренәчәк. Кем дә кем тузан бөртеге генә начарлык кылса, ул күренәчәк».

*Дәрес барышы:*

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

***1. Видеоролик карау – «Шәфкатьлелек бар ул!» («Восстановление веры в человечность»)***

**–** Сезнең игътибарыгызга видеоролик тәкъдим итәбез – ул бүгенге дәреснең темасын ачыкларга ярдәм итәр.

**Эчтәлек:** авыр хәлдә калган кешеләргә, хайваннарга ярдәм белән ашыгып килгән изге күңелле коткаручылар турында.

**II. Дәреснең темасын ачыклау.** Шәфкатьлелек бизи кешене.

– Димәк, бүген без нинди темага сөйләшәчәкбез?

– Шәфкатьлелек турында.

– Видеоролик сездә нинди хисләр уятты? Фикерегезне исбатлагыз.

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

***1. Яңа сүзләр:***

*Шәфкатьлелек, миһербанлылык, мәрхәмәтлелек, волонтерлык. (кешеләргә бушка ярдәм итү.)*

– Нәрсә ул шәфкать?

Җаваплар:

– Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә яхшылык сүзенең түбәндәге синонимнары бирелгән: мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек, кешелеклелек, шәфкатьлелек, ихтирамлылык, игелеклелек.

– Минемчә, «шәфкать» сүзе – кызгану, аяу хисе, мәрхәмәтле, киң күңелле, рәхимле, ярдәмчел, игелекле булуны аңлата.

***2. Шәфкатьлелекнең төрләре.***

– Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз. Хикәягә исем кушыгыз.

### *Бер стакан сөт*

*Беркөнне ярлы гаиләдән булган малай, мәктәптә укыган өчен түләргә акча булсын, дип ишектән-ишеккә йөреп, әйберләр сатып йөргән. Көн бик салкын, яңгырлы – вак-төяк товарын да алучы юк. Тамагы ачып кесәсен актарып карый – анда тамак ялгарлык акча юк иде. «Менә бу йорт хуҗасыннан ашарга сорап карармын», – дип уйлый, ләкин ишекне бик матур яшь кыз ачкач, малай югалып кала һәм бер стакан су гына сорый. Сөенечкә каршы, аңа бер стакан җылы сөт алып чыгып бирәләр. Аның тәмлелеген әйтеп бетерә торган түгел иде! «Күпме түләргә тиеш мин сезгә?», – дигән сорауга, – «Бер тиен дә түгел. Әнием эшләгән яхшылык өчен түләүне беркайчан да алмаска өйрәтте...»*

*Чын күңелдән булган рәхмәтен белдереп, малай үзенә хәл кергәнен сизеп, бар кешеләргә, дөнья Хуҗасына ышанычы ныгып китте.*

*Күпмедер еллар үткәч, Американың бер зур шәһәрнең хастаханәсенә каты авыру яшь хатынны алып киләләр. Бик танылган, операцияләр өчен, гадәттә, кыйммәтле түләү хакын сораган доктор Говард Келли аның кайсы шәһәрдән килгәнен ишеткәч, авыру палатасына керә һәм үлем хәлендә булган кешедә теге яшь кызны таный.*

*Дәвалауга бөтен көчен куеп, доктор аны үлемнән коткара. Операция өчен түләргә вакыт җиткәч, авыру хатын бик борчыла: калган бөтен гомере буена эшләгән бар акчасы шушы дәва өчен түләүгә китәчәк.*

*– Күпме түләргә тиеш мин сезгә? – дип сорый.*

*– Бер тиен дә түгел.*

*– Дәвалану хакын әйтегез!*

*– Бер стакан сөт...*

*– Барысы да аңлашылды... Күзләренә яшь тулган хатын: «Я, Раббым, чиксез рәхмәт Сиңа, Синең мине яратуың шәфкатьле кешеләр йөрәкләре һәм куллары аркылы миңа җиткерелде!» – дип елады...*

Бу танылган Америка докторы Говард Келли белән чыннан да булган бер хәл турында хикәя иде (1855– 1943 еллар).

– Хикәягә исем кушыгыз.

– Бер стакан сөт. (Яхшылык һәрвакыт кире кайта.)

– Хикәя геройларын нинди уртак кеше сыйфаты берләштерә? (Шәфкатьлелек.)

Укытучы:

– Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелек, тәүфыйк, миһербан, игелек, изгелек, ярдәм, киң күңеллелек, кадер-хөрмәт, наз, игътибар, юмартлык, сабырлык, итагатьлелек hам башка матур төшенчәләрне дә үз эченә алучы, бик киң мәгънәле сүз ул.

– Димәк, без игелекле эшләрне аеруча күп башкарырга, туганнарыбыз, якыннарыбыз белән тагын да күбрәк аралашырга, бер-беребезгә игътибарлы, ихтирамлы, түзем, миһербанлы булырга, ятим-мохтаҗларга җан җылысын, матди ярдәмне кызганмаска, изге гамәлләр башкарганда юмартлык күрсәтергә тиешбез.

***3. «Шәфкатьлелекне кемгә күрсәтергә була?» дигән сорауга җавап бирү.***

Җаваплар:

– Шәфкатьле булу – көчсез әби-бабайларга, күршеләргә, өлкәннәргә, хезмәт һәм сугыш ветераннарына, кечкенә балаларга, хайваннарга булышу.

– «Яхшылык җирдә ятмый» дигән борынгылар. Чынлап та, яхшылык ул безнең изге эшләребез һәм уйларыбыз, кешеләрнең бер-беренә карата эчкерсез һәм рәхимле мөнәсәбәтләре.

Укытучы:

– Яхшылык беркайчан да онытылмый. Хәзерге заманда бар дөньяны материаль байлыкка омтылу яулап алган, күп кешеләрнең уйлары, эшләре белән акча идарә итә. Ә яхшылык, игелеклек, шәфкатьлелек сыйфатларына урын юк кебек. Әлбәттә, акча белән дә мохтаҗ булган кешеләргә ярдәм итәргә була, әмма чын күңелдән ярдәм күрсәтәсе килгән кешедә әллә ни зур акча суммалары, гадәттә, булмый.

**4. *Төркемнәрдә эшләү. «Игелекле эшнең иртәсе-киче юк»***

**1 бирем.** Уен: «Мин башлыйм, син дәвам ит».

Шәфкатьлелек сүзләре белән бәйләнешле мәкальләр белән танышу (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә.)

**–** Шәфкатьлелек, яхшылык кебек күркәм сыйфатлар татар халкында иң югары бәяләнгән. Бу изге гамәлләр турында мәкаль һәм

әйтемнәр иҗат ителеп, алар еллар дәвамында безне рухи яктан баета, әдәплелеккә өйрәтә.

- Ашның мае бар, сүзнең... *җае бар.*
- Яхшы гадәт адәм итәр, яман гадәт... *әрәм итәр.*
- Кеше холкын күзәт – үзеңнекен... *төзәт.*
- Матурлык эзләмә, яхшылык... *эзлә.*
- Кешегә игелек итсәң – үзеңә... *булышырлар.*
- Изгелек итсәң яшер, изгелек күрсәң... *фаш ит.*
- Матурлык – бер көнлек, игелек –... *мәңгелек.*
- Изгелек эшен озакка... *сузарга ярамый.*
- Игелекле эшнең иртәсе-... *киче юк.*
- Изгелек итә алмасаң,... *яманлык кылма.*
- Яманлык артыннан йөргән –... *изгелек тапмас.*
- Яхшылык җирдә... *ятмый.*
- Җылы сүз – җан... *азыгы.*
- Яхшы булсаң, даның чыгар, яман булсаң,... *җаның чыгар.*
- Яхшылык кылган – аш җыйган, яманлык кылган... *таш җыйган.*
- Яхшылык эшлә дә... *суга сал.*
- Изгелек итә алмасаң, яманлык... *кылма.*

– Кайсы мәкаль сезгә күбрәк ошый һәм ни өчен? Фикерегезне исбатлагыз.

**2 бирем. Ситуациягә бәя бирү.**

– Хикәяне тыңлагыз. Аның төп фикеренә туры килә торган исем кушыгыз:

*Бу песи башкалардан ким түгел!*

*«Мәче балаларын сатам», – дигән белдерүне күргәч, Рөстәм кибеткә керде, сатучы абый белән исәнләште һәм кыймыйча гына хакын белеште. «30 сумнан алып, 50 сумга хәтле» – диелгәч, кесәсендә 2 сум гына булганын күрде, читенсенде һәм песи балаларына күз салырга гына рөхсәт сорады.*

*Сатучы елмайды, песиләрне тартмадан алып күрсәтте. Алар тарала башладылар, тик берсе ни өчендер башкалардан бик артта калды. Аягын да өстерәбрәк атлаган шикелле иде. «Бу песигә ни булган?» – дигән сорауга, – «Аягы тумыштан гарип», – дигән җавап ишетте. Рөстәмнең борчылуы йөзенә чыкты:*

*– Нәкъ бу мәче баласын алыр идем мин.*

*– Бу бит гарип мәче! Нәрсәгә ул сиңа? Инде телисең икән – бушлай бирәм.*

*– Юк, бушлай алмыйм. Бу песи башкалардан ким түгел! Тулы хакын түләрмен аның өчен.*

*Сатучының йөрәге ни өчендер әрни башлады:*

*– Улым, син аңлап кына бетермисең: бу мескен песи беркайчан да йөгерә, сикерә, уйный алмас.*

*Рөстәм чалбарының балагын кайтарды һәм сатучы хәйран калып, аның аягының зәгыйфь, гарип, тимерләр белән ныгытылган икәнен күрде...*

*– Мин дә бекайчан да йөгерә, сикерә алмаячакмын. Бу песигә дә аның авыр хәлен аңлый торган, аңа ярдәм итә торган кеше кирәк.*

*Сатучы абый иреннәрен тешләп, яшь белән тулган күзен яшереп, Рөстәмгә елмайды:*

*– Улым, дөньядагы бөтен песи хуҗаларының синең шикелле олы йөрәкле булуларын, Аллаһтан сораячакмын...*

– Хикәянең төп фикеренә туры килә торган исем кушыгыз.

– Ни өчен бу песинең хәлен Рөстәм генә аңлаган?

– Кешенең күңеле нинди икәнлеген, аның хайваннарга мөнәсәбәтендә ачык күреп була.

**3 бирем.** ***Видеоролик «Социаль эксперимент» (Америка).***

***Эчтәлеге:***

– Тамагым ач дип, урамда ризык сораган журналистка үзе ашаган пиццаның кисәген бер бомж гына бирә. Аңа да бу пиццаны хәер итеп, шул журналистның видео төшерүче иптәшләре алдан биргән булганнар булса кирәк. Башкалары «үземнең дә ашыйсы килә», – дип җавап бирәләр.

– Ни өчен болай? Ник без мохтаҗларны күрә белмибез? Ни өчен, күрсәк тә, аларны күрмәгәнгә салышабыз? Нәрсә булды безгә?!

– Видеороликта шәфкатьлелекнең киресе күрсәтелде.

– Анда кешеләргә хас булган нинди сыйфатлар сурәтләнә?

– Миһербансызлык, шәфкатьсезлек, ваемсызлык, гамьсезлек, мәрхәмәтсезлек.

– Күп очракта кеше хәленә үзе авырлыклар кичергән һәм шул авыр вакытта башкалар ярдәменең тәмен татып караучы кеше генә керә белә,

– Юкка түгелдер, «Иң зур сынау – муллык белән сыналу», – дип әйтелә. Рәхәттә яшәгән кеше үзен генә уйлый, мескеннәрдә аның йомышы юк.

**4 нче бирем.** ***Безнең киңәшләр.***

– Үзеңдә шәфкатьлелекне тәрбиялисе килгән кеше нинди киңәшләр бирер идегез? (Балалар фикер алышып, үз группаның киңәшләрен тәгъдим итәләр.)

• Кешеләрдә барыннан да элек, уңай якларны табарга өйрәнегез.

• Кешеләргә игътибарлы булыгыз. Аларга ярдәм кирәк түгел микән, уйлый белегез.

• Файда килүне өмет итмичә, мохтаҗларга ярдәм итегез.

• Табигатькә, хайваннарга карата мәрхәмәтле булыгыз.

• Кем бер хәерле, яхшы эш эшләсә, ул кешегә ун кат савап булыр.

• Изгелек эшләсәгез – ул, һичшиксез, кире кайтачак. Начарлык эшләсәгез – ул да кире кайтачак.

• Үзегездә булган мәрхәмәтлек орлыкларны кешеләрдән яшерегез, үз игелелегез белән мактанмагыз.

Укытучы:

– Барыбызга да истә тотырга кирәк: халык «Яхшы сүз – җан азыгы», дип бердә юкка әйтмәгән. Якын кешеңнең рухи яктан күңелен күтәрү, авыр минутларда аның хәлен аңларга тырышу да бик мөһим. Җылы, яхшы сүз материаль ярдәмгә караганда да кирәгрәк булырга мөмкин, чөнки байлык ул була да бетә, ә кылган яхшы эшләр күңелдә, йөрәктә кала һәм бер булса да әйләнеп кайтачаклар.

**5. Танылган шәхесләр сүзе.**

– Танылган шәхесләр сүзен ничек аңлыйсыз?

1. Һәр кеше белән гүзәл тереклек итәргә, һәркемгә мәрхәмәтле булырга, һәрнәрсәнең гүзәл тарафын алга алырга... (Риза Фәхреддин)

2. Яхшылык – начарлык эшләмәү генә түгел, ә начарлык эшләргә теләк булмау. (Демокрит)

3. Яхшылыкның көче беткәндә, ул яманлыкка әйләнә. (Оскар Уайльд)

**6. Хәдисләр.**

– Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в) әйтә:

• ***Үзеңә нәрсә теләсәң, башкаларга да шуны телә.***

• ***Игелекле эшләрне тавышсыз гына башкарыгыз.***

• ***Һәр изгелек – садака.***

**7. Изге Коръән китабыннан**

– Изге Коръән китабында шәфкатьлелек, изгелек турында болай дип язылган:

• ***«Яхшылык эшләргә ашыгыгыз»***. /Коръән, 78/

• «***Кем дә кем тузан бөртеге генә изгелек кылса, ул күренәчәк. Кем дә кем тузан бөртеге генә начарлык кылса, ул күренәчәк»*** / Коръән, 99: 6-8 /.

– Ни өчен кеше яхшылыкны кылуда ашыгырга тиеш?

– Кеше гомере буена мөмкин кадәр күбрәк изгелекләр эшләргә тиеш, алар барысы да исәпләнәләр һәм килер бер көн – яхшы эшләребезнең күп булуы безгә бик-бик кирәк булачак.

«Кем дә кем яхшылык эшләсә, моның файдасы аның үзенә була, ә кем дә кем начарлык эшләсә, моның зарары үзенә булачак. Синең Раббың колларына әз генә дә гаделсезлек кылмый» /Фуссыйләт – 4 /.

– Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

– Аллаһы Тәгалә Гадел Зат булганга күрә, бөтен кешегә дә тиешле җәзасын яки бу дөньяда, яки ахирәт дөньясында бирә. Кешенең башкаларга кылган начарлыклары үзенә кире әйләнеп кайтуы турында хәбәр итә.

– Монда Аллаһы Тәгаләнең 99 гүзәл исеменең кайсысы бик ачык күренә?

– Аллаһның гаделлеге. (Әл Гадлү)

**IV. Рефлексия (Йомгаклау).**

– Дәреснең темасын искә төшерегез.

– Шәфкатьлелек темасына карата нинди гыйбрәтләр алдыгыз? ***(Әгәр итсәң бирәүгә син изге эш, үзеңә дә килер шундый ук өлеш. Изгелек итсәң яшер, изгелек күрсәң фаш ит.)***

– Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?

– Нәрсә ул яхшылык, һәм шәфкатьлелек? Бу сүзләрнең мәгънәсе нидә?

Укытучы:

– Уйлап карасак, шәфкатьлелек – бер-береңә ярдәмгә килергә әзер булу, якын кешең өчен үзеңне, үзеңнең хис-тойгыларыңны корбанга китерүдер, гомумән, чын күңелдән эчкерсез яхшылык кылу. Безнең чынбарлыкта бар кешедә дә бу күңел сыйфаты, кызганычка каршы, юк. Яхшылык кылган кешеләр Аллаһка ышанмасаларда, шәфкатьле һәм изгелекле булып кала аладыр, минемчә. Ләкин чын күңеле белән Аллаһы Тәгаләгә ышанган кеше шәфкатьсез була алмый, чөнки Раббыбыз бер-беребезгә яхшылык кылырга кушкан.

– Үзегездә булган мәрхәмәтлек орлыкларын кешеләрдән яшерегез, үз игелегегез белән мактанмагыз.

– Тактада язылган эпиграфны укыгыз: «***Кем дә кем тузан бөртеге генә изгелек кылса, ул күренәчәк. Кем дә кем тузан бөртеге генә начарлык кылса, ул күренәчәк».***

– Бу сүзләрне үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчан да онытмыйк, чөнки һәрбер тузан бөртеге хәтле изгелегебез өчен дә, һәрбер тузан бөртеге хәтле яманлыгыбыз өчен дә Аллаһы Тәгалә каршысында җавап бирәчәкбез. Шәфкатьлелек кешене бизи һәм бәхетле итә.

**VI. Өйгә эш:**

Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. «Мин белгән шәфкатьле кеше» дигән темага җавап әзерләп килергә.

2. Шәфкатьлелек турында киңәшләрне истә калдырырга.

***Нургалиева Лилия,***
*Балтач районы Яңгул гомуми урта белем мәктәбенең*
*«Тәрбияле бала» берләшмәсе җитәкчесе*

## АЧУ – АГУ, ЙОТСАҢ – ДАРУ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1. Ачуның кешеләрне дошманлаштыруда бер чара икәнлеген исбат итү.

2. Үзеңә нәрсә теләсәң башкаларга да шуны теләргә кирәклеген төшендерү.

3. Сабырлык, ихтыяр көче, игътибарлылык тәрбияләү.

*Материал:*

**1.** Казыйханов В. «Иман дәресләре».

**2. «**Көч һәм рух тамырлары».

**3.** «Тәрбиядән яраладыр тәрбия».

**4.** Җәлил хәзрәт Фазлыев. «Гомерләр заяга узмасын».

**5.** «Дин вә йола» газеты, ноябрь, 2014 ел.

**6.** Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр

7. «Бәхетлеләр календаре» 2013. (206, 214 бит), 2014 (168 бит).

*Җиһазлау:* китап күргәзмәсе; видеопроектор, презентация, карточкалар.

*Дәрес барышы:*

**I. Актуальләштерү.**

Сәламләү.

Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Һәр барчагызга Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын.

Хәерле көн, укучылар! Менә тагын яңа көн туды. Әти-әниләребезнең, туганнарыбызның, сыйныфташларыбызның исән-сау булуына, бу мәктәптә белем алуыбызга тагын бер кат сөендек. Әнә шундый сөенеч-шатлыклар белән дәресебезне башлыйбыз. Әйдәгез әле, бер-беребезгә елмаеп хәерле көн телик. Ә һәрвакытта да кешеләр бер-берләренә шулай елмаеп, матур итеп карыйлармы соң? *(Слайд.)*

– Кайчагында кешеләр ачуланыша, үпкәли, елый, кычкырыша.

– Һәрвакытта да бөтен нәрсә дә гел матур гына булып бетми шул.

Ә сез, үзегез гел елмаеп, көлеп кенә торасызмы яки ачуланганыгыз бармы? Кемгә һәм ни өчен ачуланганыгызны дәфтәрегезгә языгыз әле. (*Дәфтәрләрдә эш.*) Ә хәзер әйтегез, ачу кайчан чыга? (Укучылар әйткәне тактага языла.)

– Тагын нинди сәбәпләре калды икән? (Башта укучылар җавабы)

*Слайд.*

– Ачу чыгуның сәбәпләре бик күп: мактанганда, тәкәбберләнгәндә, кешедән көлгәндә һәм аны гаепләгәндә, артык шаярганда, кеше фикере белән исәпләшмәгәндә, үзенә кагылмаган эшкә тыгылганда, шулай ук артык байлыкка, дәрәҗәгә омтылганда һ.б.

– Сезнең ачуыгыз чыгуга кем гаепле дип уйлыйсыз? (Җавап.)

– Сез гаепле булмагач, теге кешенең гаебе өчен сез ачуланырга, кәефегезне бетерергә кирәкме соң? (Җавап.)

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

Рәсүлебезгә бер кеше килеп: «Миңа бер киңәш бир», – ди. Рәсүлебез аңа: «Ачуланма», дип киңәш бирә.Теге кеше кабат-кабат тагын киңәш сораса да, Рәсүлебез аңа: «Ачуланма» дигән киңәшен бирүен дәвам итә. Мондый очраклар, бәлки, берничә булгандыр һәм шундый сораулар белән бик күп кеше мөрәҗәгать иткәндер.

– Ни өчен Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер үк сүзне кабатлаган? Нинди вакытта бер үк сүзне кабатлыйлар?

– Башта теге кеше «Ачуланма» сүзенең асылына төшенмәгән булса кирәк, шуңа күрә ул аны берничә кат кабатлый. Күрәсең, теге кеше бу сүзне җиңелгә санап, тагын да мөһимрәк киңәш көткән. Соңрак аңлаган: ачу бөтен яманлыкны үзенә туплый икән.

– Димәк, бүген дәрестә сүз нәрсә турында барачак?

– Ачу, ачу сакламау турында.

– Бүгенге тема «Ачу – агу, йотсаң – дару». *(Слайд. )(Дәфтәргә язу.)*

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

***1 бирем.***

– Нәрсә ул ачу? (Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән, укучылар!)

– Бик тирән нәфрәтләнү хисе, бик нык ярсу тойгысы. Ризасызлык, үпкәләү хисе, эчтәге үпкә, нөктә. *Мәсәлән: Беткә ачу итеп, тунны утка якмыйлар. Мәкаль.*

– «Ачулану» төшенчәсен ничек аңлыйсыз? (Аңлатмалы сүзлектә.)

– Берәр кешегә яки нәрсәгә дә ачу килү, кызып китү, үпкәләү, әрләү, орышу.

***2 бирем.* Слайд (сурәт).**

– Карагыз әле, бу сурәт сезгә ошыймы?

– Әйтегез әле, ни өчен кешеләр ачулары чыкканда бер-берсенә кычкыралар?(*Гыйбрәтле хикәя тыңлау.*)

– Чөнки күңелгә ачу кергәч тынычлык югала, – дигән бер укучы.

– Ә ни өчен кычкырырга соң? Югыйсә, янында басып торган кеше син әкрен генә әйтсәң дә ишетәчәк бит, – ди укытучы.

Укучылар уйга кала. Җавапның төрлесен әйтеп карыйлар, әмма укытучы аларның берсен дә дөрес дип тапмый. Ниһаять, ул үз соравына үзе үк җавап биреп:

Кешеләр бер-берсеннән риза булмаганда һәм талашканда аларның йөрәкләре ерагая. Шушы «ераклык»ны каплар яки бер-берсен ишетер өчен кычкыралар да инде. Катырак ачуланышкан саен, катырак кычкыралар, – ди һәм балаларның игътибар белән тыңлавын күреп болай дип дәвам итә (Мөбәрәк зат Әбү Мөслимнән):

– Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне яратканда, иң әүвәл тәненә акыл куйды.Шулай итеп, Адәм акыллы булды, соңрак ачуны яратты, аңа да Адәмнең гәүдәсенә керергә әмер итте. Шулвакыт ачу: «Мин Адәмнең гәүдәсенә керә алмам, чөнки анда акыл бар. Акыл белән ачу бергә сыеша алмабыз», – дигән. Шулчак Раббыбыз боерды: «Әй, ачу! Син Адәмнең гәүдәсенә керергә тырыш, шунда юнәл. Акыл синең килүеңне күрүгә чыгып китәр». Әгәр ачу килгәндә гәүдәдән акыл чыгып китә икән, димәк, ачулы кеше акылсыз, ягъни тиле булып кала.

**Слайд (сурәт).**

– Әлбәттә, күргәнегез бардыр, кешеләр бер-берсен яратканда ничек ягымлы итеп сөйләшәләр?! Алар кычкырмый бит, киресенчә, әкрен генә бер-берсен бүлдермичә генә гәп коралар. Чөнки йөрәкләре бер-берсенә бик тә якын була. Ә мәхәббәтләре көчәйгәндә, пышылдап дәшүне дә аңлыйлар. Хәтта пышылдау да кирәк булмый башлый. Алар бер-берсен

сүзсез дә аңлый башлый. Шуңа күрә ачуыгыз чыкканда, йөрәкләрегезгә ерагаерга юл куймагыз.

***3 бирем.*** **Слайд.**

– Ә хәзер әйтеп карагыз, ачуның кешеләргә нинди файдасы һәм нинди зыяннары бар? (Башта укучылар җавабы.)

– Ачулану, холыксыз бәндәләргә хас сыйфат. Юк-барга ачулану кешеләрнең, иң башлап, сәламәтлегенә зыян китерә: ачудан кешенең йөзе үзгәрә, күзе кызара, муен тамырлары кабара, куллары калтырый, кан басымы күтәрелеп, йөрәге авырта башлый. Кызулык белән, соңыннан үзенә дә оят булырлык сүзләр әйтә. Ачуланышу сәбәпле, туганнары, дуслары белән дошманлаша. Ачулы чагында, кеше үз-үзен белештермичә, нәрсәне дә булса ватарга, башкаларны кыйнарга, хәтта үтерергә мөмкин.

***4 бирем.***

– «Ачу – бөтен начар нәрсәнең ачкычы», – дигән әйтем бар. Безнең темабызда да «ачу – агу» диелгән. Шулай булгач ачудан котылырга кирәк. «Йотсаң – дару» дигәне нәрсәне аңлата икән?

«Ачу йоту» аңлатмалы сүзлектә нәрсә белдерә?

– Ачу йоту – ачу килгәндә аны кешегә белдермәү, кешегә сиздермәү.

– Димәк, ачу йоту – ачу чыгаручыга игътибар итмәү, үткәреп җибәрү, үч сакламау, оныту. Бу – җиңел эш дип уйлыйсызмы? (Укучылар җавабы.)

***5 бирем.***

– Гыйбрәтле хикәяләрне аңлатыгыз. (Төркемнәрдә эш, карточка белән.)

1) Ике дус, бергәләшеп сахрадан барган вакытта араларында бәхәс чыга. Аларның берсе ачуланып, икенчесенең битенә каты итеп суга.

Әмма дусты шундый ук җавап кайтармый. Бармаклары белән ком өстенә: «Бүген минем иң якын дустым миңа сукты», – дип язып куя. Шуннан соң алар юлларын дәвам итәләр. Каршыларына очраган бер чиста күлдә су коерга ниятлиләр. Һәм дустына сукканы бата башлый, тегесе аны коткара. Бата башлаганы яр буена чыккач, кулына бер тимер кисәге алып, яр буендагы ташка: «Бүген иң якын дустым, мине үлемнән коткарды», – дип язып куя. Әлеге язуны күргәч, дусты: «Син минем йөземә сукканнан соң, мин ком өстенә язган идем. Ә син, үлемнән котылгач, ташка язып куйдың. Ни өчен шулай эшләдең?» – дип сорады.

– Әгәр дә дусларның берсе икенчесен ачуландырса, ачуын комга язсын. Чөнки комга язылган язуларны җилләр юк итә. Әмма бер кеше дустын коткарса, таш өстенә язып куйсын. Аны бернинди җил дә, давыл да юк итә алмас, – дип җавап кайтарган дусты.

– Без бу хикәядән нәрсәне аңлыйбыз?

2) Бервакыт бер яшь егет, сабырлыгы һәм кешеләргә үпкә тотмавы белән аерылып торган бик тәкъва хәзрәткә мөрәҗәгать итеп:

– Йә, хәзрәт, сезнең сабырлыгыгыз шуның кадәр нык! Сезнең турында нинди генә сүзләр сөйләмәсеннәр, хәтта сезгә кычкырсалар да, барын да сабыр, тыныч кына уздырасыз. Берсенә дә үч сакламыйсыз, үпкәләмисез. Мин, тыштан сабыр итсәм дә, эчтән үпкә тотам. Миңа да, сезнең кебек сабыр булуны өйрәтсәгез иде, зинһар. Сабырлыгыгызның хикмәте, сере нидә? – дип сорый.

Хәзрәт, бераздан бу егеткә:

– Сине берәр кеше үпкәләтсә, син бәрәңге алып, бер ягына аның исемен яз, ә икенче ягына үзеңнекен. Җыелган бәрәңгеләрне үзең белән сумкаңа салып йөр, – дип җавап кайтара.

Бу егет, нәкъ хәзрәт кушканча эшли һәм күпмедер вакыт узганнан соң кире хәзрәт янына килә:

– Кара әле, хәзрәт, мин син кушканча эшләдем эшләвен.Әмма минем сумкам хәзер бәрәңгеләр белән тулды һәм сасый башлады. Хәзер урамнан барганда да кешеләр: «Нинди сасы кеше икән бу?» – дип борылып карап калалар! Син биргән нәсыйхәтнең хикмәтен бер дә аңламадым! – ди.

Хәзрәт, егеткә елмаеп карый һәм:

– И, кардәшем, син һаман аңламадыңмени? Һәрбер үпкәләүне, ачуны һаман күңелеңдә тотсаң, ул әнә шул бәрәңге кебек сасый башлый һәм кешенең күңеле каралып, ямьсезләнеп бетүе бар. Шуңа күрә дә беркемгә дә ачу тотмыйк! – дип сүзен тәмамлый.

– Бу хикәя безне нәрсәгә өйрәтә?

***6 бирем.***

Бервакыт Пәйгамбәребез (с.г.в.) кешеләрдән болай дип сораган: «Сезнең кайсыгыз, күбрәк кешене җиңүче санала?»

– Алар: «Кешеләр аны җиңә алмаучы», – дигәннәр.

– Моңа җавап итеп, Пәйгамбәр (с.г.в.) әйткән: «Андый кеше көчле түгел, ачуланган вакытта үзен тота белүче кеше көчле». Ни өчен?

(Башта укучылар җавабы, аннан үзем өстим.)

– Чөнки үзеңнең нәфесеңне: мин генә дөрес, миңа кирәк, мин шулай телим, дигәнне җиңү бик авыр.

***7 бирем.*** **Слайд**. Без телибезме, теләмибезме ачу бар. Кешеләрнең иң сабыры булган Пәйгамбәребез(с.г.в.) ачуны басуның кайбер ысулларын

да өйрәтеп калдырган. Бу хәдисләрнең эчтәлеген аңлатырга. (Аңлатма укучы җавабыннан соң.)

1) Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Чынлыкта, ачу – шайтаннан һәм шайтан уттан яратылган. Әгәр дә берәрегезне ачу биләп алса, тәһарәтләнсен», – дип әйткән. (Ачу ул – ут, ут – шайтаннан килә, ә ут судан курка. Моннан тыш, тәһарәт Аллаһы Тәгаләне искә алу белән бәйле булган гыйбадәтләрнең берсе, ул вакытта кеше күңелендә ачу утын кабызучы шайтан артка чигенә.)

2) «Әгәр сезнең берәрегез ачуланган вакытта басып торган булса, утырсын, утыргач та ачуы басылмаса, ятып торсын», дип әйтелә икенче хәдистә. (Басып торучы кеше утырып яки ятып торучы кешегә караганда, әлбәттә, үч алуга якынрак тора.)

3) Пәйгамбәр (с.г.в.) бервакыт: «Берәрегезнең ачуы килсә, эндәшмәсен», – дигән һәм өч тапкыр кабатлаган.

(Берәр кеше сүксә, рәнҗетсә, эндәшмәскә кирәк, чөнки җавап итеп, ачуын тагын да арттыра торган сүзләр ишетергә, яки үзе әйтергә теләмәгән һәм соңыннан үкенәчәк сүзләр әйтергә мөмкин. Ачуның асылы – ут, утка утын өстәмәсәң – сүнә.)

4) Рәсүлебез (с.г.в.) алдында ике кеше тарткалаша башлый, берсенең хәтта ачудан йөзе кызара, шунда Рәсүлебез (с.г.в.) аны күреп әйтә: «Әгәр ул, «Әгүзү билләһи минәш-шайтаанир-раҗиим» (Таш атып куылган шайтанның явызлыгыннан Аллаһка сыенам) дигән сүзләрне әйтсә, әлбәттә, тынычланыр иде».

Аллаһы Тәгалә Әгъраф сүрәсенең 200нче аятендә әйткән: «Әгәр сине, шайтан котыртса, син Аллаһы Тәгаләгә сыен. Ул һәрнәрсәне ишетүче һәм белүчедер».

***8 бирем.***

Ачу сүзе белән бәйләнешле нинди мәкаль һәм әйтемнәр бар? Сездәге карточкалардан мәкальләр төзеп тактага беркетергә. (Төркемнәрдә эш.)

| | |
|---|---|
| Ачуның даруы – | дәшми калу. |
| Ачуның башы юләрлек, | ахыры үкенеп үләрлек. |
| Ачуың килсә, | йөзгә кадәр сана. |
| Ачуың килсә, | суык су эч. |
| Ачуың килсә, | чыгып кит. |
| Көчсезнең | ачуы көчле. |
| Ачу саклама, | намус сакла. |
| Акылың булса, | ачу саклама. |

| | |
|---|---|
| Ачу йоту – | тау йоту. |
| Ачу килсә, | акыл китәр. |
| Аюны җиңгән ярты ир, | ачуын җиңгән бөтен ир. |
| Иске ачу | истән чыксын. |
| Ачуыңны | йот. |
| Ачучанны ачуландырып | серен алалар. |

– Ачулану мәсьәләсендә кешеләр төрле хәлдә булалар. Кайбер кешеләр тиз ачуланалар һәм тиз тынычланалар. Икенчеләре, тиз ачуланалар һәм озак тынычлана алмыйлар. Өченчеләре исә, тиз ачуланмасалар да, ачулансалар һич тә гафу итә алмыйлар.

Бу хакта Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сезнең арада иң хәерле кеше тиз ачулана белмәгән, ачуланса да, тиз тынычлана алган кеше. Һәм сезнең арада иң начар кеше тиз ачуланып озак тынычланган кеше», – дип әйткән.

**IV. Дәресне йомгаклау.**

– Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Нинди нәтиҗәләр ясадыгыз? (Укучылар җавабы)

**Слайд.**

– Коръән аятендә: «Ачуыгызны эчкә алыгыз, бер-берегезне гафу итегез, Аллаһы Тәгалә каршысында сөйкемле бәндәләрдән булырсыз», – диелә.

**V. Өйгә эш:**

1) Дәреснең эчтәлеген өйдә сөйләп бирегез.

2) Дәфтәрегезгә үзегез кемне ачуландырудан тыелып кала алдыгыз һәм ничә тапкыр, шуны язып килергә.

***Мөхәммәтҗанова Әминә,***

*Балтач районы, Шубан авылы*

## КИЕМГӘ КАРАП КАРШЫ АЛАЛАР

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:* киенүдә зәвык, киемгә сакчыл караш булдыру. Исламча киенү әдәпләрен аңлату.

*Бурычлар:* 1. Киемнең кеше асылының бер өлеше, хайваннардан аермалы сыйфаты булуын, аның эчке дөньясын чагылдыруын аңлауларына ирешү.

2. Киенү зәвыгына, киемдә милли үзенчәлекләр булдыруга өйрәтүне дәвам итү.

3. Тегүче һөнәренә хөрмәт, үз-үзенә, киенүгә таләпчәнлек тәрбияләү.

*Материал:* Җ. Фазлыев. «Җәлил хәзрәт дәресләре» 95–97, 106–109 нчы битләр, К. Вәлиуллин. «Ислам тәрбиясе» 1–4 нче сыйныфлар өчен дәреслек. 194–195 нче битләр. В. Казыйханов. «Әхлак дәресләре» 75–83 нче битләр.

**Җиһазлау.** Слайдлар, анкеталар, компьютер, колонкалар, проектор, түбәтәй, калфак.

*Дәрес барышы:*

**I. Сәламләшү.**

– Дәресне, гадәттәгечә сәламләшү белән башлыйк.

– «Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ» (Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте, иминлеге һәм бәрәкәте булсын.)

– Вәгаләйкемәссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү. (Рәхмәт, сезгә дә шулай ук.)

**II. Актуальләштерү.**

1. Дәреснең темасын ачыклау.

– Күз алдыгызга китерегез: сез, моңа кадәр таныш булмаган кеше белән очраштыгыз, ди. Иң элек бер-берегездә нәрсәгә игътибар итәсез?

– (Җаваплар тыңланыла.) Тышкы кыяфәтенә, киеменә, төс-битенә, матурлыгына.

– Беренче очрашудан алган тәэсирләр кеше турында ныклы бер нәтиҗә ясарга ярдәм итә. Шулай булгач, очрашуга ныклап әзерләнергә, тышкы кыяфәтең турында яхшылап уйларга кирәк.

– Хәзер дәрес темасына игътибар итик (Теманы уку.) (Слайд 1.)

– Бүген дәрестә киенү зәвыгы, кагыйдәләре, киемгә таләпләр, Ислам кануннары буенча киенү әдәпләре, тегүче, дизайнер һөнәрләре турында сөйләшербез. Киенү әдәбенә, әти-әниләр безне бик кечкенәдән өйрәтә башларга тиеш.

– Бүгенге число һәм дәрес темасын дәфтәргә язып куябыз.

2. «Мәкаль әйтеш» уены.

– Әйдәгез, уйнап алабыз. Уеныбыз «Мәкаль әйтеш» дип аталыр. (Кием турында мәкальләр әйтешү.)

1. Агач күрке яфрак, адәм күрке чүпрәк.

2. Күркәм кием – тән зиннәте.

3. Киемеңне яңа чагында, намусыңны яшь чактан сакла.

4. Киң кием тузмас, картлар сүзе бозылмас.

5. Агач җирнең – кием кешенең зиннәте.

6. Киемеңне чиста тот – ул кешенең зиннәте.

7. Тузган булса да юган булсын.

8. Пакь кием кадер арттырыр.

9. Яман кием яшь кызны әби итә, әбине пәри итә.

10. Киемне саклап кисәң, көн дә матур әйбер киярсең.

– Булдырдыгыз!

**III. Яңа тема белән таныштыру.**

1. Тема буенча әңгәмә.

– Ничек уйлыйсыз, кеше ни өчен кием кия?(Җавапларны тыңлау.)

– Суыктан, эсседән, судан, җилдән, тузаннан саклау өчен.

– Бәрелүдән, сугылудан, пычранудан саклый.

– Матур булу өчен.

– Әйе, тагын кием кеше тормышын ямьләндерә. Киемдә халыкның рухи дөньясы, милли үзенчәлекләре чагылган. Гасырлар буе яшәү дәверендә кешеләр киемгә карата таләпләр булдырган. Чорлар үзгәргән, әмма төп таләпләр үзгәрешсез калган.

2. Яңа теманы аңлату.

Кием куллану максаты буенча берничә төркемгә бүленә. (Слайд 2.)

1. Һөнәр белән бәйле эш киеме. (Пешекчеләр, кибетчеләр һ.б. супермаркетларда махсус кием кияләр.)

2. Дәүләт хезмәтендә эшләүчеләр (полиция, армия, суд, медицина, мәктәп укучылары формасы). Мондый киемнәр униформа дип атала. Күпчелек очракта баш киеме була. (Слайд 3.)

3. Дресс-код (киемгә оешмаларда куелган таләпләр) кием кодексы. (Слайд 4.)

4. Йортта, ишек алдында, бакчада эшләү киеме. (Слайд 5.)

5. Спорт костюмы. (Слайд 6.)

– Мәктәп формасын боларның кайсы төренә кертәбез?

– Ул ничә төрле була?(Көндәлек, бәйрәмчә.)

– Алар билгеле бер максатларны күздә тота, аерым таләпләргә буйсындырыла. Мәсәлән, итәк тездән түбән, ябык яка, ир-егетләргә костюм чалбар, галстук, кара туфли.

– Бу киемнәр тәртипкә, җыйнаклыкка өйрәтә, эшкә җаваплылык уята.

3. Дресс-код төшенчәсен аңлату. (Слайд 7.)

– Ә хәзер кулланышка яңарак кергән төшенчә – дресс-код турында сөйләшербез.

– Дресс-код инглиз сүзе «кием кодексы» (киенү кагыйдәләре) дип тәрҗемә ителә. Теге, я бу оешмада эшләүчеләр өчен көндәлек, эшлекле очрашуларда, тантаналы, бәйрәм чараларында, башка оешмага эш белән барганда дөрес киенү кагыйдәләре җыелмасы. (Дәфтәргә язалар.)

– Ул ни өчен кирәк? (Тормышта төрле ситуацияләрдә адәм көлкесенә калмас өчен.)

– Дресс-код нәрсәсе белән әһәмиятле?

– Ул әдәпкә, тәртипкә, башкаларны хөрмәт итәргә өйрәтә. Кием кешене тигез итә, байлык буенча катламнарга бүлми. (Слайд 8.) Халыкара очрашуларда һәм югары даирәләрдә дресс-код катгый саклана. Бу аңлашыла.

Ә менә безнең илебездә көндәлек тормышта ул әле таралып кына килә.

Дресс-код униформа түгел, нинди эшчәнлек белән шөгыльләнүләренә карап киенү формасын һәр компания үзе билгели.

Рәссамнар, артистлар, дизайнерларның киенү рәвеше шаккаттыргыч булырга мөмкин.

Ә халыкара очрашу, эшлекле сөйләшүләрдә, сату-алу мәсьәләләрен хәл иткәндә, классик стиль саклана.

Дресс-код гел бер киемдә йөрүне аңлатмый. Әйтик, тездән түбән итәк, ак яки ачык төстәге озын җиңле блузка, артык биек булмаган үкчәле, ябык аяк киеме, бизәксез колготки булырга тиеш. Фасоны һәм төсләре аз гына үзгәртелгән берничә костюм күлмәк булу мәҗбүри. Җәйге, кышкы киенү рәвеше аерым күрсәтелә.

Хезмәткәрне эшкә кабул иткәндә үк дресс-код белән таныштыралар.

Ир-егетләр өчен дә дресс-код бар. (Слайд 9.) Ул кара яки караңгы зәңгәр, көрән һ.б. костюм чалбар, галстук яки күбәләк, туфли. Джинсы чалбар һәм утыргач балтырлары күренә торган кыска балаклы носкилар тыелган.

Болар көндәлек эш киеменә таләпләр. Корпоратив, бәйрәм, рәсми булмаган очрашуларга аерым таләпләр куела.

Димәк, дресс-код нәрсә ул?

Оешма, офисларда билгеле бер очракка, максатка туры китереп киенү манерасы.

Аны кем куя?

Корпорация, оешманы төзегән җитәкчелек куя.

Дресс-код турында тагын да тулырак мәгълүмат аласыгыз килсә, бүген мәктәп радиоузелыннан булачак радио тапшыруны тыңларсыз.

**IV. Яңа теманы ныгыту.**

1. Укучылар белән әңгәмә.

– Ә җиһанны, галәмне, дөньяны кем төзегән, кем аны юктан бар иткән?

– Дөньяны Аллаһ Тәгалә юктан бар иткән. Аллаһ төзегән.

– Димәк, мөселманнарның киеменә таләпне, дресс-кодны кем билгели?

– Аллаһ Тагәлә билгели. Ул Коръәндә язылган.

2. Дәреслек белән эш. (Слайд 10.)

– Әйдәгез, китапның 194 нче битен ачыйк та «Исламда кием әдәпләре һәм догалары» – дигән бүлекне табыйк.

– Кадрия укый (194 б. Әл-Әгъраф (Пәрдә сүрәсе) 7/26 дигәнгә кадәр).

– Аятьнең ахрында Аллаһ Раббыбыз: «Тәкъвалык киеме бирдек, тәкъвалык саклау киеме хәерледер» – диде.

– Аллаһ Тәгалә безне тышкы бозыклыклардан саклау өчен күзгә күренми торган кием белән төреп алган. Аны «биокыр» дип тә атыйлар. Димәк, кием оятны гына түгел, биокырыбызны да саклый икән. Никадәр шәрә йөрсәк, безне саклаучы энергия кырыбыз, яман кешеләрнең күз карашындагы бозыклык белән кушылып, зарарланып безне саклау сәләтен югалта. Бозыклыкны иң тиз кабул итә торган антенна чәчебез. Шуңа аны каплап йөрергә кирәк. («Кием әдәпләре»н укучылар чиратлап укый. Ахырдан «Киенү догаларын» Кадрия укый.)

– Киемгә хатын-кызларга таләп зуррак, чөнки алар беренчедән, нәфис. Ә нәфис, тиз уалучан әйберне сакларга кирәк. Икенчедән, алар булачак әниләр, милләтебезнең киләчәген тәэмин итүчеләр.

«Ана» дигән бөек исем йөртүче кызлар җәен ярым шәрә калалар. Ялангач кыз баланың ояты бар дип уйласак та, киемсез тәнгә бозыклык керә, күз тия. Ә черек, бозык агачта таза җимеш үсми. Шуңа әдәпле киенеп, башны каплап йөрү кирәк.

Безнең күзгә күренми торган тәкъвалык киемебез тәһарәтле, госелле булу, тиешле киемнәр киеп йөрү, намаз, ураза кебек гамәлләр белән ныгый.

3. Р. Фәхреддиннең «Балаларга нәсыйхәт» китабыннан «Кием әдәпләре» белән танышу. (Слайд 11-12-13.)

– Ә хәзер үткән гасырның күренекле галиме Р.Фәхреддиннең «Балаларга нәсыйхәт» китабыннан «Кием әдәпләре» белән танышыйк. (Слайдтан уку, хәтердә калганча дәфтәргә язып кую.)

4. Медицина хезмәткәре чыгышы.

– Бүген дәрестә авыл фельдшеры Рузилә апагыз да катнаша. Тыңлыйк әле, медицина киенүгә нинди таләпләр куя икән.

– Рәхмәт. Күргәнегезчә, дөньякүләм стандартлар, медицина, дини таләпләр – һәркайсы шәрәлекнең организмга зыянлы булуын күрсәтеп, аны тупаслык, җиңел холыклык нәтиҗәсе, дип аңлата.

Тагын шуны да истән чыгармагыз, кием никадәр затлы булса да, аны чиста-пөхтә итеп, саклап кимәсәң, ул матурлыгын тиз җуя.

5. Анкета сораулары буенча эш, нәтиҗәләр ясау.

Мин сезгә һәм әти-әниләргә өйгә эш итеп анкета сорауларына җаваплар әзерләргә биргән идем.

– Хәзер нәтиҗә ясап китик. (Нәтиҗә ясау, әти-әниләрнең фикерләре белән танышу.)

6. Дөньякүләм танылган модельер, дизайнер, мода тарихын өйрәнүче шәхесләрнең киенү әдәбе турында фикерләре белән танышу. (Слайд 14.)

– Хәзер дөньякүләм танылган модельер, дизайнер, мода тарихын өйрәнүче шәхесләрнең киенү әдәбе турында фикерләре белән танышыйк. (Слайдтан балалар кычкырып укый.)

*Эвелина Хромченко:*

«Не трогайте слишком яркое, оно очень ядовитое».

«Нужно блистать, а не блестеть».

«Цвет звучит, кричит и громко поет».

*Влад Лисовец* (дизайнер – модельер) (Слайд 15).

«Короткая юбка – знак легкой доступности, одевайте короткую юбку только при муже».

*Мадам Шанель:*

«Экстровагантность – враг элегантности».

7. Кием белән бәйле тыюлар, йолалар белән танышу.

– Халык арасында кием белән бәйле тыюлар, йолалар да бар.

Гөлүсә: Миңа әбием киенгәндә менә мондый кисәтү-тыюлар әйтә.

– Киемне өстән аска кисәң, хөрмәткә ирешерсең, астан-өскә кисәң, түбәнлеккә төшәрсең.

– Сүтелгән киемне өстеңдә килеш текмә, гомерең кыскарыр.

– Чалбарны басып кисәң, бөлгенлеккә төшәрсең.

– Яланбаш йөрсәң, баш очыңдагы саклаучы фәрештәләр качар.

8. Татар халык киемнәре белән танышу. (Слайд 16.)

– Тарихка күз салыйк әле, борынгы әби-бабалар ничек киенде икән?

Борынгы бабаларыбыз «Болгари», «Сафьян» дигән гаҗәп нәфис күн эшләп, аны ефәк, сәйлән белән чигеп, күңелнең иң нечкә кылларын да тибрәндерерлек читек-кәвешләр белән дөнья базарында дан тоткан. (Слайд 17.)

(Татар киеменнән кыз бала чыга) (слайд 18)

1. Дәү әнием энҗе калфак
   Бүләк итте үземә.
   Энҗе калфак үзе ап-ак,
   Бик килешә йөземә.
2. Матур изү бизәп тора
   Күлмәгемнең күкрәген,
   Диңгез суы кебек тора
   Дулкынланып итәге.
3. Алъяпкычымның бизәге
   Әллә кайдан күренә,
   Аллы-гөлле чәчәк төшкән
   Килешәдер үземә.
4. Бизәк төшкән итекләрне
   Читекләр дип йөрткәннәр,
   Аларны татар кызлары
   Бәйрәмнәрдә кигәннәр.

(Татар киеменнән ир бала чыга)

1. Бигрәк матур түбәтәем:
   Энҗе бөртекләр белән,
   Алар монда килгән гүя
   Чын әкият иленнән.
2. Төрле төсле сурәт төшкән
   Бу чәчәкле читеккә,
   Кызлардан да ким булмасын
   Батыр-чибәр егет тә.
   Бу читекләр, бу бизәкләр
   Килә ерак чорлардан.
   Үсәр татар балалары
   Илһам алып шулардан.

9. Милли киемнәр турында балалар белән әңгәмә.

– Кем әйтә, ни өчен күлмәкне кат-кат бала итәкле итеп теккәннәр? (Җил итәкне күтәреп эчке киемнәр күренмәсенгә.)

– Милли киемнәрне бүген киеп йөрергә мөмкинме? (Баш киемнәрен кияләр: түбәтәй, калфак. (Түбәтәй, калфак күрсәтеләә.)

– Милли кием үрнәкләрен бүгенге модада очратабызмы? (Ләйсән Хаҗиева коллекциясе белән таныштыру.) (Слайд 19.)

10.Туран Арт фирмасы турында мәгълүмат бирү. (Слайд 20.)

11. Тегүче һөнәре турында мәгълүмат бирү.

Әйтегез әле, безгә шундый соклангыч киемнәрне кемнәр тегә? (Җавапларны тыңлау.)

– Кемнәрнең әти-әни, туганнары тегә беләә?

– Күренекле галим К.Насыйри: «Һөнәр иясе байлыгын югалтса да, кайгырмас» – дип язган. Ни өчен? (Чөнки аны туендыручы һөнәре бар.)

– Тегүчелек һөнәре безгә пәйгамбәрләрдән үк килгән. Идрис пәйгамбәр тегүче булган. Элек заманда көзге уңышны җыеп алгач, тегүчеләр (ир-егетләр) кечкенә чанага тегү машинасы, башка кирәк-яракларын төяп авылдан-авылга йөреп тегү теккән.

– Ә байларның үз тегүчеләре – хезмәтчеләре булган. Минем Гыйззәтбану әби Түнтәрнең тирә-якка данлыклы ишаны Ишмөхәммәт Динмөхәммәтовта тегүче-чигүче, Хөсәен бабам умартачы, балта остасы булган.

– Хәзер матурлык дөньясына сәяхәт итеп алабыз. (Слайдлар 21, 22, 23, 24.) Бүгенге мөселман дизайнерлары әзерләгән кием үрнәкләре белән танышыйк. Бәлки, кайберләрегез киләчәктә дизайнер һөнәрен үзләштереп, мөселман күлмәкләре тегәр.

**IV. Нәтиҗә ясау**.

Гыйбрәтле хикәя, притча тыңлау. (Слайд 25.)

Күренекле язучы А.П. Чехов: «Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә» дип язган. (слайд 26)

Бүген өйрәнгәннәр тормыш юлыгызда киңәшче, ярдәмче булса иде дигән теләктә калам.

Күңелегез дә, киемегез дә гел соклангыч булсын. Рәхмәт сезгә!

***Мөхиярова Рәзинә,***
*Чаллы шәһәренең «Ак мәчет»*
*мәхәлләсе мөгаллимәсе*

# ВАКЫТНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛҮ ӘДӘБЕ

(Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен)

*Максат:*

– Сүрә һәм хәдисләргә, мәкаль-әйтемнәргә таянып, вакытның кадерен белү әдәбе белән таныштыру;

– Аять һәм хәдисләрне, мәкаль-әйтемнәрне дөрес итеп уку, истә калдыру күнекмәләре бирү;

– Вакыт кадерен белү (үзеңнекен һәм башкаларның), аны мәгънәле файдалану сыйфаты тәрбияләү.

*Җиһазлау һәм материал:* Коръән, компьютер, интерактив тактада күрсәтеләчәк презентация (слайдлар), текстлар язылган таратма материал, Татар теленең аңлатмалы сүзлеге (Казан: «Матбугат йорты» нәшрияты, 2005), Габделҗәббар Кандалый. «Шигырьләр һәм поэмалар» (Казан: Татар. кит. нәшр., 1988), «Татар халык мәкальләре» (Мәкальләр җыелмасы: 3 томда / Нәкый Исәнбәт. – 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010), Ризаэддин Фәхреддин «Җәвамигъ-әл-кәлим шәрехе» (Казан: Рухият, 2005).

*Дәреснең төре (тибы):* яңа белем бирү.

*Метод һәм алымнар:* эвристик әңгәмә, күзәтү, чагыштыру, анализ, синтез.

*Дәреснең планы:*

I. Оештыру.

II. Актуальләштерү.

III. Төп өлеш.

1. Татар телнең аңлатмалы сүзлеге буенча вакыт сүзенең мәгънәләрен ачыклау.

2. Коръәндә һәм хәдисләрдә вакыт турындагы фикерләр.

3. Мәкаль-әйтемнәрдә вакыт чагылышы.

4. Г. Кандалыйның вакыт турындагы афоризмы.

IV. Ныгыту.

V. Йомгаклау.

VI. Өйгә эш.

*Дәрес барышы:*

**I. Оештыру этабы.**

Уңай психологик халәт булдыру.

Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

**II. Актуальләштерү.**

Вакыт төшенчәсе турында әңгәмә үткәрү.

– Нәрсә ул вакыт?

Көтелгән җаваллар (КҖ):

– Вакыт – ул сәгать (минут, секунд, көн, атна, ай, ел...).

**III. Төп өлеш.**

Вакытның нәрсә икәнлеген күзаллыйсыз. Вакыт төшенчәсен белдерә торган сүзләр шактый. Сез аның байтагын атап киттегез. Сез әйткәннәрдән тыш тагын башкача аталганнары да бар. Татар теленең аңлатмалы сүзлегенә вакыт сүзенең җиде төрле мәгънәсе күрсәтелә: *(3, 4 нче слайдлар.)*

«Вакыт» – гар. 1) Фәлсәфи яктан караганда, яшәешнең объектив бер формасы.

*Урын һәм чынбарлыкта төп формалар дип карала*;

2) Яшәеш дәвамлыгын секундлар, минутлар, көннәр, айлар, еллар һ.б. бүлеп исәпли торган кисәк, аралык.

*Вакытны әрәм итү. Вакыт үткәрү. Кыска вакытта зур эш эшләп ташлау. Иртәнге (көндезге, кичке) вакыт*;

3) Эштән, берәр шөгыльдән соңгы буш ара, төп эштән бушаган чак.

*Эшем күп, ялга вакыт калмый*;

4) Гомумән, тормышта (кешелек, дәүләт, халык яисә аерым кеше тормышында) берәр чор, дәвер, чак.

*Яшьлек вакыты. Балалык вакыты. Сугыш вакыты*;

5) Сөйләмгә төгәллек өсти: шулчак, шул ара (сәгать, көн, ай һ.б.)

*Син өйдә юк вакытта. Ул мәктәптә укыган вакыт иде;*

6) Берәр эш-хәлгә билгеләнгән вакыт, чак.

*Вакыт үтү. Вакыт җитү. Вакытына өлгермәү. Эшне вакытына төгәлләү. Вакытыннан алда килү;*

7) Нинди дә булса эшне башкару яки берәр эш кәгазен тутыру датасы көне.


*Хатның язылу вакыты күрсәтелмәгән*». (110–111 битләр.)

**Биремнәр:**


– Укыту;

– Фикер алышу.

Димәк, вакыт сүзе үз эченә бик күп мәгънә сыйдырган. Әйдәгез, вакыт берәмлекләрен аңлатучы сүзләрне схемага салыйк. *(5 нче слайд.)*




Вакытны тагын өч төрле заман белән дә билгелиләр: (Үзләреннән әйттерү.)




– Тагын нинди заман турында да без беләбез?

– КЖ: Ахырзаман.

– Әйе, ахырзаман дигән сүзне дә беләсез. Бу инде без яшәгән дөнья, хәзерге фани дөнья. Ахырзаман сүзе кергән нинди сүзтезмәләр ишеткәнегез бар?

– КЖ: – Ахырзаман пәйгамбәре.

– Ахырзаман баласы.

– Ахырзаман билгеләре.

– Әйе, кемне Ахырзаман пәйгамбәре дип атыйлар?

– КЖ: Мөхәммәд галәйһиссәламне.

– Ни өчен?

– КЖ: Чөнки җиргә башка пәйгамбәр килмәячәк, ул бөтен кешелек өчен җибәрелгән.

– Әйе, Мөхәммәд галәйһиссәлам – соңгы пәйгамбәр, Җабраил фәрештә аша Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәламгә Коръән иңдергән һәм Раббыбыз Коръәнне кыямәт көненә кадәр үзем саклармын дигән.

– Кыямәт көнен тагын нинди сүзләр белән атыйлар?

– КЖ: сәгать, хисап көне...

– Әйе, дөрес, аның тагын башка атамалары да бар: соңгы көн, кубарылу көне, очрашу көне, җыю көне һ.б.

2. – Коръәннең кайсы сүрәләрендә вакыт төшенчәсе бар?

КҖ:..

Коръәннең 103 нче сүрәсе «Гасыр» дип атала. Монда гасыр – йөзьеллык, замана, вакыт, чор, дәвер мәгънәләрен үз эченә алган. *(6 нчы слайд.)*

| | |
|---|---|
| Бу аятьтә Аллаһы Тәгалә гасырлар исеме белән ант итә. | وَٱلۡعَصۡرِ ١ |
| 93 нче «Духа» (иртәнге шәфәкъ) сүрәсендә көннең иртәнге яктылыгы. | وَٱلضُّحَىٰ ١ |
| тынычлыкка ирештерүче төн караңгылыгы белән ант итәмен дип әйтә. | وَٱلَّيۡلِ إِذَا سَجَىٰ ٢ |
| 92 нче «Ләел» (Төн) сүрәсендә дә түбәндәге фикерләр бар: Караңгылыгы белән тирә-якны каплаган төн. | وَٱلَّيۡلِ إِذَا يَغۡشَىٰ ١ |
| яктылыгы белән ачылган көн белән ант итә Аллаһы Тәгалә. | وَٱلنَّهَارِ إِذَا تَجَلَّىٰ ٢ |

**Биремнәр**:

– Укыту;

– Фикер алышу.

Шулай ук «Фәҗер» (Таң) сүрәсендә Аллаһ атып килә торган таң исеме белән, Зөлхиҗҗә аеның ун көне белән, алмашынып торучы көн вә төн исеме белән ант итә. Ә «Кадер» (Кадер киче) сүрәсендә, Раббыбыз, Коръәнне Кадер кичәсендә иңдерүе турында хәбәр бирә.

Күренүенчә, Аллаһы Тәгалә хәтта вакыт төшенчәләре белән ант итә, бу вакытның нинди кадерле нәрсә (нигъмәт) булуын бик ачык дәлилли.

Кыямәт көнендә вакытыбызны нинди эшләргә сарыф итүебез турында да хисап бирергә туры киләчәк. Шуңа күрә күркәм әхлаклы кешеләр үз вакытларын һәм башкаларныкын юк-бар эшкә сарыф итмиләр.

Вакытка кагылышлы хәдисләр дә бар. Мәсәлән, Рәсүлебезнең 46 нчы хәдисендә шундый юллар бар: «Биш нәрсә килгәнче, биш нәрсәне бәхет сана: үлемеңнән элек терек булуыңны, хасталыктан элек сәламәтлегеңне, шөгыльдән элек буш вакытыңны, картлыктан элек яшьлегеңне, фәкыйрьлектән элек байлыгыңны». *(7 нче слайд.)* (Үзләреннән укыту.)

– Хәдистә сүз нәрсә турында бара?

– КҖ: Хәдистә иң кыйммәтле биш атаманың берсе – вакыт, ягъни гомерне буш нәрсәләр белән үткәрмичә, хәерле эшләр эшләү турында әйтелә.

– 332 нче хәдистә дә бу фикер дәвам иттерелә: «Ике төрле нигъмәтнең кадерен белмичә, бик күп кешеләр алданалар. Берсе – тән сәламәтлеге, икенчесе – шөгыль вә киртәләрдән күңел тынычлыгы».

– Ә бу хәдистә сүз нәрсә турында бара?

– КҖ: Сәламәтлек белән буш вакыттан файдалана алмаган кеше, гомерен заяга үткәргән кеше хөкемендә була.

Бүгенге эшне иртәгәгә калдырмау – дөньяда яшәүнең беренче шарты. Бер эшнең үз вакытыннан кичегеп эшләнүе бик күп эшнең бөтенләй эшләнелми калуына сәбәп булуы билгеле. Намаз вакытларына килсәк, вакыты кергәнче укылганы исәпләнми (нәфел намазы булып кына саналачак). Һәрбер намазны вакыты чыкканчы укып калырга тырышырга кирәк. Каза намазы ике очракта гына рөхсәт ителә. Беренчесе – йоклап калсаң, икенчесе – нинди дә булса эш белән мавыгып, онытып куйсаң. Һәр намаз үз вакытында укылырга тиеш.

3. Безнең халкыбыз вакытның кадерен белгән, татар халык авыз иҗатында, бигрәк тә мәкаль-әйтемнәрдә бу ачык чагыла.

– Әйдәгез әле, вакытка мөнәсәбәтле мәкаль-әйтемнәрне искә төшерик.

– КҖ: (берничә мәкаль әйтелә.)

– Әйе, безнең халкыбыз мәкаль-әйтемнәргә бай. Вакытка кагылышлы кайбер мәкальләр белән танышып китик: *(8 нче слайд.)*

1) Вакыт искән җил кебек кичәр.

2) Замана безне укыта.

3) Киләсе эшне Аллаһ кына белә.

4) Иртәгә иртәге җил исәр.

5) Көткән җитәчәк, узган кайтмый.

6) Үткән гомер – сүнгән күмер.

7) Үткән эш кире кайтмый,
Аккан су кире акмый.

8) Бер югалган вакыт яңадан кайтмас.

9) Бүген эшләнәсе эшне иртәгәгә калдырма.

10) Вакытын бушка уздырган кеше ахмак.

11) Һәрнәрсә үз вакытында яхшы икәнне әтәч тә белә.

12) Югалган акча табыла, югалган вакыт табылмый.

**Биремнәр:**

– Мәкаль-әйтемнәрне укыту.

– Вакыт белдерүче сүзләрне табу.

– Мәкаль-әйтемнәрнең эчтәлеген ачыклау.

4. Шагыйрьләр, язучылар да вакытның кадерле икәнлеген аңлатып, үз фикерләрен белдерәләр. Мәсәлән, Габделҗәббар Кандалыйның шундый сүзләре калган: *(9 нчы слайд.)* (Үзләреннән укыту.)

«Якутлар табыладыр вакыт белән, вакытлар табылмыйдыр якут белән».

– Нәрсә ул якут?

– КҖ: Таш.

– Әйе, ул таш, гади генә таш түгел, ә кыйммәтле асылташларның гомуми аңлатмасы. Асылташны табу өчен нәрсә кирәк?

– КҖ: Вакыт.

– Әйе, күп вакыт кирәк, чөнки башта аны тау-таш арасыннан эзләп табарга, аннан асылташ дәрәҗәсенә җиткерү өчен, эшкәртергә кирәк. Бик күп вакыт сарыф ителгәнлектән, якут – кыйммәт. Кыйммәт, дәрәҗәле таш биреп тә үткән вакытны кире кайтарып булмый, шуңа күрә һәр минутның, һәр мизгелнең кадерен белергә кирәк. Иң кирәкле эшләрне төгәл үтәү өчен, үзебезгә нәрсә булдыру тиеш?

– КҖ: Режим.

– Әйе, режим, ягъни көндәлек эш тәртибе-план. Без аны ничек төзибез, нинди эшләрне кертәбез?

– КҖ: Иң мөһим эшләрне.

– Иң мөһим эшләрне кем атар?

– КҖ: Намаз уку, Коръән уку.

– Килешәм. Бу безнең төп эшләребез – фарыз гамәлләребез. Гыйбадәтләребезне төгәл, дөрес итеп башкару өчен, тагын нинди эшләрне көндәлек эш тәртибенә – планга кертәбез?

– КҖ: Йокы, ашау, эш вакыты.

– Әйе, иң беренче намаз вакытларын карыйбыз да (чөнки аларны үз вакытында укырга кирәк), калган эшләребезне намаз вакытларына яраклаштырабыз. Рухи сәламәтлеккә гыйбадәтләр кылып ирешсәк, тән сәламәтлегенә вакытында ашап, тиешенчә йоклап, эш режимын саклапирешәчәкбез. Вакытны төгәл итеп бүлгән очракта, без бик күп гыйбадәт кылырга, белемебезне арттырырга, төрле эшләр башкарырга өлгерәчәкбез. Әгәр буш сүзләр сөйләп, телевизор карап, компьютердагы юк-бар уеннарга вакытыбызны сарыф итсәк, иң мөһим эшләребез үтәлми калыр.

Ахырзаманның бер билгесе – вакыт тизләнеше. Кайбер галимнәрнең фикеренчә, 1985–86 нчы еллардан вакыт тизлеге арта башлаган, хәзер тәүлектә элеккечә 24 сәгать түгел, ә реаль 18–19 гына. Без моны үзебез дә тоябыз. Шуңа күрә вакытның кадере хәзер елдан-ел арта, безнең һәрбер мизгел, һәрбер сәгать исәптә.

**IV. Ныгыту**

1. Вакыт төшенчәсе кулланылган сүрә исемнәрен дәфтәрләргә теркәү.

2. Г. Кандалыйның афоризмын яттан сөйләтү.

3. Истә калган (вакытка кагылышлы) өч мәкаль-әйтемне язу.

**V. Йомгаклау**

– Бүген дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

– КҖ: Вакыт турында.

– Вакыт төшенчәсен нинди сүзләр алыштыра ала?

– КҖ: Секунд,...

– Кайсы сүрәләрдә Аллаһы Тәгалә вакыт төшенчәләре белән ант итә?

– КҖ: «Гасыр», «Фәҗер», «Духа»...

– Вакытны ничек әрәм-шәрәм итмәскә?

– КҖ: Көндәлек эш тәртибе-план булдырырга, иң мөһимнәрен вакытында төгәл үтәргә.

**VI. Өйгә эш:**

1. «Гасыр», «Духа», «Ләел», «Фәҗер», «Кадер» сүрәләрен кабатларга.

2. «Иң мөһим эшләрне үтәү серләре» дигән чыгыш әзерләргә.

## Таратма материаллар

«Вакыт» – гар. 1) Фәлсәфи яктан караганда, яшәешнең объектив бер формасы.

*Урын һәм чынбарлыкта төп формалар дип карала*;

2) Яшәеш дәвамлыгын секундлар, минутлар, көннәр, айлар, еллар һ.б. бүлеп исәпли торган кисәк, аралык.

*Вакытны әрәм итү. Вакыт үткәрү. Кыска вакытта зур эш эшләп ташлау. Иртәнге (көндезге, кичке) вакыт*;

3) Эштән, берәр шөгыльдән соңгы буш ара, төп эштән бушаган чак.

*Эшем күп, ялга вакыт калмый*;

4) Гомумән, тормышта (кешелек, дәүләт, халык яисә аерым кеше тормышында) берәр чор, дәвер, чак.

*Яшьлек вакыты. Балалык вакыты. Сугыш вакыты*;

5) Сөйләмгә төгәллек өсти: шулчак, шул ара (сәгать, көн, ай һ.б.)

*Син өйдә юк вакытта. Ул мәктәптә укыган вакыт иде;*

6) Берәр эш-хәлгә билгеләнгән вакыт, чак.

*Вакыт үтү. Вакыт җитү. Вакытына өлгермәү. Эшне вакытына төгәлләү. Вакытыннан алда килү;*

7) Нинди дә булса эшне башкару яки берәр эш кәгазен тутыру датасы көне.

*Хатның язылу вакыты күрсәтелмәгән*». (ТТАС, 2005: 110–111 битләр)

## Вакытка кагылышлы хәдисләр

Рәсүлебезнең 46 нчы хәдисендә шундый юллар бар: «Биш нәрсә килгәнче, биш нәрсәне бәхет сана: үлемеңнән элек терек булуыңны, хасталыктан элек сәламәтлегеңне, шөгыльдән элек буш вакытыңны, картлыктан элек яшьлегеңне, фәкыйрьлектән элек байлыгыңны». Хәдистә иң кыйммәтле биш атаманың берсе – вакыт, ягъни гомерне буш нәрсәләр белән үткәрмичә, хәерле эшләр эшләү турында әйтелә. 332 нче хәдистә дә бу фикер дәвам иттерелә: «Ике төрле нигъмәтнең кадерен белмичә, бик күп кешеләр алданалар. Берсе – тән сәламәтлеге, икенчесе – шөгыль вә киртәләрдән күңел тынычлыгы». Ягъни сәламәтлек белән буш вакыттан файдалана алмаган кеше, гомерен заяга үткәргән кеше хөкемендә була.

## Вакытка кагылышлы мәкаль-әйтемнәр

1) Вакыт искән җил кебек кичәр.
2) Замана безне укыта.
3) Киләсе эшне Аллаһ кына белә.
4) Иртәгә иртәге җил исәр.
5) Көткәч җитәчәк, узган кайтмый.

6) Үткән гомер – сүнгән күмер.
7) Үткән эш кире кайтмый,
Аккан су кире акмый.
8) Бер югалган вакыт яңадан кайтмас.
9) Бүген эшләнәсе эшне иртәгәгә калдырма.
10) Вакытын бушка уздырган кеше ахмак.
11) Һәрнәрсә үз вакытында яхшы икәнне әтәч тә белә.
12) Югалган акча табыла, югалган вакыт табылмый.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Түбән Сөн авылы*
*мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## ГАИЛӘ – КЕШЕ ГОМЕРЕНЕҢ БӘХЕТ КҮГЕНДӘГЕ КОЯШЫ

(Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен)

*Максат:* укучыларны гаиләнең бурычлары, вазифалары белән таныштыру. Гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең уңайлы һәм җылы атмосфера булдыра алуы, төп кагыйдәләрнең берсе булуын ачыклау. Укучыларда гаилә коруга, бала тәрбияләүгә карата уңай хисләр тәрбияләү. Баланың гаиләдәге бурычлары һәм хокуклары белән таныштыру. Әхлаклы гаиләнең нигезе, иманыбызга бәйле икәнлегенә ышандыру.

*Җиһазлар:* укучыларның әти-әниләренә багышлап язган иншалары, шәҗәрәләре, чиккән сөлгеләр, мендәр япмалары, кулъяулыклар һ.б., гаилә фотоларыннан төзелгән стенд.

*Плакатлар:* «Гаилә – кеше гомеренең бәхет күгендәге Кояшы», «Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган әрәм булган», «Ата-бабасын искә алмаган кеше игелек күрмәс».

*Сүзлек*: «Гаилә – никахка яки кан-кардәш туганлыкка нигезләнгән кечкенә төркем, аның әгъзаларын көнкүрешнең уртаклыгы, үзара ярдәмләшү, мораль һәм хокукый җаваплылыкка бәйле».

*Хәдисләр:* «Нәсел-нәсәбегезне белегез, кардәшләрегезгә барыгыз, чөнки бергә яшәсәгез дә, өзелгән туганлыкта якынлык юк, еракта торсагыз да, йөрешкән туганлыкта ераклык юк», «Туганнар белән элемтә – күркәм холыклылык».

*Кулланылган әдәбият:* Көч һәм рух тамырлары» (әдәплелек дәресләре), Хәдисләр, «Балаларга үгет-нәсыйхәт», И. Хөснетдинов.

«Бәхет дагасы», Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. «Тәрбия теориясе һәм методикасы», «Онытылмас мәктәп еллары» («Мәгариф» журналы китапханәсе.), А.И. Кравченко. «Җәмгыять белеме», «Мәгариф» журналы № 3, 5, 9.2006.

Сыйныф бүлмәсе, матур итеп әниләр һәм әбиләр мирасы булган тукылган һәм чиккән сөлгеләр, мендәр һәм өстәл япмалары һ.б. әйберләр белән бизәлгән. Бер өстәлгә укучыларның әти-әниләренә, әби-бабаларына, туганнарына багышлап язган иншалары, шигырьләре; икенче өстәлдә гаиләләренә багышлап эшләнгән шәҗәрәләре тезелгән. Каршы якта укучыларның кул эшләреннән күргәзмә, аның өстенә гаилә фотоларыннан төзелгән стенд эленә.

*Дәрес барышы:*

**1. Теманы ачу**.

*Укытучы:* – Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи ва бәрәкәтүһ кадерле укучылар! Әгүүзү билләһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Хәерле көн! Бүген булачак дәресебез, безнең гаиләбезгә багышланыр. Гаилә – җәмгыятьнең аңа тотрыклылык һәм һәрбер киләчәк буынга халыкны тулыландыру сәләте бирүче фундаменталь институтларының берсе. Гаилә – кан – кардәшлек яки никах нигезендә төзелгән кече төркем, иң ныклы, бердәм ячейкасы. Бу төркем әгъзалары уртак тормыш алып баралар, бер-берсе өчен җаваплылык тоталар, үзара ярдәмләшеп яшиләр.

– Сез укучылар, гаилә турында ниләр өсти аласыз?

*Укучы җавабы*: Гаилә – җәмгыятьнең бер күзәнәге ул. Гаилә борын-борыннан төп өч вазифаны үтәгән:

– кешелекне дәвам итү;

– балалар тәрбияләү;

– хуҗалыкны бергәләшеп алып бару.

*Укучы җавабы*: Гаиләнең төп вазифаларына керә:

– гомерне һәм сәламәтлекне саклау;

– кешенең физик, матди һәм рухи ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерү;

– балалар тудыру һәм тәрбияләү;

– гаиләнең һәр әгъзасының үсеше һәм тормыштагы урынын табуы өчен уңайлы шартлар тудыру;

– җәмгыять өчен кирәк булган кешелек ресурсларын яңадан тулыландыру.

*Укытучы:* Гаилә, әлбәттә, әти-әнидән башка була алмый. Алар безнең өчен изге җаннар. Без аларны яратабыз, хөрмәт итәбез.

*Укучы җавабы*: Гаилә – никахка яки кан-кардәш туганлыкка нигезләнгән кечкенә төркем, аның әгъзаларын көнкүрешнең уртаклыгы, үзара ярдәмләшү, мораль һәм хокукый җаваплылыкка бәйле. (Сүзлекне күрсәтә һәм стенадагы плакатка язылган сүзләрне укый.)

**2. Төп өлеш.**

**Гаиләгә багышланган шигырь уку.**

*Сөямен чын күңел берлән үземнең әткә-әнкәмне;*
*Яраткан барча нәрсәмнән алар матур, алар ямьле.*
*Сабый чакта күземне ачкач ук күрдем мин аларны,*
*Сөям мин шул вакыттан бирле бу хөрмәтле җаннарны.*
*Күтәргәннәр авырлыклар минем чөн җаннары тынмый,*
*Киендергән, ашатканнар тузан чаклы авырсынмый.*
*Язу белдем, уку белдем, үзем сигезенче яшемдә;*
*Бу нигъмәтләр насыйп булды аларның тәрбиясендә.*
*Сөямен чын күңел берлән үземнең әткәм-әнкәмне, –*
*Алар олуг, алар матур, алар дөньяда иң ямьле.*

Мәҗит Гафури. «Ата-ана»

*Укытучы*: Ә хәзер Гөлнур иншасыннан бер өзек тыңлап үтик.

*Гөлнур: «Гаилә татулыгы белән көчле», – ди халкыбыз. Билгеле булганча, кешенең бөтен гомере гаилә белән бәйле. Иң элек без, әти-әни гаиләсендә иң рәхәт, иң күңелле вакытыбызны үткәрәбез. Бала вакытымны, сабый чакларымны әтием-әнием белән еш искә төшерәбез. Безнең гаиләдә бөтен кеше бер кеше турында, ә бер кеше бөтен кеше турында кайгырта. Гаиләбездә һәрчак үзара хөрмәт, тигезлек, үзеңә караганда башкаларга күбрәк яхшылык эшләү теләге хакимлек итүен дәвам итсә, миннән дә бәхетле кеше булмас.*

*Исәнлек-саулык сорап*
*Дога кылам.*
*Гаиләмнән аермасын*
*Берүк Ходам!*

Илсур Хөснетдинов сүзләре һәм көенә язылган *«Матур гаилә корыйк»* җыры башкарыла.

*Укытучы:* Баланың иң якын киңәшчесе, хәленә керүче, кайгы-шатлыгын үз йөрәге аша үткәрүче кеше – **Ана.** Илшат әнисе турында болай дип язган иде үз иншасында (Илшат үзенең иншасыннан өзек укый): *«Җир йөзендә иң матур сүз – ӘНИ. Әниемнең куллары дөньядагы иң-иң*

*йомшак куллар! Әни куллары – иң мәрхәмәтле һәм назлы куллар. Барысына да җитешәләр алар: өйне матур итеп тотарга да, ашап туйгысыз тәмле ризыклар әзерләргә дә. Әни йөрәге иң сизгер йөрәк. Аңарда мәхәббәт беркайчан да сүнми, ул бернәрсәгә дә ваемсыз булмый.*

*Биш яшьме, илле яшьме – күпме генә булмасын, сиңа ул һәрвакыт әни; аның иркәләве, ягымлы карашы кирәк. Әниеңә синең мәхәббәтең никадәр зур булса, тормышың да шулкадәр шатлыклы һәм якты була.*

*Әни, әнием! Кадерлем минем! Синең йөрәгеңдәге игелек миңа да күчсен иде. Нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә җитмәс төсле. Мин һәр көнне синең җылы карашыңны тоюым, ягымлы сүзеңне ишетеп уянуым белән бәхетле. Мин, синдәй әнием булу белән горурланып яшим.*

*Әни! – бу дөньяның бөтен изгелеге*
*Яхшылыгы синең күңелдә.*
*Назлы карап, күз сирпүең җитә,*
*Тирә-ягым нурга күмелә».*

*Укытучы:* Сез инде зур сыйныфта укысагыз да, аналарга чын хөрмәтегез булуын матур итеп күрсәтә аласыз. Анага карата күпме наз, күпме җылы хисләр бу иншада. Син куанганда куанып, син кайгырганда кайгырып, синең белән сулап, бергә көлеп яшәүче кеше ул әни. Әниләр гаиләнең татулыгын идарә итүчеләр дә булып торалар. Әниләр шундый гаҗәп, әйбәт кешеләр инде алар.

Илсур Хөснетдинов сүзләре һәм көенә язылган *«Әнием»* җыры башкарыла.

Чулпы таккан күлмәгеңне
Бүген бәйрәмгә киче.
Сабый чагымдагы кебек
Мине бүген бер сөйче.

Куш.: Әнием! Әнием!
Гөлләр үстерәм сиңа.
Гөлләремне бүләк итеп,
Бәйрәм иттерәм сиңа.
Әнием! Әнием!
Гөлгә сулар сибимме?
Төнге гөлләр серле була,
Шуны сиңа сөйлимме?

Ал син, ал син, әнием,
Ал син, чәчәк бәйләмен.

Алып килдек без сиңа
Бүген язның бәйрәмен.

Куш.: шул ук. (Соңыннан беренче куплет кабатлана.)

*Укытучы:* Ә хәзер әйтегез әле, гаиләдә этиләр нинди роль башкаралар?

*Укучы җавабы*: Гаиләдә **Әти** ныклы терәк. Ул гаилә терәге генә түгел илебез терәге дә әле. Илебезнең, күгебезнең иминлеген саклый алар. Басукырларда иген үстереп, туклыгыбызны булдыралар. Аның иңнәрендә – сынауларның иң авыры. Карлыгачтан көнне, сандугачтан төнне сорамыйча эшли, чын ирләрнең күбесе. Ялгыз агач сыман сынмый алар.

*Укытучы:* Әтиләр турында берәр шигырь уйлап карыйк әле.

*Укучы җавабы*: Элек өйрәнгән бер шигырем хәтеремдә калган:

Ул – җирдә иң шәп кеше!
Шәп кеше, гаҗәп кеше!
Ул иң-иң көчле кеше!
Ул зирәк тә, шаян да.
Акыллы да, әйбәт тә!
Кем дисезме? Ул кеше –
Минем эти, әлбәттә!

*Уытучы*: «Ир кеше – иген басуы, хатын – иген тулы келәт», – диләр. «Иген» не кадерләп саклаучы «келәт»е белән балаларының тәүфыйклылыгына, оныкларының бәхетенә куанып, соңгы сулышларына кадәр кулга-кул тотынышып, тигезлектә, тынычлыкта, матур гаилә булып, озын гомер кичерергә язсын безнең эти-әниләребезгә.

*Укучы җавабы*: Гаилә тирәнтен әхлакый-эстетеик кичерешләр, фикерләүләр, бәяләмәләр формалаштыруның да нигезе булырга мөмкин, аларга таянып бик кыйммәтле кешелек мөнәсәбәтләре – мәхәббәт, дуслык, кайгыртучанлык, өлкәннәргә хөрмәт, тирә-юньне яхшырту теләге, үзтәрбиягә омтылыш уята.

*Укытучы:* Әти-әниләр үз баласын тырышып, җаннарын да кызганмыйча, күз карасыдай якын күреп, саклап, назлап-сөеп үстерә. Бала да эти-әнисен ихлас күңелдән хөрмәт итәргә, игелекле булырга омтылырга тиеш. «Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр», «Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр», – диелә хәдисләрдә.

Ризаэддин Фәхреддиннең *«Тугамәләр әдәбе»*н уку.

Безнең бер хәдисебездә дә «Туганнар белән элемтә – күркәм холыклылык», диелә.

Р. Тимербаев көе, Рамил Чурагулов сүзләре. *«Туганнарның кадерен бел»* җыры җырлана.

*Укытучы:* Гаилә баланың тормышын акыллы итеп оештыруны, өлкән буыннар тормышының һәм хезмәт юлының уңай тәҗрибәсен үзләштерүдә ярдәм итүне, төрле эшчәнлекләр, мөнәсәбәтләрнең шәхси тәҗрибәсен туплауны тәэмин итәргә тиеш.

*Һәр бала үз буынын белергә тиеш.* Әгәр дә бала җиде буынын белсә, ул алга таба да чын буын дәвам итүче шәхес булып калачак. Хәдистә дә «Нәсел-нәсебегезне белегез, кардәшләрегезгә барыгыз, чөнки бергә яшәсәгез дә, өзелгән туганлыкта якынлык юк, еракта торсагыз да, йөрешкән туганлыкта ераклык юк» диелгән.

Безнең Сиринә үзенең 7 буыннан торган нәсел шәҗәрәсен эшләде. Ул шәҗәрә турында берничә сүз әйтеп китик әле.

*Сиринә:* «Әгәр үлгәч тә искә алсыннар дисәң, игелекле нәсел калдыр», – дигән борынгы акыл ияләренең берсе. Игелекле нәсел калдыр – бу сүзләр кешегә икеләтә бурыч йөкли. Беренчесе – нәселең игелекле булсын өчен, син үзең игелекле булырга тиеш. Икенчесе – игелекле балалар тәрбияләргә тиешсең. Менә шушы кагыйдәләрне өйрәнеп, мин дә үземнең шәҗәрәмне төзеп, нәселемне өйрәндем. (Үз шәҗәрәсе белән, *җиде буынын* белгән һәм аны матур итеп эшләгән Сиринә таныштыра.)

*Укытучы:* Бел син, ерак бабайларның
Ничек итеп көн иткәнен,
Ни иккәнен, ни чәчкәнен,
Нинди уйлар, нинди моңнар?
Безгә калдырып киткәнен, –

дип язган бит үзенең шигырендә Равиль Фәйзуллин да.

*Укытучы:* Гаиләнең буыннар чылбыры, бу – буыннарның эзлекле бәйләнеше. Стенада язылган *хәдисләргә* игътибар итик: «Нәсел-нәсәбегезне белегез, кардәшләрегезгә барыгыз, чөнки бергә яшәсәгез дә, өзелгән туганлыкта якынлык юк, еракта торсагыз да, йөрешкән туганлыкта ераклык юк», «Туганнар белән элемтә – күркәм холыклылык». Зур вакыт аралыгында яшәүче гаилә – эзлеклелеген югалткан хәлдә һәр буынында бүленә һәм тулыландырыла торган бербөтенлек ул. Һәр алдагы буынында үзенең бердәмлеген тулыландыра алуы – гаиләнең бик әһәмиятле характеристикасы.

*Укучы: Фәнис Яруллинның «*Кеше китә – җыры кала», – дигән шигырен укый.

Кеше китә – җыры кала диләр,
Бер җыр калсын әле бездән дә
Ул җыр җанга шатлык булып керсен
Кояш булып кунсын йөзләргә.
Җыр калдырыйк җирдә, нур калдырыйк,
Җырда калсын безнең гомерләр
Безнең дөрләү, безнең януларны
Киләчәккә җырлар илтерләр.
Без һәммәбез җирдә берәү генә,
Беркемнең юк җирдә алмашы.
Кабатланмас үз язмышы белән
Туа җиргә адәм баласы.

*Укытучы:* Әйе, без бүген бары тик матур итеп тормыш корып, тигезлектә генә яшәгән гаилә тормышы белән генә таныштык. Гаилә турындагы законнарны beләбезме икән соң без?

*Укучы җавабы:* Гаилә турындагы законнарны без *Россия* һәм *Татарстан Республикасы Конституцияләрендә* күрә алабыз. Мисал өчен, 30 нчы маддәдә болай диелгән:

«Гаилә, ана һәм балалар дәүләт яклавында.

Никах хатын-кыз белән ир-атның ирекле килешүенә нигезләнә; гаилә мөнәсәбәтләрендә хатын белән ир тигез хокуклы.

Гражданнарның гаилә тормышы закон белән саклана.

Дәүләт гаилә турында кайгырта, ана белән баланың сәламәтлеген саклауга һәм балаларны тәрбияләүгә аерым игътибар бирә».

*Укытучы: Бала хокуклары турындагы Конвенциясендә* балалар турында ни дип әйтелгән?

*Укучы җавабы: Бала хокуклары турындагы Конвенциядә* дә балалар турында болай дип язалар:

«*Бала тәрбияләүдә төп җаваплылык – ата белән ана, әмма дәүләт тиешле ярдәмне күрсәтергә тиеш.

* Һәр бала яшәүгә хокуклы.

* Дәүләт баланың сәламәт үсүен һәм исән-имин яшәвен булдыра алган кадәр тәэмин итәргә тиеш.

* Балалар сәламәтлек саклау системасында иң яхшы чаралардан файдаланырга хокуклы.

*Дәүләт баланы наркотик матдәләр кабул итүдән, бу матдәләрне җитештерү һәм сатудан сакларга тиеш».

**3. Йомгаклау.**

*Укытучы:* Кеше җиһанга бәхетле булу өчен туа. Бәхетле булу өчен, иманлы булырга кирәк. Иманлы гаилә генә бабаларына бәхет китерә ала. «Кешенең бөтен гомере, киләчәге, аның төп тамыры – үзен тәрбияләгән гаиләдә», – дип юкка гына әйтмиләрдер. «Гаилә – бәхет ачкычы», – диелә бит татар халык әйтемнәрендә дә. Гаиләнең тотрыклылыгы, гаилә тигезлеге безнең үзебездән генә тора. Мин сезгә, алдагы тормышыгызда бәхетле, тигез гаиләле, пар канатлы булып яшәвегезне теләп калам.

Гаилә кору – зур юлларның башы,
Юлларыгыз һәрчак ак булсын.
Тормышыгыз гөрләп чәчәк атсын,
Чәчәкләре мәңге саф булсын.

**4. Өйгә эш:**

Гаиләгә, туганлыкка, нәселгә карата хәдисләрне барларга һәм язып килергә.

«Җәннәт – аналар аяк астында» дигән темага сыйныф сәгатенә әзерлек йөзеннән, гыйбарәнең эчтәлеген ачарга әзерләнегез.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Кече Сөн авылы мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## ТӘҮБӘ

(Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен)

*Максат:* тәүбә сүзенә дөрес итеп аңлатма бирүгә ирешү. Балаларны тәүбә намазы белән таныштыру. Бәраәт кичәсендә тәүбә кылырга кирәклеген төшендерү. Коръән сүрәләреннән тәүбә турындагыларын сайлап алырга һәм дөрес итеп аңлатма бирә алуларына ирешү.

*Җиһазлар:* Коръән сүрәләре, «Мең дә бер хәдис», «Хәдисләр», дәфтәрләр, шигырь.

**Кулланылган әдәбият:** Коръән сүрәләре, «Мең дә бер хәдис», «Хәдисләр», «Балаларга үгет-нәсыйхәт» китабы, Имам Әбү Хәмит әл-Газали. «Әдәпләр», Вил Казыйханов. «Әхлак дәресләре». К. Вәлиуллин. «Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методикасы».

## Дәрес барышы.

**1. Кереш өлеш.**

*Укытучы:* Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Әссәләмегаләйкем вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ кадерле укучылар! Без бүген сезнең белән, тәүбә турына сөйләшербез.

Шәфкатьле вә мәрхәмәтле Аллаһы Тәгаләгә хәмде вә шөкер – бары тик ул гына һәммә нәрсәдән Бөек, Ярлыкаучы, Кичерүче. Аллаһы Тәгаләдән башка беркем дә гөнаһларны ярлыкый алмый.

**Нәрсә соң ул тәүбә?**

(Укучыларның җаваплары тыңланганнан соң кагыйдә чыгарыла.)

*Билгеләмәсе:* Тәүбә – гарәп телендә «тәвәбә» фигыленнән алынган исем, «кире кайту» дигәнне аңлата.

*Төп аңлатма:* **Тәүбә – хатадан, гөнаһтан кайту, кылынган гөнаһлар өчен Аллаһы Тәгаләнең гафу итүен сорау.**

**Тәүбә** – кешенең чын күңеленнән гөнаһлары өчен үкенүе, киләчәк тормышында Алла кушканча эшләү максаты белән Аңа кайту, гөнаһ эшләр эшләүдән тыелу, яхшы гамәлләр кылу. Һәм бу эшләр аны тәүбәгә килүен практик рәвештә дәлилләргә тиеш.

(Төп аңлатмасын балалардан кабатлату.)

**2. Төп өлеш.**

*1) сорау-җавап рәвешендә әңгәмә.*

***1. Тәүбәң кабул булсын өчен нинди эшләр эшләвең яки эшләмәвең хәерле?***

*Укучылар:* (кул күтәреп саныйлар) Алла хакы өчен, гөнаһ кылмаска һ.б.

*Укытучы:* Хәзер сез әйткәннәрдән чыгып, тәүбә кабул булсын өчен эшләнә торган эшләрне дәфтәрләргә язып куябыз. Һәрбер хәерле эшне сезнең белән дөрес формалаштырып, тәртипләп язабыз. *(дәфтәрләрдә эш.)*

*Тәүбә кабул булсын өчен хәерле эшләр:*

1. Тәүбә кылу Аллаһ хакы өчен булырга тиеш.
2. Гөнаһлар кылудан баш тартырга.
3. Кешедә вөҗдан газабы булырга тиеш.
4. Киләчәктә гөнаһлар кылмам, дигән катгый ниятта булу.
5. Гөнаһлар алдан уйлап эшләнмәгән булсын.
6. Тәүбәгә килүче Аллаһ кушканнарның барысын да үтәргә тиеш.
7. Тәүбәгә килүче тәүбәсен онытмаска тиеш.
8. Үз вакытында тәүбә кылырга тиеш.
9. Тәүбә намазын укырга кирәк.

***2. Тәүбә намазы бармы?***

*Укытучы:* Тәүбә намазы бар.

**Тәүбә намазы** – гөнаһлардан үкенеп, тәүбә кылыр өчен укыла торган ике рәкәгатьле нәфел намазы. Һәрбер намаздан соң ике тарафка сәлам биреп, өч мәртәбә:

«Әстәгъфируллаһе – ләзше ләә иләәһә иллә һүәл хәйүл кайүүм, үә әтүүбү иләйһи. (Мәгънәсе: Аллаһының ярлыкавын сорыйм. Аннан башка Илаһ юк һәм ул тередер, күк-җирләрне, һәр нәрсәне Яралтучыдыр. Аллаһыга тәүбә һәм истигъфар кыламын)», – дип укырга кирәк.

Бу фани дөньяда кылган гөнаһларыбыз өчен тәүбәгә килеп, иман китерсәк, Коръән юлы белән изге гамәлләр кылсак, Аллаһы Тәгалә безгә ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы булыр.

**Бәраәт кичәсендә тәүбә кылырга кирәк**. Бу кичә гөнаһлардан котылу, бәхет һәм иминлек кичәсе, төрле уңышлар, изгелекләр иңә торган көн. Нәкъ ошбу көнне Аллаһы Тәгалә һәрбер кешенең язмышын билгели.

*(Плакат буенча эш.) Бер укучы укып чыга.*

*Тәүбә кабул булсын өчен эшләмәвең хәерле эшләр:*

1. Аллаһыга башка берәүне тиңләү.
2. Көферлек.
3. Икейөзлелек.
4. Хәрам кылу.
5. Зина кылудан һәм кешеләрне зина кылуда гаепләү.
6. Рибачылык.
7. Золымлык.

***3. Тәүбә итү өчен махсус вакыт билгеләнгәнме?***

*Укытучы:* Тәүбә итү өчен билгеле бер вакыт юк. Һәркем теләгән чагында тәүбә итә ала. Әмма түбәндәге вакытларда тәүбә кылу яхшырак (фазыйләтлерәк).

*1. Сәхәр вакытында.*

Сәхәр вакытының тәмамы-кояш чыгуга ике сәгать калганда. Бу хакта Аллаһы Тәгалә «Әл-Гыймран» сүрәсендә әйтә: «Тәүбә кылучылар сәфәр вакытында истигъфар кылырлар».

*2. Намаз вакытында.*

Рөкүгъ вә сәҗдәдә һәм намаздан соң.

*3. Азаннан соң.*

Пәйгамбәребез (с.г.с.) әйтте: «Кем дә кем азан әйткәннән соң «Разыту билләһи раббән» – «Мин Аллаһы Тәгаләдән тәрбия итүче

икәнлегеннән разый булдым» – дип әйтсә, Аллаһы Гәззә вә Җәллә ул бәндәне кичерер.

*4. Җәберләнгән вакытта.*

Аллаһы Тәгалә «Нәмл» сүрәсендә әйтә: «Җәберләнгән кеше дога кылса – аның догасы кабул итүче вә кешеләрдән зарарны җибәрүче. Аллаһы Раббыбыз хәерле, Ул сезне хуҗа кылыр».

*5. Дога өчен фазыйләтле вакытларда. (Дога кылган вакытта. Азан белән камәт арасында җомга көнне кыйблага карап.)*

Мәсәлән, төннең икенче өлешендә, азан белән камәт арасында җомга көн – кыйблага юнәлеп, тәһарәтләнеп.

*Укытучы:* Кем үкенүне һич тә кичерми,
Аның ***тәүбәсе*** кабул ителми.

*2) Шигырь уку.* Игътибар белән тыңлап, эчтәлеген ачып биререгә. Укучы укый.

...Үткән гомер һич кайтмас,
Малың һич файда бирмәс.
Үлгәннән соң **тәүбә** булмас,
Аллаһ! – дигел, бәдавәм.

Шәригатьне мәхкәм тот,
Гөнаһлардан **тәүбә** ит.
Туры юлга туры кит,
Аллаһ! – дигел, бәдавәм.

Шәригатьне тотмаган,
Гөнаһтан **тәүбә** итмәгән.
Урны тәмугтыр һаман,
Аллаһ! – дигел, бәдавәм.

Һәркем шәригатьне тота,
Гөнаһтан **тәүбә** итәр.
Оҗмахка туры китәр,
Аллаһ! – дигел, бәдавәм.

*Нәтиҗә:* Безнең Ислам динебез буенча, күкне, җирне, кешене – бөтен нәрсәне бар итүче, бөтен дөнья белән идарә итүче Аллаһыбызга тәүбә итү кирәк.

*3) Коръән сүрәләре буенча эш:* Тәүбә турында булган сүрәнең исемен һәм кайсы аятьләр икәнен билгеләп язабыз. Кем күбрәк таба?

*Коръән сүрәләре һәм аятьләре:* «Халык төркеме» сүрәсе, 53 аять; «Таһа» сүрәсе, 82 аять; «Сыер» сүрәсе, 37, 54, 172, 217, 279 аятьләр; «Нур» сүрәсе, 31, 63 аятьләр; «Тәһрим» сүрәсе, 8 аять; «Гыймран»

сүрәсе, 16-17, 101, 102, 132, 135, 136 аятьләр; «Фуркан» сүрәсе, 70 аять; «Касас» сүрәсе, 67 аять; «Тәүбә» сүрәсе, 14, 117 аять; «Әхзәб» сүрәсе, 73 аять; «Киңәш» сүрәсе, 25 аять; «Мәрьям» сүрәсе, 39, 60–61 аятьләр; «Хатыннар» сүрәсе, 17-18, 66-68, 146 аятьләр; «Нәсыр» сүрәсе; «Терлек» сүрәсе, 153 аять; «Мөэминнәр» сүрәсе, 51, 60, 99–100 аятьләр; «Мәидә» сүрәсе, 72 аять; «Табыш» сүрәсе, 38 аять; «Фатиха» сүрәсе, 5, 6-7 аятьләр; «Ниса» сүрәсе, 145 аять; «Аңлатылды» сүрәсе, 36 аять; «Һүд» сүрәсе, 114 аять; «Кәһаф» сүрәсе, 113 аять; «Дәрәҗә» сүрәсе, 27-28 аять; «Бәкарә» сүрәсе, 222 аять; «Шура» сүрәсе, 25 аять; «Рум» сүрәсе, 45 аять; «Нух» сүрәсе, 10-12 аять.

*4) тәүбә турында хәдисләрне табабыз, укып күрсәтәбез.* «Кем тизрәк?»

Хәдисләр:

1. «Гөнаһларыннан *тәүбә* итүчеләр гүя гөнаһлары юк кешеләр».

2. «Гөнаһларыннан *тәүбә* итүче кеше гөнаһсыз кеше мисалыннандыр».

3. «Үкенү – *тәүбә*».

4. «Дөнья мәшәкатьләре турында уйласаң – үлемне искә төшер. Гөнаһка тартылсаң – *тәүбәңне* уйла. Байлыкка ирешсәң – кыяматтә җавап бирәчәгеңне онытма. Ашарга утырсаң – ачлар турында искә төшер. Нәфесең мескеннәрне рәнҗетергә теләсә – сиңа карата Аллаһы Тәгаләнең көчен онытма».

5. «Кайда гына булсаң да, Аллаһтан чын курку белән курык. Бер бозыклык эшләсәң, артыннан ук яхшылык эшлә, бетерер ул гөнаһны. Бәндәләр арасында күркәм холыклы бул».

6. «Әҗәл җиткәнче тәүбә итәргә ашыгыгыз».

7. «Җәһәннәмдәге кешеләрнең күбесенең газабы тәүбәне кичектерүдәндер».

*Ике эш буенча да, иң тиз эшләгән, иң күп һәм иң тиз табучылар билгеләнә.*

**4. Йомгаклау.**

*5. Адәм баласы хатадан хали түгел, ә хаталы кешеләр арасында иң хәерлеләре кемнәр?*

Хаталары юк – сабырлы булмас.
Тәҗрибәсе юк – акыллы булмас.

Хаталы кешеләр арасында иң хәерлесе, эшләгән гөнаһлары өчен үкенүче, тәүбә иткән гөнаһларын яңадан кабатламаучы, гөнаһлы эшләрен Аллаһы Тәгаләдән куркып ташлап, гөнаһларыннан ваз кичеп тәүбә кылган кеше.

**5. Өйгә эш:**

1) тәүбә турында бер вәгазь табып сөйләргә әзерләнеп килергә;

2) тәүбә турында намазны өйрәнергә.

***Фәхертдинова Сөмбелә,***
*Тукай районы Теләнче-Тамак*
*«Мирас» мәчете каршындагы*
*якшәмбе мәдрәсәсе мөгаллимәсе*

## ДИН – КҮРКӘМ МӨГАМӘЛӘ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Дәреснең максаты:* дини кеше булып яшәүнең күркәм гадәт икәнлеген төшендерү.

*Җиһазлау:* интерактив тактада дәрес темасы буенча слайдлар күрсәтелә.

*Дәрес барышы:*

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

Дин – акыллы кешеләрне үз теләге һәм ихтыяры белән дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерә торган илаһи бер канун. Дин ул – адәм баласының дөньяга карашы, тоткан юлы. Димәк, динле кеше – юллы кеше, динсез милләт – юлсыз милләт. «...Нигъмәтнең иң зурсы – Ислам динедер, шөкер итүнең иң зурысы – Ислам динен дөрес тотудыр». [«Әнгам»: 53].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлламның якын иптәше (сәхәбә) һәм мөселманарның икенче хәлифәсе хәзрәти Гомәр сөйләгән: «Көннәрдән беркөнне, без Аллаһының Илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлам янында утырганда, безнең янга актан киенгән, кара чәчле бер кеше килде. Аны мосафир (юлчы), дип әйтеп булмый һәм аны безнең арадан берәү дә белми иде. Ул Мөхәммәд галәйһиссәламнең каршысына утырды да, учларын аның тезләренә куеп: «Мөхәммәд, нәрсә ул Ислам?» – дип сорады. Пәйгамбәребез аңа болай дип җавап бирде: «Ислам ул – бер Аллаһы Тәгаләдән башка һичбер Илаһ юк, Мөхәммәд – Аның колы һәм илчесе булуына ышану, шулай ук, намаз укуы, зәкят түләү, Рамазан аенда ураза тоту һәм, әгәр барырга мөмкинчелегең булса, Мәккәгә барып, хаҗ кылу». «Дөрес», – диде ир кеше. Шуннан соң ул: «Нәрсә

ул иман?» – дип сорады. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгаләгә, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә һәм тәкъдирнең яхшысы да, яманы : Аллаһыдан булуына иман китерүең (ышану)», – дип җавап бирде. Теге ир: «Бу да дөрес», – диде. Шуннан соң ул: «Нәрсә ул ихсан?» – дип сорады. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Синең Аллаһы Тәгаләгә – Аны күзең белән күреп торган кебек гыйбадәт кылуың, хәтта син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күреп тора, дип», – диде. «Дөрес», – диде әлеге кеше. Без аның үзе сорау биреп, җавап алгач, аның дөреслеген үзе үк раславына бик гаҗәпләндек. Әлеге кеше китеп барды. Ул киткәч, Мөхәммәд галәйһиссәлам озак вакыт уйга чумып утырды. Шуннан соң ул: «Гомәр, кем ул миннән сорау алган кеше, беләсеңме?» – дип сорады. Мин: «Белсә – Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесе генә белер», – дип җавап бирдем. Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Ул – Җәбраил фәрештә иде, сезгә динегезне өйрәтер өчен килгән», – диде.

Төркемнәрдә тикшерегез.

– Нәрсә ул ислам? (Җаваплар тактага һәм дәфтәрләргә язылa.)

– Бер Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Мөхәммәд галәйһиссәлам аның колы һәм илчесе икәнлегенә ышану; намаз уку, зәкят түләү, Рамазан аенда ураза тоту һәм хаҗ кылу (әгәр мөмкинлек булса).

– Нәрсә ул иман?

– Аллаһыга ышану; фәрештәләргә ышану; китапларга ышану; пәйгамбәрләргә ышану; Ахирәт көненә ышану; тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһыдан булуга ышану.

– Димәк, бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләячәкбез?

– Ислам дине турында.

**II. Уку мәсьәләсен чишү.**

Төркемнәрдә тикшерегез

**1 бирем.**

– Юлдан бару җиңелме яисә юлсыз җирдәнме?

– Юлдан, әлбәттә. Әгәр юл кагыйдәләрен яхшы белсәк, анда бертөрле дә каршылыклар булмый. Юл картасы буенча теләгән урынга барып җитәсең.

– Ә юлсыз җирдән барсак?

– Гел каршылыкка очрыйсың: урманнар, күлләр, елгалар, сазлыклар, далалар үтәргә туры килә. Бу куркыныч тудыра, көтелмәгән һәлакәткә юлыгуың бар. Шулай ук адашуың да мөмкин.

– Әгәр компас булса?

– Барып була, ләкин барыбер кыен.

– Әгәр тормышта ялгышсак, безне ни көтә?

– Тормышта ялгышу, адашу бозык эшләр эшләүгә китерә (эчүчелеккә, наркоманиягә, урлашуга һ.б.)

– Алардан ничек котылып була соң?

– Ихтыяр көче туплап, үз нәфесеңне җиңеп. Иң мөһиме – Аллаһыга инанып.

– Кешеләр өчен тормыш кагыйдәләре нинди китапларда тупланган?

– Коръәндә һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең хәдисләрендә.

– Коръән безгә кайдан һәм кем тарафыннан җиткерелгән?

– Аллаһы Тәгаләдән, Җәбраил фәрештә аша пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вәсәлламгә 610 елның Рамазан аенда Кадер кичәсендә «Галәк» сүрәсенең әүвәлге 5 нче аяте белән иңә башлый, 632 елда «Маидә» сүрәсенең 3 нче аяте белән тәмам була. Коръән 22 ел 2 ай 22 көн буена иңдерелә. Коръәндә 114 сүрә, 6666 аять бар.

«Менә бу китап. Анда һичбер шик-шөбһә юктыр. Ул мөттәкыйларга (дин кануннарын ихлас тотучы, Аллаһының җәзасыннан куркып, бозыклыктан, хыянәттән ваз кичүче саф мөселманнарга) юл күрсәтүче» [«Бәкара»: 2].

– Димәк, тормышта дөрес яшәү өчен без кемгә ышанып яшәргә тиешбез?

– Аллаһы Тәгаләгә һәм пәйгамбәрләргә.

– Менә бу ышану нәрсәнең нигезендә ята?

– Диннең.

– Нинди диннең?

– Ислам диненең.

– Ничек уйлыйсыз: шулай ышанып яшәү рәхәтме, җиңелме, әллә юкмы?

– Рәхәт, җиңел, әлбәттә. Чөнки син гомер буе Аллаһ белән буласың.

Үзбәя.

**2 бирем.**

– Дин ничә терәктә тора?

– Биш: иман, намаз, ураза, зәкят һәм хаҗ.

– Гыйбадәтне ничек аңлыйсыз?

– Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт – Аның кушканнарын үтәү һәм тыйганнарыннан тыелу.

– Балалар, мин сезгә «Аллаһының таләпләре» дигән гыйбрәтле хикәя укыйм. Фатыйма әтисе белән циркка барды. Клоуннар чыгышыннан соң төрле җәнлекләрне өйрәтүче (дрессировщик) чыкты. Җәнлекләр

өйрәтүченең чыбыркы тоткан кулына карап, төрледән-төрле трюклар ясадылар. Юлбарыслар, хәтта ки янып торган бөжра эченнән сикереп чыгып, тамашачыларны гаҗәпләндерделәр. Менә аренага зур гәүдәле филләр чыкты. Шулкадәр зур гәүдәле булсалар да, яннарында басып торган җыйнак кына гәүдәле өйрәтүченең барлык боерыкларын да үтәделәр. Кечкенә атлар-понилар да бик тырышлар икән. Алар күрсәткән номерларны да тамашачылар сокланып карадылар. Җәнлекләрнең һәммәсе дә бик тырышып өйрәтүченең боерыгын үтәделәр, моны күреп торган Фатыйманың исе китте. Өйгә кайткач, сүз шул хакта барды:

– Алар бит кеше шикелле үк акылга ия түгелләр, ә шулай да өйрәтүченең әмерен үти беләләр, – дип күңелендә туган уйларын әтисенә дә белгертте.

Чынлап та, хайваннар үзләренең өйрәтүчесенең боерыгын үтиләр, ә без – кешеләр, үзебезне яратучының әмерләрен үтибезме соң? – диде әтисе.

– Кем соң безнең Яратучыбыз? – дип сорап куйды кыз.

– Безнең Яратучыбыз – Аллаһ. Аллаһының безгә карата таләпләре бар.

– Бездән нәрсә таләп итә соң Ул?

– Беренче чиратта, Аны – Аллаһыны тануыбызны, яратуыбызны, Аңа гыйбадәт кылуыбызны, Аның Пәйгамбәре салләллаһу галәйһи вәсәлламгә ышануыбызны һәм ул өйрәткән юлдан баруыбызны. Шулай ук, Аллаһ безнең үрнәк һәм хакыйкый мөселман булуыбызны таләп итә.Төнлә йокларга яткач, Фатыйма бу сүзләр хакында бик озак уйланып ятты...

Сорау – җавап:

– Без, үзебезнең Яратучыбызга карата нинди мөгамәләдә булырга тиешбез?

– Без Аның барлык кушканнарын үтәргә тиешбез.

**III. Дәресне йомгаклау, укучыларның эчке кичерешләре белән танышу.** Бүген нәрсә өйрәндек? Нәрсә белдегез?

Ислам диненең максаты – ул югары әхлаклы шәхес тәрбияләү. Күркәм әхлак үрнәкләре ниндидер изгелекләрне даими рәвештә эшләүдән гыйбарәт. Адәм баласы изгелекләрне һәрвакыт кыла торгач, ниһаять, бу гамәлләре аның әхлагына әверелә. Башкалар аны шул күркәм гамәлләре белән таный башлыйлар. «Аллаһка вә Ахирәт көненә ышанганнар, игелеккә өндәүчеләр, яманлыктан ваз кичүчеләр, игелекле эшләрдә ярышучылар – менә шулар изгеләрдер» [«Әл-Гыймран»: 114].

**IV. Өйгә эш:**

1. Бүгенге дәресне, дәфтәрдән файдаланып өегездә әти-әниләрегезгә сөйләгез, фикер алышыгыз.

2. Дәрестә өйрәнгән аятьләрне, хәдисләрне ятлагыз.

**Әдәбият**

1. Җәлил хәзрәт дәресләре. – Казан, 2008. – 189 б.

2. Казыйханов В.С. Иман дәресләре (мәктәп балалары өчен уку әсбабы). – Казан, 2003. – 136 б.

3. Коръән: аятьләрнең татарча мәгънәләре [төрле галимнәрнең тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып матбугатка әзерләүче М.Р. Батулла, кереш сүз авт. Р. М. Мөхәммәтшин]. – Казан: Җыен, 2012. – 997 б.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Түбән Сөн авылы*
*мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## АКЫЛ БАЙЛЫГЫ ТУЗМАС БАЙЛЫК

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1) укучыларның интеллектуаль һәм креатив фикерләү сәләтләрен үстерү;

2) танып-белү эшчәнлеген үстерүгә юнәлтелгән күнекмәләр булдыру һәм продуктив иҗат югарылыгына күтәрелергә ярдәм итү.

3) аек акыл белән, *иманыбызга* тугры булып яшәгәндә генә тормышта куелган максатка ирешеп булуны раслау.

4) акылсызлыкның, *Аллаһыбызга* тугры була алмаган кеше тормышын – күңелсез хәлләргә китерүче сәбәпләрнең берсе икәнлеген аңлауларына ирешү.

*Бурычлар:* 1) укучы һәм укытучы арасында иҗади хезмәттәшлек булдыру; укучыны креатив эшчәнлеккә тарту.

*Дәрес барышы:*

**1. Кереш өлеш:**

*Укытучы:* Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ кадерле балалар! Без, бүген сезнең белән «Акыл байлыгы – тузмас байлык», – дигән дәресебезне башлап җибәрербез.

«Башкалардан үрнәк алучы кеше – бәхетле (**акыллы**) кеше. Бәхетсез (**акылсыз**) кеше – үзенең начар хәле белән башкаларга сабак бирүче кеше».

Мөхтәрәм балалар, мөселманнар! Бу хәдиснең мәгънәсе шулкадәр тирән ки, кеше аның тәфсирен сәгатьләр буе тыңлый ала. Акылы булган мөселман, яхшы кешеләрдән үрнәк ала һәм үз тормышында кулланырга тырыша. Шулай ук акыллы мөселман, башка кешенең начар гамәленнән сабак ала һәм үзен андыйдан сакларга тырыша. Начар кешеләрнең тискәре гамәлләре нәтиҗәләреннән ул үзен саклый. Башкача әйткәндә, акылы булган мөселман, үрнәкне һәм сабакларны башка кешеләрдән ала. Акылсыз һәм бәхетсез кеше, барлык начар гамәлләрне үзе кыла, ә соңыннан, тискәре нәтиҗәләрен күргәч, кайгыга бата. Аның күңеленнән тынычлык кача, гаиләсе, мал-мөлкәте таркала. Шул рәвешле ул, башкалар өчен сабак булып тора. Бары тик дин юлы белән генә тормыштан сабаклар алып була. Йөрәгендә иман булган кеше үрнәк һәм сабак алудан бәхет таба. Йөрәкләре иман тулы кешеләр, сабый бала гамәлләреннән дә үрнәк һәм сабак ала ала.

Мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) мәчеткә иртә килә торган була. Бервакыт ул кечкенә баланың иртән иртүк мәчеткә йөгерүен күрә. Мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү) бу баладан, аның мәчеткә йөгереп баруының сәбәбен сорый. Бала, болай дип җавап кайтара:

– Мин намазга ашыгам. Намаз вакыты якыная, ә мин тәһарәт алмаган. Азан әйтелгәнче, тәһарәт алып өлгерәсем килә.

– Син бит әле кечкенә, сиңа намаз уку фарыз түгел, – ди аңа мөхтәрәм Гомәр (радыйаллаһу ганһү).

– Намаз кылуда яшь аермасы бармыни? Кичә үлгән бала миннән кечерәк иде, – дип җавап бирә аңа бала.

Баланың бу сүзләре мөхтәрәм Гомәрнең (радыйаллаһу ганһү) күңеленә үтеп керә, ул елый башлый, хәтта күз яшьләреннән күлмәге юешләнә. Шуннан соң ул, болай ди:

– Я Аллаһ! Бу бала нинди яхшы һәм акыллы!

**2. Төп өлеш:**

*Укытучы:* Әйдәгез әле, балалар, без дә дәресебездә акыл турында сөйләшүебезне дәвам итик.

*1) Сорау-җавап рәвешендә әңгәмә.*

– Акыллы кешегә хас сыйфатларны санагыз. (Динебезне хөрмәт итә, Аллаһыбызга иман кыла, ныклы омтылыш белән яши, сер саклый белә, акыллы кешеләр белән дуслаша, үз вакытында тукталып кала белә.)

– Акыллы кеше ахмаклык эшли аламы? (Ала. Дүрт аяклы ат та абына. һ. б.)

– Яки киресенчә: ахмак акыллы эш эшли аламы? (Андый хәлләр дә була. Әйтик, ахмак мөһим мәсьәләләр хәл иткәндә дәшми калса һ. б.)

– Акыллы кеше хата ясаса, аңа күпчелек очракта игътибар итмиләр, ә ахмакның хатасын шундук күреп алалар. Ни өчен? (Чөнки акыллы ялгышса, бәлки, шулай дөрестер дип уйлыйлар, ә акылсызныкын монда инде юк-бар фикер дип уйлыйлар).

*2) Мәкальләр өстендә эш.*

– Акыллы кешеләр белән бәйләнешле мәкальләрне, әйтемнәрне искә төшерик әле.

Аз булса да, үз акылың булсын. Акчаңны югалтсаң да, акылыңны югалтма. Акыл белән алтын табыла, алтын белән акыл табылмый. Акыллы сүзен «мин» дип башламый. һ. б.

*3. Акылсызлык турында әңгәмә.*

– Акыллылыкның киресе нинди сүз була?

– Ахмаклык, акылсызлык, дивана, юләр, дурак, сантый, тиле, тинтәк, юньсез һ.б.

– Андыйлар турында нинди мәкаль-әйтемнәр беләсез?

– Ахмак башта эшләр, соңыннан уйлар (һинд). Ахмакны мактау боза (балкар). Акыллы үзен гаепләр, юләр – кешене (каракалпак). Ахмак белән аш ашама, акыллы белән таш ташы (уйгур). Түземсез акыллы булмый (һинд).

*4. Үз-үзеңә бәя кую, бәя бирү турында фикерләшү.*

– Борынгы гарәпләр ахмак булмас өчен дүрт нәрсәдән сакланырга кушканнар. Нәрсәләрдән дип уйлыйсыз?

1) Үзеңне генә яратудан һәм үз-үзеңнән бик канәгать булудан;

2) башкаларның хатасын эзләүдән;

3) үтә саранлык, үтә комсызлык күрсәтүдән;

4) үзеңнән түбән кешеләрнең киңәшеннән.

**3. Мөстәкыйль эш.**

Акыллы һәм акылсыз кешеләргә югарыда әйтелгән сыйфатларны файдаланып, үзеңдә нинди уңай сыйфатлар тәрбияләү, нинди кире сыйфатлардан котылу планын төзегез.

*План:*

1. Күп укырга. Һәр укыган әсәрдән аның уңай персонажларының яхшы сыйфатларын язып алырга, кире сыйфатларыннан тиешле нәтиҗә ясый белергә.

2. Үз холкындагы җитешсезлекләрне анализларга өйрәнергә, аларның нилектән килеп чыкканлыгының сәбәпләрен ачарга һәм бетерергә тырышырга.

3. Төшенкелеккә бирелмәскә. Һәр нәрсәне уйлап башкарырга. Юморны көндәлек юлдаш итеп алырга.

4. Өлкәннәрнең киңәшенә һәрчак колак салырга, үзеңнән кечкенәләрнең фикере белән дә хисаплаша белергә.

5. Кешеләрне нахакка рәнҗетүдән сакланырга. Кешенең нинди дә булса хатасын күрсәтүдән элек, аның урынына башта үзеңне куеп карарга өйрәнергә.

6. Әйтәсе фикереңне ачык һәм турыдан-туры әйтергә.

7. Көндәлек режим булдырырга һәм аның үтәлешен көн саен йоклап китәр алдыннан анализлый барырга.

8. Спорт белән даими шөгыльләнергә. («Сәламәт тәндә – сәламәт акыл»)

9. Ныклы ихтыяр көче тәрбияләргә.

**4. Халык педагогикасына таянып.**

*– татар халкының киң таралган фольклор әсәрләрнең берсе– мәкальләр.*

*Укытучы:* Мәкальләрдә ана телебезнең матурлыгы һәм камиллеге, төгәллеге һәм байлыгы гәүдәләнә. Халык үзе болай ди: «Әйтем-сүзнең бизәге, ә мәкаль– сүзнең җиләге».

Мәкальләр кешенең фикерләү сәләтен үстерә, акылын, тапкырлыгын тирәнәйтә, телгә мәхәббәт тәрбияли.

Мәкальләрдә халыкның әхлакый идеаллары, хезмәт сөючәнлеге, өлкәннәргә ихтирам, әдәплелек, дуслык, туган илгә булган чиксез мәхәббәте, дөреслек, сафлык кебек сыйфатлары чагылыш таба.

*1) Акыл турында халык мәкальләрен табу.*

Аз булса да, үз акылың булсын.

Айгырның алдыннан, ишәкнең артыннан, ахмакның һәр ягыннан сак бул.

Акча ярлысыннан акыл ярлысы яман.

Акчаңны югалтсаң да, акылыңны югалтма.

Акыл айнымас, алтын черемәс.

Акыл байлыгы тузмас байлык.

Акыл базарда сатылмый.

Акыл баскыч башында үсми.

Акыл белән алтын табыла, алтын белән акыл табылмый.

Акыл белән эш итү – мең бәланең калканы.

Акыл буй белән үлчәнми.

Акыл булмаса, алтын ни эшкә.

Акыл булса, юл бар.

Акыл – дәрья, уй – диңгез.

*2) мәкальләрне дәвам итәргә.*

Акыл келәт түгел, яңадан..........(салып булмый).

Акыл кемгә дә капчык белән.............(асмаган).

Акыл сакал белән бергә............(үсми).

Акыл – тезген, холык – ат, тезгенеңне...........(белеп тарт).

Акыл төбе –...............(тәҗрибә).

Акыл юлда............(чәчелеп ятмый).

Акыл яшьтә түгел,...............(башта).

**5. Йомгаклау.** Бүгенге дәрестә сез үзегезгә нинди сабаклар алдыгыз?

Үзенең «Тәрбияле бала» исемле китабында Р.Фәхреддин болай ди: «Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата-ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас.Тәрбияле бала җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер. Тәрбияле бала дөнья байлыгына бирелмәс, аны һәркем яратыр һәм мактап телгә алып сөйләр. Тәрбиясез баланы бер кеше дә яратмас».

Р. Фәхреддин сүзләренә нигезләнеп, шуны әйтәсем килә: **гаиләдә дөрес тәрбия алган бала гына акыллы була ала.**

Безнең динебез Ислам – гакыл дине. Ислам акыллы кешеләргә мөрәҗәгать итә. Ислам акыллы кешеләргә бурычлар йөкли. Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) болай дигән: «И, мөселманнар! Мөселман кардәше өчен үзенә яратканны яратмыйча, арагыздан берегез дә ышанучы булмаячак». Җир йөзендә, акылы була торып, үзенә начарны теләгән кеше юк. Шулай булгач, үзенә яхшылыкны теләгән мөселман башкаларга да яхшылык теләргә тиеш.

Аллаһ Раббыбыз барыбызга да үзенең кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүләребезне насыйп әйләсен. Амин.

**6. Өйгә эш:**

1. Үз-үзеңне тәрбияләү планын әти-әниеңә укып күрсәтергә. Өстәргә кирәк җирләре булса, өстәп язарга. Темага карата хәдисләр табып, язып килергә.

***Сәхәбиева Люция,***
*Теләче районы балалар иҗат үзәге мөгаллимәсе*

## АТА-АНАГА, ӨЛКӘННӘРГӘ ХӨРМӘТ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1. Ата-аналарны хөрмәтләүгә кагылышлы хикәяләр уку, хәдисләр өйрәнү.

2. Һәр укучыны гаиләсе белән таныштыру осталыгына ирешү.

3. Ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт хисе, мәхәббәт тәрбияләү.

*Җиһазлау:* Гаилә альбомнары, Р. Фәхреддин. «Нәсыйхәт», «Балаларга үгет-нәсыйхәт» китаплары, В.Казыйханов. «Иман дәресләре», Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин. «Бәхетлеләрнең серләре» китаплары.

*Дәрес барышы:*

I. Оештыру. Исәнләшү. Дәрескә йөрешне тикшерү.

II. Яңа материалны өйрәнү.

а)Укучылар, мин сезгә бер матур шигырь сөйләп күрсәтәм.

Бу бармагым – бабаем,
Бу бармагым – әбием,
Бу бармагым – әтием,
Бу бармагым – әнием,
Бу бармагым – мин илә.
Без барчабыз – дус.... нәрсә була?

*(Гаилә)*

Укучылар бүген дәрестә үзебезнең гаиләләребез турында сөйләшербез.

Гаилә ул – бик олы сүз. Без үзебезнең гаиләдә иң кирәкле, иң яраткан кеше итеп тоябыз. Әти, әни, әби-бабай – гаиләнең иң хөрмәтле кешеләре. Апа-абыйларыгыз сезнең өчен кайгырсалар, эне-сеңелләрегез сезнең ярдәмгә мохтаҗ. Гаиләдә кешеләр бер-берсен кайгыртып, бер-берсенә таяныч булырга тиеш.

Ә хәзер үзегезнең гаиләләрегез турында сөйләшик әле. Өегездәге кешеләр турында ниләр әйтә аласыз, алар яхшымы, сез аларга булышасызмы, бигрәк тә кемнәрне яратасыз? Ни өчен?

Өй эше итеп бирелгән «Минем гаиләм иң әйбәте» дигән иҗади эшләрне ничек үтәдегез икән? Тыңлап китик әле.

*Балалар үз гаиләләре турында сөйлиләр. Гаилә альбомнары күрсәтәләр.*

Менә без, сезнең әти-әниләрегез белән таныштык та инде. Аларның кем булып эшләүләре, гаиләгездә барлыгы ничәү икәнегезне белдек. Ә аларны без ни дәрәҗәдә хөрмәт итәбез соң?

– *Әти-әниләргә өйдәге эшләрдә булышабыз.*

– *Әйткән сүзләрен тыңлыйбыз.*

– *Авырткан вакытларында хәлләрен сорашабыз.*

– *Үзебезнең яхшы укуыбыз белән сөендерәбез.*

– *Тәрбияле булырга тырышабыз*.

(«Балаларга үгет-нәсыйхәт» китабыннан өстәмәләр)

– Әйе, бик дөрес укучылар әгәр дә без боларның барчасын да үтәсәк, иманлы бала булачакбыз.

б) Ислам динендә дә ата-ананы хөрмәтләүгә кагылышлы хәдисләр бик күп. Пәйгамбәребезнең берничә хәдисен сезгә дә укып китәм.

*«Җәннәт –аналарның аяк астында»*

*«Әниләргә беркайчан да, «уф» димәгез»*

*«Әниең, әниең, әниең, аннан соң гына әтиең»*

(Мәгънәләре аңлатыла.)

Бу хәдисләрдән аңлашылганча, әниләр иң бөек кешеләр, аларны без иң беренче урынга куеп хөрмәт итәргә, ярдәм итәргә, үзебезнең авырлыкларыбызны алардан башка да җиңәргә өйрәнергә тиешбез.

Укучылар, бүген без тагы бер хәдисне өйрәнербез, әйдәгез дәфтәрләргә шуны языйк. *(Тактада һәм дәфтәрләрдә языла.)*

**«Аллаһның ризалыгы әти-әниеңнең ризалыгында, Аллаһның ачуы, әти-әниеңнең ачуында».**

Бу хәдистә, Аллаһның ризалыгы ата-аналарның ризалыгы белән бәйләнгән. Әйе, әти-әниләребезнең хакы бик зур. Беренчедән : алар балаларына тормыш бүләк итәләр.

Икенчедән: әни кеше төннәр буе йокламыйча, баласы авыру чакларында, хәсрәтләнеп, борчылып дәвалый. Зур өметләр белән баласын үстерәләр, тәрбиялиләр, укыталар, гыйлем өйрәтәләр, кеше итәләр.

Инде зур үсеп, гыйлем, белем ияләре булып җиткәч, газиз әнисен тыңламаса, ихтирам итмәсә, моннан да зур әхлаксызлыкның булуы мөмкин түгел. Безнең һәр гамәлебезне күзәтүче Аллаһ барлыгын да онытмыйк.

в) Ә без укучылар, әти-әниләребезнең изге догалары, ризалыкларын ала алсак иде дә, бәхетле бәндәләр булсак иде. Сезнең «Әнкәмнең догалары» дигән җырны ишеткәнегез бармы?

Әйдәгез, шул җырны тыңлап китик әле. (Җырга анализ ясала.)

III. Материалны ныгыту.

в) Укучылар, без әле генә гаиләнең ныклыгын, ихтирамлылыкны дини юнәлештә карап үттек, шулай бит. Ә хәзер безнең хәзрәтләребез, галимнәребез, язучыларыбызның хикмәтле хикәяләрен тыңлап китик, алар киләчәктә нинди әхлаклы, изге күңелле, игелекле яшьләр яшәвен телиләр икән, тыңлыйк әле.

*Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин «Бәхетлелеәрнең серләре» китабыннан «Бер стакан сөт» хикәясе укыла. (Укучылар белән әңгәмә.)*

*Нәтиҗә:*

*1. Дөрес балалар, һәрбер ата-ана да бу егет кебек игелекле бала үстерергә хыяллана. Бу егет үз гаиләсенә генә түгел, тирә-юньдәгеләргә дә яхшылык кылды. Чынлап караганда, без гаиләдә генә түгел тормышта адәм балалары белән дә туганнар бит.*

*2. «Зилзәләһ» сүрәсендә әйтелгәнчә, тузан бөртеге кадәр генә яхшылыкны әти-әниләргә һәм башкаларга да эшләсәк, аны киләчәктә күрәчәкбез. Шулай ук тузан бөртеге кадәр начарлык кылсак та, шулай ук күрәчәкбез. Бу сүзләр безнең тормыш девизына әйләнергә тиеш.*

Укучылар дәресебезнең ахырында бер бик матур шигырь укып китәсем килә.

Аш кашыгы – агачтан,
Чәй кашыгы – көмештән.
Җиз самавар кайнап тора –
Сау изге инештән.
Әбием белән әнием
Безгә бәлеш пешергән
Бәлеш уңган күрәсең,
Өйгә тәмле ис тулган.
Әби-бабай, әти-әни,
Мин, нәни кыз, Наилә.
Менә нинди сокландыргыч
Безнең матур гаилә!

Илебездәге тыныч тормышны без гаиләләребездән башлыйбыз. Барыбызның гаиләләрендә дә шундый бердәмлек, хөрмәт итүчәнлек бетмәсен. Әти-әниләргә, туганнарга һәм, гомумән, игелекле гамәлләрне күбрәк кылырга тырышыйк, Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәрсә язсын, шулай эшләсәк иманыбыз да ныгыр, бәхетле тормышта да яшәрбез.

Сезгә бүгенге дәрес ошадымы, үзегезгә нинди яңа фикерләр тупладыгыз? Әхлагыбызны арттыру өстендәниләр эшләргә кирәк диеп уйлыйсыз?

*(Укучылар фикере.)*

*Өйгә эш: Сезнең әби-бабаларыгыз кемнәр булды икән, әти-әниләрегездән сорашып, гаилә шәҗәрәгезне төзеп килегез.*

*Дәрес тәмам.*

**_Вагизова Әлфия,_**
*Мамадыш шәһәре мәчете*
*каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## АГАЧ – ҖИМЕШЕ БЕЛӘН, КЕШЕ – ХЕЗМӘТЕ БЕЛӘН МАТУР

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1. Укучыларны «Агач – җимеше белән, кеше хезмәте белән матур» дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта үз урыннарын табарга ярдәм итү.

2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.

Эпиграф: **_«Эш – кешенең гомерендә иң әһәмиятле нәрсә. Бөтен күңелсезлекләрдән, кайгылардан коткаручы бердәнбер чара – ул эш»_** /Америка язучысы Эрнест Хемингуэй/

*Дәрес барышы:*

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

– Әкиятне тыңлагыз, ул бүгенге дәреснең темасын ачыкларга ярдәм итәчәк.

*Ананың ике кызы булган. Берсе тырыш, хезмәт сөючән, икенчесе – ялкау. Беренчесе, армый-талмый әнисенә булышкан, икенчесе – аз гына эшләп ала да, я уйный, я диванга ятып йокыга китә. Ыршып та караганнар аны – файдасы булмаган. «Бер көн булса да ял иттермисез мине!» – диеп зарланган.*

*Тылсымчы бабайдан киңәш сорагач, ул әнисенә кызын бер көн ял иттерергә кушкан һәм болай дигән: «Ялкауга менә шушы тылсымлы татлы чикләвекне бирерсең.Ул, кызыңны бөтен эштән азат итәр: ни*

*эшли, ни сөйли, ни уйлый, хәтта ашый да алмас – калак каптырып ашатырсыз – бер көнгә түзәрсез инде. Борчылмагыз – чикләвекнең тылсымы бер көнлек кенә – рәхәтләнеп ял итсен».*

*«Эшсезлек ялкауны тырышлыкка йөрәтә алыр микән?» – диеп уйласа да, – әнисе тылсымлы чикләвекне кызына биреп, аңа көне буе ял итеп, диванда ятарга рөхсәт иткән. И сөенде моңа кыз, и сөенде! Көне буе диванда ятып, күзләрен мөлт-мөлт китерүдән артык бернәрсә эшли алмады, хәтта ашатуын калактан каптырып ашатканнар аны.*

*Икенче көнне ялкау кыз иң беренче торып, эшкә тотынган: идән себергән, мичкә яккан, тәмле ботка пешергән. Әнисе: «Кызым, бераз ял ит», – дигәнгә: «Кичә ял итеп арып беттем. Көне буе ятып торудан авыррак эш юк икән, әнием!» – диеп җавап биргән. (Александра Лопатина.)*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

– Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Намуслы хезмәт турында.)

– Әйе, укучылар, бүгенге дәресебезнең темасы: Агач – җимеше белән, кеше хезмәте белән матур.

– Әкияткә нинди исем куштыгыз? (Хезмәтсез яшәп булмый.)

– Сез ялкау кызга нинди үгет– нәсыйхәт бирер идегез? (Җаваплар.)

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

**1 бирем.** «Хезмәт куймыйча гына яшәп буламы? Ни өчен?» дигән сорауларга җавап табу.

**2 бирем.** ***Уен «Мин башлыйм, син дәвам ит»***

(Мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

– Данның төбе – хөрмәт, хөрмәтнең төбе – хезмәт! Кеше хезмәте белән матур һәм хөрмәткә лаеклы. Яшәүнең бер мәгънәсе – хезмәт! Бу һәрвакыт шулай булган һәм шулай булачак та. Шуңа күрә дә халык телендә хезмәт турында бик күп мәкаләләр ишетергә була. Әйдәгез әле, укучылар, аларны искә төшерик. Мин сезгә мәкаләнең башын әйтәм, сез дәвам итегез.

– Уйлый торыгыз: кайсы мәкальне әлеге ялкау кызга киңәш итеп әйтер идегез?

Ялкау кеше – ярты кеше, уңган кеше –... *алтын кеше.*

Ялкаулык – гомерне кыскарттырган... *агу.*

Бер кечкенә ялкаулык зур... *кайгыга китерә.*

Кем эшләми,.. *шул ашамый.*

Агач – җимеше белән, кеше –... *хезмәте белән матур.*

Агачны яфрак бизәсә, кешене... *хезмәт бизи.*

Аз сөйлә, күп... *эшлә.*

Ашаганың белән мактанма,... *эшең белән мактан.*

Бүгенге эшне иртәгәгә... *калдырма.*

Ике уйла, бер...*эшлә.*

Калган эшкә... *кар ява.*

Карама кешенең сүзенә, кара... *эшенә.*

Маңгай тире эшнең сыйфатын... *яхшырта.*

Плансыз эш – ...*тозсыз аш.*

Син эшне сөйсәң, эш тә... *сине сөяр.*

Сөйләп күрсәткәнче,... *эшләп күрсәт.*

Хезмәт төбе – ... *хәзинә.*

Хезмәте каты –... *җимеше татлы.*

Яратмаган эш... *авыр була*

– Кайсы мәкальне әлеге ялкау кызга киңәш итеп әйтер идегез? (*Агач җимеше белән, кеше – хезмәте белән матур. Син эшне сөйсәң, эш тә сине сөяр).*

**3 бирем.** ***Бер эксперимент нәтиҗәсе***.

– Хезмәтсез яшәп булмый, диләр. Бу чыннан да шулаймы икәнен белер өчен, бер эксперимент нәтиҗәсе белән танышып китик:

*– 15 ел элек Мәскәүдә бер гаҗәеп эксперимент уздырылган булган. Анда катнашкан 30 кеше бернәрсә эшләмәскә, бары тик 30 көне буена түшәктә ятып торырга тиеш булган: ашар эчен дә торырга рөхсәт булмаган – нәкъ алдагы әкияттәге шикелле.*

*Беренче атнада ук боларга чыдамыйча, 13 кеше эксперименттан чыга һәм аның ахырына кадәр бердәнбер кеше генә барып җитә. Экспериментның нәтиҗәсе: хәрәкәтсезлек кешенең сәламәтлеген нык какшата. Бөтен приборлар, анализлар күрсәткечләре шуны раслый.*

– Ни өчен, сезнеңчә, хезмәтсез яшәп булмый? *(җаваплар)*

– Нинди кеше генә башлаган эшне ахырына кадәр җиткерә ала? (уңган, тырыш, белемле, кечле).

**4 бирем.** ***Танылган шәхесләр фикерләре:***

– Тормышта эшлисе килмәгән чаклар буламы?

– Нинди чаклар алар?

– Күңел төшкән, эч пошкан, сагышлы чаклар.

– Ә аннан ничек котылырга? /җаваплар/ (Бары тик эш эшләп.)

– Сезнең җавапларны танылган шәхесләр фикерләре белән чагыштырыйк:

• *Эш – кешенең гомерендә иң әһәмиятле нәрсә. Бөтен күңелсезлекләрдән, кайгылардан коткаручы бердәнбер чара – ул эш.* /Америка язучысы Эрнест Хемингуэй /

• Э. Хэмингуэй сүзләрен ничек аңлыйсыз?

• *Хезмәт... Эшләгәндә үземне шундый бәхетле итеп хис итәм.*

• / Рус язучысы Толстой Л. Н /.

• Л.Н. Толстойның сүзләрен ничек аңлыйсыз?

• *Эшләрне күркәм итеп башкаручыларны Аллаһы Тәгалә сөяр*. / Хәдис /

**5 бирем «Эшләрне күркәм итеп башкаручылар».**

«Күркәм итеп башкаручыларны» дигәнне ничек аңлыйсыз? (Әйбәт, мактауга лаеклы.)

– Башкаларга карата мөнәсәбәтенә һәм хезмәтенә карап кешегә бәя бирәбез.

Кеше хезмәткә төрлечә карарга мөмкин. Кем өчендер ул вакытны һәм көчне сарыф итүче мәшәкать кенә. Мондый кешеләр тормышны бушка вакыт уздыруга санйылар.

• *Иң мөхиме, эшеңне яратырга һәм нәтиҗәсе мөмкин кадәр камил рәвештә булсын өчен тырышырга кирәк.*

• Хезмәтеңнең кемгә дә булса кирәк булуын белү һәм аннан сөенеч алу үзенә күрә бер бәхет.

• Күбегезнең игътибар иткәне бардыр – кемнең дә булса үзенең эшен күңел биреп башкарганын. Мәсәлән, игенчеләрнең хезмәт куюлары, төзүченең берсеннән-берсе матур йортлар җиткерүе.

• Әгәр дә кеше эшен күңел биреп башкара икән, ул үзе дә хезмәтеннән ләззәт таба, башкаларга да сөенеч китерә.

• Сезнең туганнар, дуслар, танышлар арасында булган андый тырыш кешеләрне искә төшерегез.

• Без гүзәл дөньяда яшибез. Безнең әйләнә-тирәбездә табигать һәм кеше хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән матур бер дөнья. Җирнең төп зиннәте – ул акыллы, мәрхәмәтле, хезмәт сөючән кеше. Әгәр барча кешеләр дә шундый булсалар дөньябыз тагын да гүзәлрәк булыр иде.

• Кеше үзеннән соң башкаларга да файда китерә торган игелекләр калдырыга тиеш.

• Шул чакта ул үзеннән соң яхшы хатирәләр калдырачак. Халык мәкалендә әйтелгәнчә: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә дә балык белер».

• *Игелекләребез ул – безнең яхшы гамәлләребез, хезмәтләребез һәм рухи байлыгыбыз.* Ә рухи байлык ул – безнең хезмәт сөючәнлегебез нәтиҗәсе.

Эштән эшкә сикермә,
Сайла менә бу җирдә
Күңел сөйгән һөнәрне.
Дуслар, тагын сезгә
Бар әйтәсе бер сүзем.
Нинди һөнәр сайласаң да,
Кирәк беренче белем.
Эзлән, яшь дус, эшең калсын җирдә,
Кечкенәме, зурмы – барыбер.
Тар булса да яңа сукмак яса,
Тарны киңәйтүче табылыр.

**6 бирем.** ***Безнең киңәшләр:***

– Һөнәр турында уйланып йөрүче иптәшегезгә нинди киңәшләр бирер идегез?

/Җаваплар/

– Сезнең фикерләрегезне безнең киңәшләр белән чагыштырыйк:

• Һөнәр сайлау – язмышны сайлау шикелле.

• Кайсы өлкәдә сәләт бирелгән икән, аны үстереп һөнәр сайла.

• Яхшы уку – булачак һөнәргә иң ышанычлы нигез.

• Сайлаган эш күңелеңә хуш килсен, ошасын.

• Эшеңне яратырга һәм нәтиҗәсе мөмкин кадәр камил рәвештә булсын өчен тырышырга кирәк.

• Башкаларга да файда китерә торган һөнәр генә сине бәхетле итәр.

• Үз-үзенә ышанган кеше таулар күчерергә дә үзендә көч таба. Ышану ул – җиңү дигән сүз. Кайсы бала – укуда, кайсы – спортта, кайсы – хезмәттә оста була. Булдыксыз бала юк.

– Бу җәһәттән, хезмәткә һәм гади хезмәт кешесенә хөрмәт белән карау бигрәк тә мөһим. Бүген җәмгыятебездә физик хезмәткә кимсетүле караш, ул – акыл сәләте түбән булган кешеләр шөгыле, дип карау киң таралган. Әмма илнең байлыгы – намуслы хезмәт нәтиҗәсе.

**7 бирем.** ***Хәдисләр***

– Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисен укып, үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) әйтә:

• *Эшли белмәгән кешегә эш тапшырылса, кыямәт кубасын көтеп торсыннар.*

**8 бирем.** ***«Һөнәр – бер агым судыр вә ышанычлы дәүләттер».***

– Каюм Насыйри үзенең «Китаб-әт-тәрбия»сендә: «...һөнәр – бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер», – дип язган. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

/җаваплар/

– Кешегә кайсыдыр өлкәдә сәләт бирелгән икән, аңа шул ягын күреп, үстереп, аның булдыклы икәнен, җәмгыятькә кирәк икәнен төшендерү мөһим. Һәркем үзенә яраклы, ошаган хезмәт төрен, һөнәр сайларга тиеш. Тормышта үз юлыңны табу – булачак һөнәреңне дөрес сайлауга бәйле. Яратып башкарган эш кенә яшәешне мәгънәле итә. Синең хезмәтеңнең башкаларга кирәк булуын тою – олы бәхет ул. «...һөнәр – бер агым судыр, вә ышанычлы дәүләттер».

**9 бирем.** ***Булачак һөнәргә каршы 7 адым***

1. Сиңа ошаган һөнәрләрнең исемлеген төзе. Кайсылары характерыңа, сәләтеңә туры киләләр, күңелеңә күбрәк ошыйлар.

2. Сайлаган һөнәргә карата төп таләпләр исемлеге.

3. Үзеңнең профессиягә карата булган таләпләр:

– һөнәр – аның илгә, кешеләргә файдасы;

– һөнәр – минем сәләтләрем;

– һөнәр – минем булачак вазифаларым;

– һөнәр – эшкә урнашу мәсьәләсе;

– һөнәр – минем булачак хезмәт хакым;

– һөнәр – минем яшәү максатым.

4. Исемлектә булган бөтен пунктларга туры килә торган һөнәрне ачыклау (һөнәр сиңа һәм син аңа туры килүе буенча).

5. Нәтиҗәгә килгәннән соң әти-әниләр, укытучылар, дуслар, психолог белән киңәшләш.

6. Һөнәр сайланган – бөтен көчеңне максатка юнәлдер:

– уку йортын сайла;

– әһәмиятле сыйфатларыңны үстерү өстендә эшлә;

– кирәкле уку фәннәрне тирәнтен өйрән;

– шул юнәлештәге практик эшне башкарып кара (табиблыкка– кешеләргә беренче ярдәм күрсәтүдә катнаш, укытучылыкка – вожатый булып эшләп кара...);

– үзеңнең «конкурентоспособность»не (иң яхшы белгеч булуга омтылышны) арттыру турында хәзер үк уйла.

7. Сиңа туры килә торган икенче һөнәрне «запаста» тот.

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

– Дәреснең темасын искә төшерегез.

– Агач – җимеше белән, кеше хезмәте белән матур. Хезмәткә карата нинди гыйбрәтләр алдыгыз? ***(«Эш – кешенең гомерендә иң әһәмиятле нәрсә. Бөтен күңелсезлекләрдән, кайгылардан коткаручы бердәнбер чара – ул эш»*** /Америка язучысы Эрнест Хемингуэй / ).

– Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграфы итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчан да онытмыйк. Хор белән укыйлар: «Эш – кешенең гомерендә иң әһәмиятле нәрсә. Бөтен күңелсезлекләрдән, кайгылардан коткаручы бердәнбер чара – ул эш». – Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? («Эшләрне күркәм итеп башкаручыларны Аллаһы Тәгалә сөяр.»)

– Димәк, Аллагы Тәгаләнең ризалыгын алыр өчен, бәхетле булыр өчен, авырлыкларны җиңәр өчен һәрбер эшне тырышып башкарырга кирәк. Һөнәрнең кешеләргә күбрәк файда китерә торганын, үзеңә ошый торганын сайларга кирәк.

**VI. Өйгә эш:**

Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. «Агач – җимеше белән, кеше хезмәте белән матур» дигән темага җавап әзерләп килергә.

2. Нәселегездә тырыш хезмәте белән хөрмәткә лаеклы булган туганнарны барлагыз. Аларның кайсы якларын син үзенә үрнәк итеп аласың?

3. Эш, хезмәт турында хикәя, хәдисләрне эзләп табу.

***Вагизова Әлфия,***
*Мамадыш шәһәре мәчете*
*каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## АКЫЛЛЫ КЕШЕ ЯЛГЫШАМЫ?

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

– акыллы кешенең гомере кеше хаталарын өйрәнүгә китүен аңларга ирешүе;

– акыл – бөек хәзинә икәнлеген исбатлау;

– акыл турында халык әйтемнәре, мәкальләре белән таныштыру;

– үз-үзләренә бәя бирә белү өстендә эшне дәвам итү.

Эпиграф: ***Киңәш бирергә була, ләкин шул киңәшне куллану өчен акыл биреп булмый. (Франсуа де Ларошфуко)***

*Дәрес барышы:*

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

– Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Акыл иясе булган Сөләйман патша янына ике ана килгән. Хатыннар берүк йортта яшәгәннәр. Аларның икесендә дә бер яшьтәге ир балалар булган. Бер ана узган төндә баласын таптап үтергән дә, аны икенче хатын янына салып, исән баланы үзе янына алган һәм: «Бала минеке», – дип дәгъвалаган. Икенче хатын, бу сүзләр – бары тик ялган дип тукып тора. Аналар бер-берсен алдауда гаеплиләр.*

*Сөләймән патша колычны алып килеп, аның белән баланы чабарга һәм яртысын бер анага, яртысын икенче анага бирергә куша. Чын ана елый башлый, борчыла, улын исән килеш үзенә бирүен үтенә. Ә икенчесе: «Миңа булмагач, аңа да булмасын!» – дип, чабарга рөхсәт итә.*

*Шулай итеп Сөләймән патша чын ана улын исән калдырырга үтенгән хатын икәнен ачыклый һәм баласын үзенә бирдерә.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

– Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Акыллы кеше турында)

**III.** Уку мәсьәләсен чишү. Төркемнәрдә эшләү.

**1 бирем.** ***«Син әдәпне кемнән өйрәндең?»***

– Хәзер сезгә гыйбрәтле өзек тәкъдим итәм. Тыңлагач, хикәягә исем кушарсыз.

*Локман хәкимнән сорадылар: «Син әдәпне кемнән өйрәндең?– диделәр. Локман әйтте: «Әдәпсезләрнең әдәпсезлеген күреп, үземә килешмәгән кебек булды да, һаман андый эшләрдән саклана килдем, «әдәпле булдым» – диде. Әй угыл, гакыллы балага атлам саен гыйбрәтләр бар, вәгазьләр бар, шуны күрә бел» (К.Насыйри, «Китаб-әт-тәрбия, 16 нчы тәрбия).*

– Локман хәким акыллы булырга кемнән өйрәнгән?

– Акыллыларның хаталанулары мөмкинме?

– Мөмкин, әлбәттә.

– Хикәягә нинди исем куштыгыз?

– Әсәрнең төп фикерен ничек аңлыйсыз?

**2 бирем.** ***«Акыллы кеше ясаган хата»***

– Акыллы кеше ясаган хата белән акылсыз кеше ясаган хата арасында нинди аерма бар?

– Акыллы кеше дә ялгыша, әлбәттә, ләкин ул һәр хаталанган саен яңа хата ясый, ә акылсыз кеше исә бер үк хатасын кабатлый. Үз-үзеңә бәя кую.

**3 бирем.** ***«Акыллы кеше үз вакытында туктала белә».***

– «*Акыллы кеше уз вакытында туктала белә*» – дигәннәр борынгы кытайлылар. Сез моны ничек аңлыйсыз?

– Кеше моңа үз акылы белән ирешә ала. Мондый очракта беркем дә ярдәм итми, ул үз хатасын, үз житешсезлекләрен үзе төзәтә. Андый кеше үз-үзе белән идарә итә белә, үз-үзен контрольдә тота, үз-үзенә коррекция ясый (үз тәртибенә үзе үзгәрешләр кертү сәләтенә ия һ.б.)

Үз-үзеңә бәя кую.

**4 бирем.** ***«Хаталарны ничек ясамаска?»***

– «Хаталарны ничек ясамаска?» дигән сорауга җавап табып карыйк.

/Укучылар җаваплары/

**5 уен.** ***«Мин башлыйм, син дәвам ит».***

(Тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә.)

– Хәзер уен уйнап алыйк! Сыйфатларны мин әйтә башлыйм – сез дәвам итәрсез.

1. Акыллы, яхшы кешеләр белән генә... *аралаш, дус бул.*
2. Бәхәстән, тарткалашудан... *ерак булырга тырыш.*
3. Кешеләрнең начар холыкларын... *кичерә бел.*
4. Ачык йөзле, елмаючан... *булырга тырыш.*
5. Дошманлык хисләр синнән... *ерак булсыннар.*
6. Кеше кимчелеген эзләп, тикшереп гомереңне... *әрәм итмә.*
7. Беркайчан да... *зарланма.*
8. Үзеңдә матур, үрнәк холык...*тәрбияләргә тырыш.*
9. Кешеләр белән аралашканда «кирегә сукалама», сүз саен... *каршы килмә.*
10. Кешене гаепләгәнче – барысын да... *төшен.*
11. Синнән сорамаганда, сиңа кагылмаган эшкә... *«тыгылма».*
12. Үзеңне генә түгел, башкаларны да... *«тыңлый, ишетә» бел.*
13. Үзеңне кешеләрдән акыллырак итеп... *күрсәтергә тырышма*, син генә һәрвакыт дөрес дип... *исәпләмә.*

**6 бирем.** ***«Чагыштырыйк әле!»***

– Сезнең җавапларыгызны безнең фикерләр белән чагыштырыйк:

- Эшкә тотынганчы, ныклап уйла – нәтиҗәсен күз алдыңа китер.
- Әти-әниләр, укытучылар, дуслар белән киңәшләш.
- Эш өчен җаваплы кеше буларак, карарны үзең кабул ит.

• Хаталарыңны таный бел һәм вакытында төзәт.

• Хаталарыңны күрсәткән кешегә үпкәләмә – төзәтергә тырыш.

• Үз хаталарыңны кабатламаска тырыш.

• Кешеләрне күзәт – аларның хаталарында кабатлама.

**7 бирем.** ***«Танылган шәхесләргә сүз бирик».***

• Акыллы кеше күңел ачу чаралары артыннан түгел, ә үзенә күңелсезлекләр китерми торган әйберләрне булдыру артыннан чаба. (Аристотель)

• Кыска акылның теле озын. (Аристофан)

• Саадидан сораганнар: «Син кемнән әдәплелеккә өйрәндең? – «Әдәпсезләрдән», – диеп җавап биргән ул. – Мин алар эшләгәнне эшләмәскә тырыштым». (Саади)

• Яхшылыкка караганда кимчелекләргә өйрәнүе күпкә җиңел.

(К. Станиславский)

**8 бирем** ***«Акыллы кешенең 13 киңәше»:***

– Киңәшне дәвам итегез.

1. Акыллы кеше күбрәк тыңлап тора, әзрәк... сөйләшә.

2. Акыллы кеше бөтен ситуациядә башта «плюсларны»... эзли, аннары «минусларны»... исәпли.

3. Акыллы кеше күңелендә булганын башкаларга ахырына кадәр... ачмый.

4. Акыллы кеше белемен кайчан һәм ничек итеп кулланырга икәнен... яхшы белә.

5. Акыллы кеше башка кеше белән булган проблемаларын үзе... хәл итәргә тырыша, 3нче кешене... катнаштырмый.

6. Акыллы кеше башкаларны... гаепләми, хурламый.

7. Акыллы кеше гаепне, үземдә түгел микән...дип уйлый.

8. Акыллы кеше һәр эшкә бар көчен... кулланып эшли.

9. Акыллы кеше башкарасы эшкә алдан... әзерләнә, аны планлаштыра, булачак авырлыкларга... әзер була.

10. Акыллы кеше башкаларның фикерен... тыңлый, үзенчә... эшли. Үз фикере ялгыш икәненә төшенсә – аны... дөресли, үзгәртә.

11. Акыллы кеше Аллаһы Тәгалә биргән мөмкинлекләрне кулдан... очкындырмый, белемен, сәләтен... куллана.

12. Акыллы кеше аңа бирерлгән саулыкның... кадерен белә.

13. Акыллы кеше уңышсызлыкларны уңай тәҗрибә итеп... кабул итә.

**9 бирем. Хикмәт иясе булган чын акыллы кешенең 10 сыйфаты:**

1. Аллаһ Тәгаләгә ышана, бөтен эшендә Аңа таяна.

2. Дөньясын алыр барганда, ахирәтенә кимчелек китерми, ахирәтен алып барганда, дөньясын да онытмый.

3. Изгелекне ярата, гөнаһлардан, файдасыз эшләрдән тыела.

4. Начарлыкка начарлык белән җавап бирми.

5. Ачуландырсалар ачу сакламый.

6. Акыллы сүзне игътибарсыз калдырмый, файдалы киңәш бирергә саранланмый.

7. Дөньяга һәм ахирәткә кагылышлы файдалы эшләргә ялкаулык күрсәтми.

8. Булганның кадерен белә, сынаулар килсә, зарланмый.

9. Кешеләрдә булган уңышларга карата хөсетләнми (көнләшми).

10. Туганнарын, дусларын, күршеләрен хөрмәт итә, игелек күрсәтә.

**V. Рефлексия** (Йомгаклау).

Дәреснең темасын искә тешерегез.

– Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? *(«*Хаталарыңны таный бел һәм вакытында төзәт. Хаталарыңны күрсәткән кешегә үпкәләмә– төзәтергә тырыш. Үз хаталарыңны кабатламаска тырыш. Кешеләрне күзәт – аларның хаталарында кабатлама.)

– ***«Киңәш бирергә була, ләкин шул киңәшне куллану өчен акыл биреп булмый. (Франсуа де Ларошфуко)***

**–** Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграф итеп тактага яздык.

**VI. Өйгә эш:**

Өй эшен вариантлап бирәбез:

1. «Гаиләдә нинди хаталарга юл куела?» дигән темага җавап әзерләп килергә.

2. «Хаталарны азрак ясар өчен, ни эшләргә? дигән темага җавап әзерләргә.

***Хөсәенова Венера,***
*Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы*
*БӨБ «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» әхлак укытучысы*

## ГАИЛӘ – БӘХЕТ ИШЕГЕ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1. Рәҗәп ае, Рәгаиб кичәсе турында белешмә бирү.
2. Гаилә әгъзаларына, әти-әни, әби-бабайларга, өлкәннәргә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү.
3. Гореф-гадәтләргә, гаилә традицияләренә, ядкарьләренә кызыксыну уяту, буыннар бәйләнеше, үз гаиләң белән горурлану хисләре тәрбияләү.

*Материал:*

1. «Тәрбиядән яраладыр тәрбия».
2. «Көч һәм рух тамырлары».
3. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр.
4. Җәлил хәзрәт Фазлыев. «Иманлы бала».
5. Атлас биографии пророка.
6. «Иманлы гаилә» газеты, ноябрь, 2012 ел.
7. «Мәгариф» №8, 2008 ел.
8. «Тәрбия» газеты, №1, 2014 ел.
9. «Дин вә мәгыйшәт» газеты, декабрь, 2014.
10. «Шура»дини альманах; №4, 2014.
11. «Балалар һәм ислам «Шамил Аляутдинов.

*Җиһазлау:* китап-шәҗәрәләр күргәзмәсе, видеопроектор, презентация, карточка.

*Дәреснең барышы:*

**I. Актуальләштерү.**

Сәламләү.

Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ. Һәр барчагызга Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын.

Хәерле көн, укучылар. Менә тагын яңа көн туды. Әти-әниләребезнең, туганнарыбызның, сыйныфташларыбызның исән булуына тагын бер кат сөендек. Әнә шундый сөенеч шатлыклар белән дәресебезне башлыйбыз. **(слайд)**

20 нче апрельдән һиҗри ел исәбе буенча ислам дөньясындагы 3 изге айның башы – Рәҗәп ае башланды. Шушы айның беренче җомгасына каршы кичә – Рәгаиб кичәсе була. Гарәбстан дигән илдә бик матур Мәккә шәһәре бар. (Слайд – карта-рәсемнәр күрсәтү.)

Шушы илнең Габдулла дигән егете, Әминә дигән кызга өйләнгән, гаилә корган. Бу кичә пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең әтисе белән әнисенең никахлашкан көнедер. Аларның баласы – Мөхәммәд туган. Мөхәммәд пәйгамбәр – кешеләрне яхшылыкка өйрәтүче. Бөтен балалар әйбәт, күркәм булсыннар, пәйгамбәребез кушканча яшәсеннәр, диеп бу көнне бәйрәм итәбез. Бу көн – Гаилә бәйрәме дип атала.

(Мөнәҗәт җырлау.) **Слайд.**

Бу айда кылган изгелек гамәлләрнең савабы зур. Рәҗәп аенда сада-калар бирү, мескеннәрне-фәкырьләрне шатландыру, «Ихлас» сүрәсен ешрак уку – күркәм гадәт.

(Бер бала «Ихлас»ны һәм мәгънәсен укый.)

**II. Төп өлеш. Уку мәсьәләсен кую.**

Ислам дине буенча һәр мөселман кешесе, 7 буынга кадәр әти-әнисе ягыннан булган бабаларының исемнәре тәртибен белеп, дога кылырга тиеш. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.нең нәселен карап үтик. (**Слайд: шәҗәрә пәйгамбәр.)**

Шәҗәрәне дәвам итсәк, 21 нче буын Гаднәнгә барып җитә. 21 дән Ибраһим г.с.гә кадәр. Бу шәҗәрәнең икенче өлеше.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бабасы Габделмоталлиб, оныгы тууын белгәч, бик сөенә, тизрәк аны күрергә ашыга, оныгын кулына алып үбә, шуннан сон аны саклык белән изге Кәгъбәтулла янына алып килә. Габделмоталлиб Аллага шөкер итә, онытгы өчен дога кыла, аннары аңа Мөхәммәд дип исем куша. Кешеләр: «Каян алдың бу исемне?» – дип сорыйлар. Габделмоталлиб әйтә: – «Мин өмет итәм, аны җирдә һәм күктә мактап торырлар», – дип.

Безнең эраның VI гасырында, бу дөньяга бөтен кеше өчен үрнәк, камил кеше җибәрелә – соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәлам. Бөек Аллаһ изге Коръәндә җирдәге һәм Ахирәттәге тормыш бәхетле булсын өчен, бар-лык кешеләргә пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә иярергә куша. Ул мул сулы елгалар койган диңгез кебек. Һәрбер кеше аның тормышын үзенә үрнәк итеп алырга мөмкин. **(Слайд Афзал бабасы турында.)**

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

Менә безнең мәктәптә дә үз нәселләрен кызыксынып тикшерүче укучыларыбыз бар. Үткәннәрне бәйләп торган нәсел җебе – нәсел тамы-

ры өзелмәсен. Яңа буыннар җиргә килә тора. Нәсел-нәсәбеңне онытмас өчен үзеңнең гаилә шәҗәрәсен белергә кирәк. Әгәр дә бабаларыбызны онытсак, берникадәр вакыттан сон безне дә онытырлар.

Мәңгелеккә үтеп бара торган
Кешелекнең без бер буыны,
Алып кара, өзеп ташлап кара,
Чылбырдагы безнең урынны!

Нәсел җебегез өзелмәсен, керләнмәсен дисәгез харам малдан, намус кушмаган эштән тыелып калыгыз. Шушы кагыйдәне үтәү, үз нәселең турында кайгырту була да инде. Үзегезнең нәсел агачына һичкайчан зыян салмагыз. Нәселегезгә хас булган күркәм гадәтләрне онытмагыз.

Без бүген Гаилә бәйрәме дидек. Гаиләле булу – бәхет. Гаилә – ул ил терәге. Гаилә – ул гомер чишмәсе. Гаилә – ул безнең өебез (әби-бабай, әти-әни, абый-апа, эне-сеңел).

Шигырь «Бик бәхетле бала мин».

Азат шигырь, «Ата-ана», М. Гафури.

Слайд (әти-әни – гаиләләр.)

Слайд – Коръән аятьләре, хәдисләр, мәкальләр.

Әби-бабайларыбызның балачагы бик авыр елларга туры килгән.

Бөек Ватан сугышы кешелек дөньясының астын-өскә китергән вакыйгалардан санала. Әлеге афәт дистәләрчә миллион кешене вакытыннан алда гүргә кертә. Миллионнарның күзенә кара кайгы пәрдәсе булып, энҗе яшьләр эленә.

Барлык мөселманнар җиһад – изге сугыш дип кабул итә. Мәскәүдән алып, Берлингача Европа киңлекләрендә ятып калган, яу кырында башын салган татар мөселман солдатларын без шәһит киткәннәр, дип әйтә алабыз. Алар пәйгамбәребез өйрәткәнчә, Ватан хакына гомерен корбан иткән, мөкаддәс җаннардан. Бүгенге матур көннәр хакына шәһит киткәннәрнең рухына дога кылыгыз, яуда һәлак булган кардәшләрегезне онытмагыз, Ватанны сакларга үзегез дә һәрчак әзер торыгыз, бу пәйгамбәребез васыяте. Ул исә: «Ватанны сөю иманнан», – дигән.

Мөселманнар үзләренең каһарманлыгы белән Ватанның тугры уллары һәм туган илдә тынычлык вә иминлек булсын өчен, гомерләрен дә бирергә әзер икәнлекләрен күрсәтте. Шуңа күрә бабаларыбызның үрнәген хәзерге буын заман мөселманнары да истә тотсын.

Слайд Ф. Әхкәмов.

Слайд И. Мәхмүтова.

**IV. Дәресне йомгаклау. Укучыларның эчке кичерешләре белән танышу.** Бүген нәрсә өйрәндек? Нәрсәләр белдегез? Үзегезгә нинди нәтиҗә ясадыгыз?

**V. Өйгә эш:**

1. Дәреснең эчтәлеген өйдә сөйләп бирегез.
2. Әл-Исра сүрәсе, 17/23-24 аятьләрне ятларга.

***Нургалиева Лилия,***
*Балтач районы БӨБ мәктәптән тыш*
*эшләр үзәге өстәмә белем педагогы*

## ГЫЙЛЕМ – НУР, НАДАНЛЫК – КАРАҢГЫЛЫК

*Максат:*

1. Кешенең аң-белемен үстерүдә укуның, тәҗрибәнең ролен күрсәтү, кешене кешелекле итеп тәрбияләүдәге кыйммәтен раслау.
2. Дөньяви һәм дини гыйлемнең бербөтен булуын төшендерү;
3. Сабырлык, ихтыяр көче, игътибарлылык тәрбияләү.

*Материал:*

1. В. Казыйханов. «Әхлак дәресләре».
2. «Көч һәм рух тамырлары».
3. «Тәрбиядән яраладыр тәрбия».
4. Җәлил хәзрәт Фазлыев. «101 вәгазь».
5. К. Насыйри. «Сайланма әсәрләр», 2 том.
6. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр.

*Җиһазлау:* китап күргәзмәсе; видеопроектор, карточка, таблицалар.

*Дәрес барышы:*

**I. Актуальләштерү.**

Сәламләү.

Хәерле көн, укучылар! Менә тагын яңа көн туды. Димәк, бу җирдә яшәүгә омтылышыбыз, теләгебез артты. Яңа көн туу белән, үзебезнең туган җиребездә бәхетле булуыбызга тагын бер кат инандык. Әти-әниләребезнең, туганнарыбызның, сыйныфташларыбызның исән-сау булуына, бу мәктәптә белем алуыбызга тагын бер кат сөендек. Әнә шундый теләк-омтылышлар, сөенеч-шатлыклар белән дәресебезне башлыйбыз.

**II. Уку мәсьәләсен кую.**

– Ә хәзер К. Насыйриның «Китаб-әт-тәрбия»сеннән 3нче нәсыйхәтне тыңлагыз. (Слайд 1.)

*«Бер падишаһның берничә углы булып, араларыннан берсе – зәгыйфь, кыска буйлы кечкенә нәрсә иде. Калганнары озын буйлы, матур йөзле иделәр, әмма аталары ул углына нәфрәт һәм кимсетү белән карар иде. Ул углы акыл иясе вә мәгърифәтле (белемле) бала иде. Әйтте: «Әй ата, гакыллы, тәбәнәк надан озыннан яхшырак түгелме? Һәр нәрсәнең кыйммәте гәүдәсенә карап йөрмәйдер. Мунча ташы бик ире, йөге бер тәңкә. Энҗе бик вак, мыскалы (4.26 грамм) ун тәңкә», – диде. Аталары вә дәүләтнең зур кешеләре барчасы көлештеләр вә хәйран калдылар. Бәс, әй угыл, гыйлем һәм мәгърифәт дигән нәрсә, буйга вә кыяфәткә карап булмайдыр».*

Укучылар, бу нәсыйхәтнең төп мәгънәсе нинди?

– Кешенең тышкы кыяфәте түгел, акылы, гыйлеме кыйммәтрәк.

– Димәк, бүгенге дәресебездә сүз нәрсә турында барачак?

– Гыйлем турында, аның кеше тормышында тоткан урыны турында.

Теманы әйтү. (Слайд 2.)

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

**1.** – Нәрсә соң ул – гыйлем? (Аңлатмалы сүзлектән)

– Гыйлем – ул белем, уку, тормыш тәҗрибәсе, фән...(Слайд 3.)

– Белемгә ничек ирешеп була?

– Уку, тәҗрибәләрне өйрәнү аша.

**2.** – Уку үзе нәрсә ул? (Слайд 4.)

– 1) Хәрефләр яки башка билгеләр белән язылганны күз белән күреп аңлау;

2) нинди дә булса билгеләрне тану (нота уку, эзләрне уку);

3) Һөнәр алу (укытучылыкка уку);

4) тышкы билгеләренә карап, кичерешләрне аңлау (күздән карап уку);

5) изге теләк, каргау (рәхмәт уку).

Укудан файда алу өчен ничек укырга кирәк?

– Аңлы уку – уйлап уку, күп уку – йөгерек уку, дәвамлы уку.

– Үзалды, үзлегеңнән укуны ничек аңлыйсыз? Читтән торып уку ничек була?

– Башка кешенең ярдәменнән башка, үз көчеңә ышанып үзләштерү.

– Слайд 5. *«Гыйлемнең афәте – онытудыр, ә аны тиешсез кешеләргә сөйләп йөрү гыйлемне юкка чыгару була»*. Онытмас өчен нәрсә эшләргә?

– Бөтен белгән нәрсәне кабатларга, язып барырга.

– Слайд 6. «*Гыйлемне язу белән беркетегез*».

Чөнки берәүнең бетүе, юкка чыгуы белән, аның белгән нәрсәсе дә бетәр иде. Бу тарих гыйлеменең кирәклеген күрсәтә.

**3.** – Белем алуның нинди чыганаклары бар? Аларны ничек файдаланырга?

– Китап, газета-журнал, телевизор, компьютер, интернет һәм белгәннәрдән өйрәнәбез. Шушы чыганаклардан үзеңә кирәген сайлап ала белергә кирәк.

**4.** – Безнең авылларыбыздан да үзләренең тырышлыклары, белемгә омтылышлары, даими шөгыльләнүләре нәтиҗәсендә галим булган, зур дәрәҗәгә ирешкән кешеләр бар. Кемнәр алар? Әйтеп китегез әле.

Җаваплар.

**5.** – Ә сезнең гаиләдә олыгайган көннәрендә дә белемгә омтылган, укуларын дәвам иткән әби-бабайларыгыз бар бит. Шулар турында сөйләп китегез әле.

Җаваплар.

**6.** – Ә шулай да укырга кайчан керешү хәерлерәк икән?

**Төркемнәргә биремнәр.**

**1 төркемгә.**

К. Насыйри «Китаб-әт-тәрбия», 34 нче нәсыйхәт.

*«Әй угыл, балаларга белем бирсәң, кечерәк вакытта бик тырыш. Яшь чакта алган гыйлем ташка чокып ясалган бизәккә охшаш булыр. Чыбыкны нечкә чагында бөгү уңайракка киләдер...»*

Ни өчен яшь чакта уку файдалы дип уйлыйсыз?

**2 төркемгә.**

К. Насыйри «Китаб-әт-тәрбия», 6 нчы нәсыйхәт.

*«Олуглардан бер адәм үзенең углын бер галим остазга белем һәм тәрбия бирү өчен тапшырды. Вә әйтте ки: «Әй, остазы камил, бу баланы тәрбия кыл һәм укыт, акыллы галим булсын», – диде. Берничә вакыт бу баланы остаз тәрбия кылды да укытты, әмма һичбер гыйлем бирә алмады. Ул баланы атасына кайтарып йибәрде. Әйтте: «Бу бала һичбер белемгә сәләтле түгелдер, хәтта үземне дивана кыйлды», – диде».*

Бу нәсыйхәтне ничек аңлыйсыз?

**3 төркемгә.**

*«Әбү Хәнифә хәзрәтләре, Хәммәт хозурына белем (фикъһы) укырга барганда, Хәммәт: «Һәр көнне 3 мәсьәлә белсәң, ярар. Аннан арттырма!»* – дип боерган».

Бу хикәятнең мәгънәсе ничек?

Җаваплар.

**7.** – Күп укыган, белемле кешене һөнәренең остасы, гыйлем иясе дип атый алабызмы? Ни өчен?

– Чөнки тәҗрибә кирәк.

– Нәрсә икән ул тәҗрибә?

– Тормыштан, гамәли эшләрдән алган белемнәр, күнекмәләр, үзең эшләп карау.

– Гыйлемлелек белән тәҗрибә арасында нинди уртаклык бар?

– Алар бер-берсен тулыландыра.

**8.** – Гыйлем 2 төрле була: дөньяви һәм дини. Дөньяви – мәктәптә укытыла торган фәннәр. Дини гыйлемнең нигезе – Коръән китабында һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә. Коръән гарәп телендә. Телне аңламаучылар өчен татарча «Тәфсире» чыгарылган. Ләкин Коръәнне гарәпчә укырга кирәк, югыйсә асылы югала. Дөньяви белән дини гыйлем бер-берсенә бәйләнгән, тулыландырып торалар.

Димәк, ике төрле гыйлемне дә өйрәнгән кеше һавада очкан ике канатлы кош шикелле күркәм булыр. Дөньяви гыйлем тән сәламәтлеге, бу дөньяда яшәү өчен кирәк, сәвабы да бу дөньяда гына кала.. Дини гыйлем җан сәламәтлеге, кальб, күңел чисталыгы, ахирәт тормышы өчен, бу дөньяда да бәхетле яшәр өчен кирәк.

**9.** – Тагын файдалы гыйлем, файдасыз гыйлем була. (Слайд 7.)

– Файдалы гыйлем нинди, файдасыз гыйлем нинди була?

– Файдалы гыйлем булганда – белемен, алган белгечлеген эшендә, гамәлләрендә файдалана. Файдасыз гыйлем – укый, гыйлем ала, өйрәнә, ләкин өйрәнгәннәрен үтәми. Мәсәлән, укытучылыкка укый, сатучы булып эшкә урнаша.

– Гыйлемнең тагын бер төре – кешегә зыян китерә торганы – тыелган гыйлем. (Слайд 8.) Сез моны ничек аңлыйсыз?

– Сихер, багучылык, карта, отышлы уеннар, уен автоматлары һ.б.

– Сихер һәм тыелган башка гыйлемнәр кешегә рухи яктан, материаль яктан зур зыян китерәләр, тормышын җимерәләр. Кешене үзенең һәм башкаларның гомерен өзүгә китереп җиткерергә мөмкин. Сезгә алган гыйлемнәрегезнең файдасын күрергә насыйп булса иде.

**10.** – Укучылар, һәрбер нәрсәнең капма-каршысы бар. Гыйлемнең капма-каршысы нәрсә?

К. Насыйриның 45 нче нәсыйхәтендә шундый юллар бар: *«Әй, угыл, йиде төрле кешегә киңәш итмә. Әүвәл, надан кешегә киңәш итмә,*

*чөнки надан кеше үзенең наданлыгына булышып, сине азгынлык юлына салыр...»* (Слайд 9.)

Надан кеше нинди була? Нәрсә ул – наданлык?

– Укый-яза белмәүче, аз белемле, үз эшен, белгечлеген начар белүче.

– Наданлык кайдан килә?

– Тырышмаганлыктан, ялкаулыктан, иренгәнлектән.

– Укучылар арасында бик тырышып укучылар да, шул ук вакытта укуга булган сәләтләрен үстермичә, җиңел генә яхшы билге алырга тырышучылар да бар. Ялкау кеше гыйлемгә, яктылыкка омтылмый, надан була. Тырыш укучы, нинди билге алуына карамастан, «5ле»ме ул яки «3ле»ме, белемгә ирешә.

Өйрәнмәгән, белмәгән кеше җиңел юлны эзләп, юк-бар сәбәпләр табып, тәкәбберләнеп йөри. Мәсәлән, караңгы, уты янмаган бүлмәгә кергәч кеше нишли?

**IV. Рефлексия.**

– Бүгенге дәрестә сүз нәрсә турында барды?

– Гыйлемле булу, тәҗрибәле булу, наданлыкны җиңү буенча нәрсәләр эшләргә кирәк?

Җаваплар.

Слайд 10. Мөнәҗәттән өзек тыңлау.

Кадерле укучылар, минем бүгенге дәресне Галимә Хөсәенованың «Ник кадерен белмисез?» хикәясе белән тәмамлыйсым килә. («Көч һәм рух тамырлары». 62 бит.)

Слайд 11.

**V. Өйгә эш:**

1) Дәрестә өйрәнгәннәр буенча өйдә әңгәмә корырга;

2) гыйлемле булу, тәҗрибәле булу, наданлыкны җиңү буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын төзергә.

***Бариева Нурзидә,***
*Балтач районы Шеңшеңәр төп гомуми*
*белем бирү мәктәбе мөгаллимәсе*

## ИЗГЕЛЕК КЫЛЫП КАЛ, ЯХШЫЛЫК ҖИРДӘ ЯТМАС

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:* укучыларда мәрхәмәтлелек, миһербанлылык, кешеләргә карата игътибарлылык һәм ярдәмчеллек күнекмәләре тәрбияләү, изгелек иманлы кешенең иң гүзәл сыйфаты икәнлегенә төшендерү.

*Материал:* Әхлак дәресләре, Вил Казыйханов. Җәлил хәзрәт дәресләре, дин – культуралылык һәм әхлак билгесе, Р.И. Шаяхмәтова, Коръән тәфсире.

*Җиһазлау:* видеопроектор, күргәзмә китаплар.

**I. Актуальләштерү:**

Әгүүзү билләһи минәш-шайтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Әссәләме галәйкем, килгән кунаклар, укучылар, укытучылар!

**II. Өй эшен тикшерү.**

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар, әгәр тирә-ягыбызга карасак, кемнәр генә үтми безнең яннан. Алар арасында безнең ярдәмгә мохтаҗ кешеләр бар. Алар бер чынаяк чәйгә, ипигә, сөткә тилмереп ятмыйлармы? Берәр дару кирәк түгелме? Шуңа күрә һәрвакыт игътибарлы булыйк. Чит кешегә ярдәм итүдән, яхшылык эшләүдән күңелләр сафланып китә. Ярдәмгә мохтаҗ кешегә ярдәм кулы сузыйк, мәрхәмәтле, миһербанлы булыйк.

Игелек эшләүченең һичкайчан эче пошмас, рәхәтлектә гомер кичерер. Һәркем бәхетле, сөекле булуны теләр. Ләкин кешеләрнең хөрмәтен яулау, сөекле булу өчен башкаларга игелек итү кирәк.

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) әйтеп калдырган бер хәдисне дәфтәрегезгә языгыз:

«Изгелек искермәс вә тузмас, гөнаһ онытылмас», – дигән.

Хәдистә сүз нәрсә турында бара?

– Изгелек турында.

– Димәк, дәреснең темасы: Изгелек кылып кал, яхшылык җирдә ятмас.

– Нәрсә ул – изгелек?

– Изге булу, изге эш, яхшылык эшләү.

Түбәндәге хәдисне ничек аңлыйсыз?

– Күңел аны кабул итә һәм йөрәк тынычлык таба торган нәрсә изгелек.

– Ә гөнаһ аның киресе, аны күңел кабул итми һәм йөрәк тә аның белән тынычлык тапмый.

Җаваплар:

**Эрегән тоз**

Авыл уртасыннан инеш ага. Яңгыр вакытында инеш аша салган басманы су агыза, аннан йөрерлек булмый. Хәбри исемле малай кибеткә бара икән. Ул басманы төзәтә һәм юлын дәвам итә. Үзе бара, үзе уйлый:

– Мин нинди яхшылык эшләдем, ә моны беркем дә күрмәде! – ди.

Кибеттән тоз ала, кайтырга чыга, ә үзе һаман:

– Нинди изгелек эшләдем, ә кешеләр белмәделәр! – ди.

«Туктале, ди, басманы кире суга батырыйм. Кешеләр җыелсыннар, аларның күз алдында басманы төзәтермен».

Һәм Хәбри басма такталарын кире суга батыра. Юеш такта кулыннан таеп, көчле агым белән агып китә.

Хәбри шунда гына исенә килә: ул инешнең аръягында икән.

Шуннан ул чишенеп, киемнәрен дә, тозын да күтәреп инеш аша чыгарга мәҗбүр була. Кулы талганлыктан, ул тозы һәм киемнәре белән суга чумып та ала.

Өйгә кайткач, бар да аңа аптырый.

– Нишләп болай киемнәрең юеш, капчыктагы тозың эреп беткән? – диләр.

– Бер юньсез кеше басма тактасын суга агызган, суга чак батмадым! – дип җавап биргән Хәбри.

Картлар дөрес әйткән: «Яхшылык үзеңә изгелек булып, начарлык явызлык булып кайтыр», – дип.

Син һәрчак яхшылык эшлә. Кешеләр күрәме, юкмы – яхшылык беркайчан да югалмый.

**1. Хәбри нинди ялгышлык эшләгән?**

**2. Хәбри басманы төзәткәч, нинди уйлар уйлый?**

**3. Изгелекне кеше күрсен өчен эшлиләрме?**

**Хәдис**

Мөселманнарга зыян китерердәй нәрсәләрне читкә алып кую игелек эшләүнең икенче төре булып тора. Бу төр игелек эшләүчеләр Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә, бүләгенә һәм мәрхәмәтенә лаек булачаклар.

Укучылар.

– Кеше күрмәгәндә эшләнгән изгелекнең дә савабы күп икән.

Хәдис.

– Иң кечкенә бер игелекне дә кадерсез санама һәм игътибарсыз калдырма. Хәтта су алырга килүченең чиләгенә су алып салуың да бер изгелектер, – диелгән.

Укучы.

Егылганда иптәшемә сузсам кулым,
Өлкәннәргә хөрмәт белән бирсәм урын,
Күрше картка чишмәбездән су китерсәм,
Әнкәемне «бишле» алып сөендерсәм,
Я берәрсе, мине сөеп, рәхмәт дисә,
Улы кебек якын итеп, кулын бирсә,
И сөенәм, и сөенәм.

Менә, укучылар, мәрхәмәтле, миһербанлы булу сөенеч китерә икән.

Түбәндәге хәлләрдә сез үзегезне ничек тотар идегез?

1. Әниегез бик арыган кебек тоела.

2. Сыйныфка яңа укучы килде. Ул үзен бик тә уңайсыз хис итә.

3. Күрше әби авырып ята, даруга барырга кирәк. Синең түгәрәккә барасың бар.

Җаваплар:

**Дәресне йомгаклау.**

Укучыларның эчке кичерешләре белән танышу. Дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

Нинди нәтиҗәләр ясадыгыз?

**Өйгә эш:**

Сезнең гаиләгездә нинди игелекле кешеләр бар?

***Фәхертдинова Сөмбелә,***
*Тукай районы Теләнче-Тамак*
*«Мирас» мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсее*

## «ЙОСЫФ» СҮРӘСЕНДӘ ӘХЛАК ҮРНӘГЕ

**(**Өлкән сыйныф укучылары һәм зурлар өчен)

*Максат:* «Йосыф» сүрәсендәге төп проблемаларны ачыклау. Укучыларда гомумкешелек кыйммәтләренә омтылыш уяту.

*Җиһазлау:* интерактив тактада аятьләр язылган слайдлар күрсәтелә.

*Дәрескә эпиграф:* «Шик тә юк, бу китап – Коръән Кәрим сакланган кешеләр өчен дөрес юлның нәкъ үзедер» («Бакара» сүрәсе, 2 нче аять)

*Төп алымнар:* Әңгәмә, геройларны чагыштыру.

*Дәрес барышы:*

1.1. «Йосыф» сүрәсе белән таныштыру.

Йөз дә унбер аятьтән торган «Йосыф» сүрәсе Коръәннең иң яхшы, гыйбрәтле, гүзәл эчтәлекле кыйссаларыннан санала. 3 нче аятьтә Аллаһы Тәгалә Үзе белгертә: «Без, сиңа бу Коръәнне вәхи итеп яшәп узган кавемнәрнең хәлләре турында гүзәл сурәттә аңлатабыз...»

Ни өчен «Йосыф» сүрәсенә игътибар шул дәрәҗә югары бирелә соң, дигәндә, күп кенә сәбәпләрне атап үтәргә мөмкин. Беренчедән, ул Коръәндә иң җентекләп хикәяләнгән кыйсса булып санала. Икенчедән, кеше тормышындагы уңай һәм тискәре вакыйгалар җәмгыятьнең бөтен катлау ирләре һәм хатын-кызларына да кагыла. Өченчедән, адәм баласы үз гомерендә кичерә торган рухи яшәешнең һәммә күренешләре гаҗәеп нечкәлекләре белән бирелә: монда олы яшьтәге пәйгамбәрнең төпчек улларына карата аталарча яратуы, кайгыртуы да бар, өлкән улларының шул нисбәттән килеп туган усал көнчелекләре һәм Йосыфка кылган хыянәтләре дә тасвирлана; ата кешенең яраткан улын югалту хәсрәте, Йосыфның колдан түбән дәрәҗәдә бик арзан хакка базарда сатылуы; гыйффәтле вә саф, чиста мәхәббәткә капма-каршы буларак эгоистик хисләр бәрелеше; яла ягып, гаепсез кешене зинданга яптырып, соңыннан тәүбәгә килеп гафу сорау, гафу үтенү; төш юрау, дәүләт белән идарә итү, түбән һәм югары әхлакый тормыш алып бару, ил җитәкчесенең гаҗәеп гаделлеге һәм халыкчанлыгы, ата һәм ул мөнәсәбәтләренең тугрылыгы белән аерылып торуы һәм, ниһаять, Аллаһтан куркуның иң югары дәрәҗәсенә җиткерелеп, иң гүзәл үрнәк

рәвешендә тасвирлануы – боларның һәммәсе «Йосыф» сүрәсендә үз урынын табып, иң тәэсирле хикәяләү үзенчәлекләре белән җиткерелгән! Шунысы кыйммәт: биредә һәр көн, һәр сәгать саен диярлек үзгәрешләргә дучар ителгән кешелек дөньясында үзгәрмичә хакыйкый асылын саклап кала алган гүзәл әхлак һәм Аллаһы Тәгаләнең әмере һәм теләгенең могҗизаи көче бөтен матурлыгы, нечкәлеге белән яктыртыла.

1.2. «Йосыф» сүрәсендә әхлак үрнәге (сүрәне укып, аятьләрнең мәгънәләре турында фикер йөртү)

Сүрә Коръәннең һәм анда сурәтләнгән кыйссаларның өстенлеген раслаучы аятьләр белән башланып китә. Соңыннан, 100 нче аятькә кадәр, Йосыф тарихы сөйләнә. Ахырдагы 10 нчы аять исә Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Аллаһ илчесе булып килүенең хаклыгын раслый, Коръәннең бердәнберлеген, анда сурәтләнгән пәйгамбәрләр тормышындагы үгет-нәсыйхәтләрнең бәхәссезлеген дәлилли. Исеменнән үк күренгәнчә, биредә Йосыф галәйһиссәлам тормышы хакында сүз бара.

«Йосыф» сүрәсе кеше тормышындагы уңай һәм тискәре вакыйгалар, адәм баласы үз гомерендә кичерә торган рухи яшәешнең һәммә күренешләре: кечкенәдән әнисез үсеп, агаларының яман холкы аркасында әтисен дә, туып-үскән илен дә калдырырга дучар ителгән Йосыф галәйһиссәлам колдан алып бөек патша дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Ул үзенә Раббысы тарафыннан тапшырылган изге бурычын намус – вөҗдан белән үтәп чыга һәм бөтен кешелек өчен югары әхлакның гүзәл үрнәгенә әверелә. Бу сыйфатлама Йосыфның Аллаһ илчесе, ягъни пәйгамбәр буларак кешеләргә Ислам динен таратуында да, яшәү барышында килеп туган һәртөрле хәл-вакыйгаларда үзен ничек тотуында, аеруча ата-анасына һәм туганнарына карата мөнәсәбәтләрендә дә бердәй чагылыш таба – олуг кыйммәтләрне үз эченә ала.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә сурәтләнгән вакыйгаларны гадәти хикәяләү итеп кенә бирми. Изге Китабыбыз ничек итеп гамәл кылырга кирәклеген пәйгамбәрләр тормышы аша җиткерә.

«Ий, Мөхәммәд! Без сиңа Коръәнне вәхи итеп кыйссаларның күркәмлеген хикәят кылабыз...» [«Йосыф»: 3].

«Хактыр ки, Йосыф һәм аның абыйлары белән булган вакыйгада гыйбрәт-сабак алырга теләгәннәр өчен хикмәтләр бар». [«Йосыф»: 7.]

«Балигъ яшенә җиткәч, Без аңа хикмәт һәм гыйлем бирдек. Изге эшләрне үтәүче хәерле холыклыларны Без шулай бүләклибез». [«Йосыф»: 22.]

1.2. Хикмәтнең өч баскычы бар:

1. Гыйлем (дөньяви һәм дини).

2. Әл-хилм. (Акыл, уйлау, фикерләү, яхшы холык.) Гыйлемең булу өстенә, күркәм холкың булуы да шарт.

3. Ашыкмау һәм соңга да калдырмау, вакытында үтәү.

Әтисе йортыннан чыгып киткәндә, Йосыф һәрнәрсәгә ышанучан яшь бала, беркатлы сабый була. Әмма коедагы сынаулар, агаларының хыянәте, кол булып сатылу, вәзир йортына килеп эләгү аның өчен зур хикмәт тупларлык дәрес бирә, ул күп нәрсәне аңлый башлый. Бу гыйлемнәр аңа Аллаһтан бирелгән пәйгамбәрлек гыйлеме. Әлеге аятьтән күренгәнчә, тормыш сынаулары кешене күп нәрсәгә өйрәтә. Әгәр инсанлыгыңны югалтмасаң, хәерлегә өйрәнәсең, зирәк акыл туплыйсың. Әгәр инде сабыр итәргә теләмәсәң, хәлең тагын да авыраерга мөмкин. Сынауларны Аллаһы Тәгалә кешегә тормышына бер нәтиҗә ясап, гөнаһ-хаталарын төзәтеп, сабак алыр өчен, рухи яктан тагын да камилләшеп, ихласлыгын арттырыр өчен җибәрә. Фикерли торган кеше моны яхшы аңлый һәм кыенлыкларга түзеп, алдагы тормышы әйбәт булачагына ышанып, Аллаһтан өметен өзмичә яши. Тормыш сынаулары күбрәк булган саен, кешенең рухи яктан җитлегүе, чыныгуы да тизрәк бара.

23 нче аять:

«Вәзир хатыны Зөләйхә үз өендә Йусуфтан ялынып вә ялварып нәфесе теләгәнне үтәүен таләп итте вә барча ишекләрне бикләде һәм Ий, Йусуф, кил минем яныма, мине мәхрүм итмә», – диде. Йусуф әйтте: «Бу эштән Аллаһуга сыгынамын, тәхкыйк тәрбиячем Гәзиз миңа хөрмәт күрсәтте, торачак җиремне күркәм кылды, инде мин аңар ничек хыянәт итим! Бу эшне кылсам залимләрдән булырмын бит, әлбәттә, залимләр Аллаһ газабыннан котыла алмаслар».

Йосыфка бу вакытта 25, ә Зөләйхага 40 яшьләр тирәсе була. Үзенең түбән хисләренә бирелеп, Йосыфны ул зур гөнаһка өнди. Аятьтән күренгәнчә, бу хатын бик күп ишекләрне бикли, ләкин Аллаһның ишеген бикли алмый...

Безнең заманда да зинаны күпләр гөнаһка санамый. Чынлыкта зина – Аллаһ разый булмаган шәһвәтнең азагы – мәңгелек үкенү белән тәмамлана. Зина – җанга золым. Зинадан туган балалар күпчелек очракта ятим, ата-ана назыннан, җылысыннан мәхрүм булып үсә. Зиначы Аллаһтан, Аның рәхмәтеннән өзелә. «Зинага якын бармагыз. Чөнки зина – әдәпсезлек, бер нәҗес гамәлдер, пычрак юлдыр». [«Исра»: 32.]

«Әлбәттә, иман китереп яманлыклардан сакланганнар өчен Ахирәт бүләге тагын да хәерлерәк». [ «Йосыф»: 57.]

II. «Йосыф» сүрәсе нигезендә «Кыйссаи Йосыф» поэмасы.

2.1 «Йосыф» сүрәсе Коръән тәфсирчеләре һәм мөселман шагыйрьләренең яраткан темасына әверелгән. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан (1233 ел): Кол Гали әсәрнең төп герое Йосыфның түбәндәге ун төрле уңай сыйфатларын саный:

Беренчедән, буе зифа, чибәр үзе,
Икенчедән, якты чырай, күркәм йөзе,
Өченчедән, теле төзек, туры сүзе,
Җитмеш ике телне тәмам белә инде.
Дүртенчедән, кечелекле һәм шәфкатьле,
Бишенчедән, алп йөрәкле һәм гайрәтле,
Алтынчыдан, күп кешедән ул куәтле,
Кырык ирдән куәте аның артык инде.
Җиденчедән, дине бөтен, диянәтле,
Сигезенче: хаин түгел, әманәтле,
Тугызынчы: холкы йомшак, теле татлы,
Унынчыдан, пәйгамбәрләр нәселе инде.

«Кыйссаи Йосыф» татар халкының болгар дәвереннән бирле кадерләп сакланган әсәре.Ул җиде гасыр дәвамында халык күңелендә яшәгән, яратып укылган һәм хәзер дә актуальлеген югалтмаган.

– Моның сәбәбе нидә?

– Сюжетның кызыклы һәм гыйбрәтле, сәнгатьчә эшләнеше камил, бик күп проблемалар күтәрелүендә.

Нинди эпизодлар аеруча игътибарыгызны җәлеп итте?

1. Йосыф һәм әтисе белән бәйле вакыйгалар.

2. Йосыфның туганнары белән мөнәсәбәтенә бәйле вакыйгалар.

3. Йосыф-Зөләйха мөнәсәбәте.

– Нинди нәтиҗә чыгара алабыз?

Әсәрнең төп темасы Аллаһка ышану, шәфкатьлелек, әхлаклылык.

2.2. Әсәр тулысы белән ислам, Коръән рухында иҗат ителгән.

– Коръәндә ата-анага, ятимнәргә, туганнарга шәфкать кылу мактала.

36. «Аллаһуның үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары: ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят

юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!» («Ниса» сүрәсе, 36 нче аять.)

8. «Без кеше затына ата вә анага изгелек итәргә әмер бирдек, әгәр ата һәм анаң син Аллаһ дип танымаган Аллаһудан башка бер нәрсәне Аллаһ дип таныргa көчләсәләр, ул вакытта аларга итагать итмә, бит кайтарылмагыгыз Миңадыр, кыйлган эшләрегездән хәбәр бирермен һәм җәза кыйлырмын».

9. «Иман китереп изге гамәлләр кылган мөэминнәрне, әлбәттә, изге бәндәләрем арасына кертәчәкмен». («Ганкәбүт» сүрәсе, 8–9 нчы аятьләр).

– Коръәндә тынычлык саклау, үзара тату, дус, туганнарча яшәү мәсьәләсе мөһим урын тота.

– Коръәндә зина кылу, башка диндәге кеше белән гаилә кору тыела.

Кол Гали моңа ничек карый? (Зөләйха потка, сынга табына. Ул мәҗүсилек динен тота. Ләкин соңыннан ул да мөселман диненә күчә. Аллаһ аны Йосыф белән кавыштыра.)

– Коръәндә сабырлык мактала. (Әсәрдә сабырлык мотивы зур урын алып тора. Йосыф сабыр, Зөләйха сабырсыз. Йосыф акыл белән эш итә. Зөләйха хис кешесе. Димәк, бу яктан алар капма-каршы куелалар.)

Кыйссада әлеге өйрәтүләр ничек чагылыш тапкан? (Фикер алышулар)

Нәтиҗә ясау:

«Кыйссаи Йосыф» поэмасының социаль-тарихи, идея-фәлсәфи, этик-эстетик эчтәлеге гаять киң. Әсәр шул заман кешелек тарихы алдындагы бөтен проблемаларны диярлек эченә ала. Поэмада бик күп тормышчан мәсьәләләр, конфликтлар бирелгән: яхшылык һәм гаделлекнең явыз-залим көчләр белән туктаусыз көрәше; кешеләрнең яктыга, бәхеткә, әхлакый сафлык, камиллеккә омтылышы һәм шул юнәлештә тормыш киртәләренә очравы, кыенлыкларны җиңеп, идеал-максатларына ирешүләре, геройларның җанлы-табигый кичерешләре, аһ-зарлары, шатлык-куанычлары, матур хисләре, күз яшьләре.

Әсәр гасырлар буе халкыбызның әхлагын, зәвыгын тәрбияләүгә, аның аңында сафлык-пакьлек, гаделлек – тугърылык, кешелек һәм гуманизм сыйфатларын үстерә баруга йогынты ясап килгән. Шигъри сүзенең гади, ягымлы, төзек, шул ук вакытта табигый, сурәтле һәм аһәңле әйтелүе белән дә ул классик әдәби телебез һәм поэтик стилебезнең кабатланмас үрнәге булып, әдәбиятыбызга аяк баскан һәр яңа буынга шигъри мәктәп булып хезмәт иткән. Халкыбыз тормышына, аның рухи дөньясына бу кыйссаның никадәр тирән үтеп керүен, әсәрнең сюжет һәм мотивлары

халык җырлары, әкият, бәет һәм легендалар белән беррәттән йөрүеннән һәм, ниһаять, басма китапларының (1839–1917 еллар арасында поэма җитмеш тапкырдан артык басылып чыга) иске татар мәдрәсәләрендә дәреслек рәвешендә кулланылуыннан да күрергә мөмкин.

«Йосыф» сүрәсе – Аллаһтан килгән тәкъдирне аңлатучы иң мавыктыргыч сүрә. Нинди генә сынауда да адәм баласы Аллаһтан ярдәм сорап түзәргә, сабыр булырга тиеш. Уңышка ирешү юлында киртәләр булмый калмый. Бу табигый хәл. Чөнки авырлыклар аша табылган нигъмәт кенә кадерле. Кадерсез әйбер юлда аунап ята, аны алыр өчен тырышлык та, көч тә, акыл да кирәк түгел. Ә менә алтын, энҗе-мәрҗәннәр ансат кына табылмый. Аларны эзләп табар өчен күпме вакыт сарыф ителә, никадәр көч-гайрәт түгелә...

«Хактыр ки, бу кыйссаларда акылы булганнар өчен бик күп гыйбрәтләр бар. Бу уйлап чыгарган хикәяләр түгел. Бәлки, аннан элек килгәнне дөресләүче, һәрнәрсәне ачыклаучы. Иман китергәннәр өчен тугры юл күрсәтүче һәм рәхмәт алып килүчедер». («Йосыф» сүрәсе 111 нче аять.)

Аллаһы Тәгалә «Йосыф» сүрәсен, Кыямәт көненә кадәр яшәячәк халыкларга зур сабак, ярдәмче буларак иңдергән.Мәгълүм ки, чынбарлыктан ерак торган хикәяләрдән гыйбрәт алып булмый. Ә бу сүрәдә без, тарихи шәхес – Йосыф галәйһиссәламнең – балачагыннан алып вафатынача булган тормыш юлы белән танышабыз. Бу кыйссада беренче карашка зәгыйфь, яклаучысыз тоелган дөреслек һәм зур, гайрәтле күренгән явызлык капма-каршы куела. Ахырдан барыбер хакыйкать җиңеп чыга. Әмма бу әкият түгел! Адәм балаларының күңелләрен йомшартып, пәйгамбәрләр юлының үрнәк юл икәнен аңлату ниятеннән бөтен халыклар өчен Аллаһ сүзе буларак Коръәндә тасвирлана. Барчабыз да моның шулай икәнен аңласак иде... Акыл, фикер ияләре өчен «Йосыф» сүрәсе зур дәрес, гыйбрәткә тиң...

**Өйгә эш:**

«Йосыф» сүрәсен һәм Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен тулысы белән укырга.

Әдәбият

1. Йосыф пәйгамбәр хикмәтләре.– Казан, 2012. – 185 б.

2. Коръән: аятьләрнең татарча мәгънәләре [төрле галимнәрнең тәрҗемәләре һәм шәрехләреннән файдаланып матбугатка әзерләүче М.Р. Батулла, кереш сүз авт. Р. М. Мөхәммәтшин]. – Казан: Җыен, 2012. – 997 б.

3. Коръән тәфсире (Ногмани). – Казан: Татар.кит.нәшер., 1994.– 683 б.
4. Мөхәммәд Мостафа. Коръән аятьләренең тематик белешмәсе [Китапны басмага әзерләүче Р.Миннеәхмәт]. – Чаллы: Ак мәчет, 2008. – 115 б.
5. Хөснетдинова Л.К. 9 нчы сыйныфта әдәбият укыту: укытучылар өчен кулланма. – Чаллы, 2006. – 108 б.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Түбән Сөн авылы*
*мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## ИСЛАМ ДИНЕНДӘ АТА-АНА ХАКЫ
(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:* балаларга гаилә турында төшенчә бирү. Әти-әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. Өлкәннәргә авыр сүз әйтүдән тыела белергә кирәклеген, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү. Ата-аналарга карата ислам дине кануннарын барлау.

*Җиһазлар:* тактада: *«...дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул әти-әнисенә, олыларга изгелек эшләүче кеше»* язып кую. Коръән сүрәләре.

*Кулланылган әдәбият:* Коръән китабы. «Балаларга үгет-нәсыйхәт» ТР мөс. Диния нәзарәте. Йосыф Туаслы. «Вәгазьләр әдәп-әхлак китабы», «Бәхетлеләрнең серләре» Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин. Татар дини календарлары. «Әйтер сүзем бар». Рәсим хәзрәт Хәбибулла. «Ата-ана хакы». Рәмис Гарифуллин. Арча.

*Дәрес барышы:*

**1. Кереш өлеш.**

*Укытучы:* – **Әссәләмегаләйкем вә-рахмәтуллаһи вә-бәрәкәтүһ** кадерле укучылар! **Әгүүзү билләһи минәш-шайтаанир – раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.** Хәерле көн! Балалар, кеше гомере аккан сулар кебек бик тиз узып китә. Аның ничек узуы һәркемнең үзенә бәйле. Гаилә ул – җылы учак. Учак янына гаилә әгъзалары җыела. Гаилә нык булса гына, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була. Гаилә – тормыш көзгесе, тормыш нигезе. Әти-әни аның тоткасы булса, балалар – гаилә көзгесе. Әгәр тотка купмасын, көзге ватылмасын дисәң, бер-береңне санлап, рәнҗетмичә, хөрмәтләп яшәргә кирәк.

Гаилә, әлбәттә, **әти-әнидән** башка була алмый. Алар безнең өчен изге җаннар. Без аларны яратабыз, хөрмәт итәбез.

Әти-әниләр үз баласын тырышып, җаннарын да кызганмыйча, күз карасыдай якын күреп, саклап, назлап-сөеп үстерә. Бала да әти-әнисен ихлас күңелдән хөрмәт итәргә, игелекле булырга омтылырга тиеш. **«Ата-аналарын риза кылучы балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр», «Ата-аналарыгызга игелек итегез, сезгә дә балаларыгыз игелек итәр»,** – диелә хәдисләрдә.

**2. Төп өлеш.**

***1) теманы ачу***.

– димәк, бүгенге дәреснең темасы нинди икән?

– балалар, сез әти-әниләрегезне яратасызмы? Ни өчен алар сезгә бик кадерле?

*Балалар:*

* Безнең бу якты дөньяга килүебезгә ата-аналар сәбәпче булган;

* Җил-давылларга тидермичә, ышыклап, авырган вакытларыбыз да төннәрен йокламыйча безне үстергәннәр;

* Кеше итәргә тырышканнар;

* Безнең ата-аналарыбызга карата булган хакларыбыз бик зур, ата-ана хакын түләп бетерергә мөмкин түгел;

* Без бу якты дөньяда яшәгән вакытта аларның разыйлыгын алырга тиешбез.

*Укытучы*: («Исра» сүрәсен укый) «***Раббыбыз Аллаһ Коръән Кәримдә әйтә: Аллаһ Бер Үзенә генә гыйбадәт кылырга боерды. Башка затларны үзе белән тиң кылмаска кушты, ата-анага яхшылык кылырга өндәде, әгәр аларның берсе яки икесе дә синең алда картайса, аларга «уф» дип тә әйтмә, аларга җикеренмә һәм аларның икесенә дә карата күркәм мөгамәләдә бул». («Исра»-23)***

***2) ата-ана хакы.***

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер яшь егеткә: *«Син әтиеңнеке, синең тапкан малың да әтиеңнеке»*, – ди. Менә бу хәдис белән балаларның әти-әни алдында булган бурычы ачык итеп бәян ителә. Безнең борынгы бабаларыбыздан килгән шундый әйтем бар: ***«Кеше исән чакта, үзе мал табып яшәгән чорында тапкан малының бер өлеше белән бурычын түли, бер өлешен бурычка бирә, ә бер өлешен суга сала».*** Бу әйтемне ничек аңларга соң? Кешенең бурыч түләве – ул ата-анасын карарга тотылган мал, ә бурычка бирүе – балаларын

үстерергә тотылган өлеш, ә инде суга салуы – үз тормышын алып баруга тотылган мал. Әйе, кешенең үз тормышын алып барырга тотылган малы суга салган кебек югала, кире әйләнеп кайтмый. Чыннан да, безнең ата-бабаларыбыз бик гыйлемле халык булган. Бу әйтем пәйгамбәребезнең (с.г.в.) хәдисенә дә тәңгәл килеп тора.

***3) төркемнәрдә эшләү.***

**1 бирем. Уен «Мин башлыйм, син дәвам ит»**

– Олыласаң олыны,...*(олыларлар үзеңне)*

– Әткәй шикәр, әнкәй... *(бал)*

– Ана күңеле балада, бала күңеле... *(далада)*

– Атаңны башыңда тот, анаңны... *(учыңда тот)*

– Атасын алдаган... *(илен алдар)*

– Ачтан үлсәң дә, ата-анаңны... *(ташлама)*

– Ата-ананы тыңлаган-адәм булган, тыңламаган... *(әрәм булган)*

**2 бирем.**

Укытучы: хәзер сезгә гыйбрәтле өзек тәкъдим итәм.

*Бер бәдәви гарәпләр гаиләсендә бабай картаеп бетә дә гаиләсенә кирәкми башлый. Шул вакытта бабайның малае әтисен аркасына менгереп утырта да чүлгә таба илтә башлый. Чүлгә таба барганда, бабай көлә-елый шундый сүзләр әйтә: «Җитте, җитте үземә дә килеп җитте», – ди. Бу хәлне күргән кешеләр сорыйлар: «Әй, бабай, нәрсә килеп җитте соң?», – диләр. Улының аркасында утырган бабай җавап бирә: «Беләсезме, мин дә яшь чагымда бу улымның күз алдында, үземнең картаеп беткән әтиемне нәкъ шулай ук чүлгә үләргә илтеп ташлаган идем. Күрәсезме, хөрмәтле кардәшләрем, ничек син әти-әниеңә мөгамәлә кылсаң, нәкъ шундый ук мөнәсәбәтне үз балаларыңнан күрәсең», – ди.*

– Бу риваятьтән нинди нәтиҗә чыгарырга була?

*Аллаһның рәхмәтенә ирешәсең килсә, балаларыңа дөрес тәрбия бирәсең килсә, нәтиҗәдә бәхетле булам дисәң, әти-әниләреңә матур мөнәсәбәт күрсәт, игелекле бул.*

3 бирем. Ата-аналар каршында булган бурычларыбызны ачыклау:

(башта балаларның җаваплары тыңлана, кабат тулыландырылып тәртипкә салына)

*1. Ата-анага карата салкынлык күрсәтмәү.*

*2. Ата-ананы тыңлау, аларга буйсыну.*

*3. Ата-аналар белән тупас мөнәсәбәттә булмау, алар белән ачуланышмау.*

*4. Ата-ананың изгелеген, теләк итүләрен санга сугу.*

*5. Ата-ананы каргамау.*

*6. Ата-ананың киңәшен тоту.*

*7. Ата-ана рөхсәтеннән башка өйдән китмәү.*

*8. Ата-ана йортыннан аерылмау.*

*9. Ярдәмгә мохтаҗ ата-аналарны картлыкларында ялгыз калдырмау.*

*10. Ата-анага кул күтәрмәү.*

Кадерле балалар! Бүгенге вәзгыять, җәмгыятебезнең көннән-көн бозыклыкка баруы – ата-аналарның бала хакын, балаларның ата-ана хакын үтәмәвеннән килә. Шуның өчен балаларыбызны үзебезгә һәм өлкәннәргә карата мәрхәмәтле, ихлас иманлы итеп тәрбияләргә тырышыйк. Без үз хәлебезне үзебез үзгәртмәсәк, Аллаһы Тәгалә безнең хәлебезне үзгәртмәячәк. Тәүбәгә килеп, Ислам кануннары белән яшәргә насыйп булса иде һәммәбезгә.

**4 бирем**.

*Укытучы:* Бер ир кешенең атасы булган, картлык сәбәпле ашаган вакытта ризыкларын чәчкәли торган булган, бу, әлбәттә, килен кешегә ошамый, ул иренә мөрәҗәгать итеп әйтә: *«Әтиең бигрәк карт, ашаганда куллары калтырый, ризыкларын чәчә, әйдә без аны икенче бүлмәгә күчерик булмаса»,* – ди. Алар шулай эшлиләр дә, әмма шайтан гел вәсвәсәләп тора, килен тагы иренә мөрәҗәгать итә*: «Әтиең безгә авыр йөк, аның артыннан карап йөреп тәмам арыдым, җыештырып та туйдым, әйдә без аны куып чыгарыйк»*– ди. Шулай итеп мескен әти кешене урамга куалар, улы әтисен җәлләп туңарсың дип, җылы юрган бирә, ә бу вакыйганы кечкенә бала күреп тора: *«Әти, ди, – тукта, яртысын кисеп ал ул юрганның». «Нишләп?»*, – дип сорый әтисе кечкенә сабыйдан. *«Миңа тиздән мин үсеп җитәм, сине чыгарып җибәргәндә миндә шулай эшләрмен»*, – ди сабый.

*Дуслар! Ата-аналарыбызны рәнҗетсәк, үзебез мәңге игелек күрмиячәкбез, балаларыбыз тарафыннан безгә дә шундый начар караш булачак, берүк ата-аналарыбызга карата дорфа булудан, каты бәгырьле булудан сакланыйк. Ата-аналарыбыз бездән разый булмыйча торып җәннәтнең исендә тоймаячакбыз, Раббым Аллаһ Үзе сакласын.*

**Өлкәннәргә хөрмәт күрсәтүне без ничек аңларга тиеш һәм ул нәрсәдә чагыла?**

- Иң беренче чиратта, олыларга хөрмәт күрсәтү, очрашкан вакытта иң беренче булып сәлам бирү.
- Әти-әни чакырса, бала яннарына йөгереп килергә тиеш.

• Кечкенә – олыга, узып баручы утырып торучыга, әз төркем күп төркемгә сәлам бирергә тиеш.

• Ашаган вакытта ризык кабул итүне иң беренче өлкән кеше яки хөрмәтле кеше башларга тиеш.

• Әгәр дә кешеләргә берәр нәрсә бирергә туры килсә, бирүне олы кешедән башла.

• Сүз башлаганда да, әдәп буенча беренче сүзне олыларга бирәләр.

• Олылар сөйләшкәндә, аларның сүзен бүлү бик зур тәртипсезлек.

**3. Йомгаклау.**

Бу дәрестә үзегез өчен нинди нәтиҗәгә килдегез?

Балалар тактада язылган *«...дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул әти-әнисенә, олыларга изгелек эшләүче кеше»,* – язуны хор белән укыйлар.

Димәк, без һәрвакыт әти-әниләребезгә, өлкәннәргә мәрхәмәтле һәм игътибарлы, шәфкатьле булырбыз.

Иң асыл сыйфатыбыз булган КЕШЕЛЕКЛЕЛЕКНЕ югалтмыйк!

Безнең мөхтәрәм кешеләребезнең өлкәннәргә хөрмәтен күрү, безнең өчен сөенеч, горурлык. Шулар мисалында, балаларыбызда да ата-анага карата хөрмәт һәм мәрхәмәт тәрбияли алсак иде.

**4. Өйгә эш:**

Ата-аналар, өлкәннәр турында хәдисләр әзерләп килергә.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Түбән Сөн авылы*
*каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## КЕШЕ ХОЛКЫН КҮЗӘТ, ҮЗЕҢНЕКЕН ТӨЗӘТ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен )

*Эпиграф:*

Матурлыкка бай ул безнең заман,
Адым саен бездә матурлык.
Барлык батырлыкның,
Матурлыкның
Иҗат итүчесе халык бит!

*Һади Такташ.*

*Максат:* 1. Төп матурлык – кеше күңеленең матурлыгы. Чын кеше – үзе булып кала белгән, эчке матурлыгын саклаган шәхес ул.

2. Укучыларда тәрбиялелекне, гаделлек, тыйнаклылык, мәрхәмәтлелек, эчкерсезлек кебек сыйфатлар тәрбияләү.

*Җиһазлау:* фотолар, китаплар, слайдлар.

*Дәрес барышы:*

**1. Төп проблеманы ачу.**

Әссәләмегаләйкем, кадерле балалар!

Сезгә *«Ничек итеп матурлыкны танырга?»* дигән проблемалы сорау куела.

Нәрсә ул – матур холык?

*Укучылар җавабы*: табигать, кеше күңеле, тыныч тормыш, илнең иминлеге, үз туган җирендә яшәү, матур йөз, буй-сын. Уңган-булган кешеләрне дә матурлык төшенчәсе үз эченә ала. Матурлыкка болар гына чик була алмый, әлбәттә.

*Фикерләрнең дөреслегенә ышану, үз-үзеңне тикшереп карау өчен «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нә күз салыйк.*

1. Матур, гүзәл, күңелгә рәхәтлек бирә торган – күренеш, тормыш, сәнгать әсәрләре.

2. Матур, сокланырлык урыннар – табигатьтә, матур әдәбият әсәрләрендә.

3. Ягымлы, сөйкемле, үзенә җәлеп итә торган тышкы кыяфәт, кеше характерындагы, эшчәнлегендәге хуплана торган сыйфатлар.

**2. Теманы ныгыту.**

***1) «Урыннан күчеш» уены.***

Сораугa җавап ӘЙЕ булса күчәбез. Җавап ЮК икән күчмибез. Урыннан күчеш уенына сораулар.

1. Бүген иртән кем тәмле итеп чәй эчте?
2. Кем бер генә тапкыр булса да өй эшен әзерләми килде?
3. Кем бу атнада өйдәгеләренә хәерле иртә теләде?
4. Кемнең классташларын үчекләгәне бар?
5. Кем кичә ашханәдә ашады?
6. Кемнең өй эшен эшләргә әнисе булыша?
7. Кем кичә укучылар ашаганда тәмле булсын диде?
8. Кем бүген кемгәдер рәхмәт әйтте?
9. Кемнең әй, эшлисе килми әле дигән җавапны әйткәне бар?
10. Кем бу арада күршесенең кереп хәлен белде?
11. Кемнең әнисен алдаганы бар?
12. Кем бүген әти-әнисенә хәерле эш көне теләде?

*Нәтиҗә:*

Менә, балалар, без үзебез турында күбрәк белдек. Матур сүзләрне дә сирәк әйтәбез әле. Без бу уеннан соң хаталарыбызны төзәтә алырбыз дип ышанып калам. Бу уеннан кемнәр үз-үзенә үрнәк алырлар икән? (Кул күтәргән укучыларның фикерләре тыңлана.)

***2) Кешенең холкына багышланган мәкальләр:***

Киемеңне – яңа чагында, намусыңны – яшьтән сакла.
Яхшылык итсәң, үзеңә кайтыр.
Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.
Үзенә игелек күрсәтмәгән кешедән игелек көтмә.
Намус җаннан кадерле.
Үз кадерен белмәгән, кеше кадерен белмәс.
Матурлыкның күзгә бәреп торганы түгел, күзеңне ачканы кадерле.

***3) Мәкальләрне дәвам итәргә.***

Агач – җимеше белән,..... (адәм кыланмышы белән).
Кешегә яхшылык итсәң,.....(үзеңә кайтыр).
Изгелек.....(җирдә ятмый).
Миһербанлык – йөрәктән,.....(миһербансызлык beləктән).
Әдәп, әдәпнең төбе..... (яхшы гадәт).
Намусыңны.....(яшьтән сакла).
Башта холык тап,.....(аннан гыйлем).

***4) Матур холык турында бөек шәхесләр фикере:***

*Р. Батулла* – күренекле татар язучысы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе: «Әгәр дә матурлык бөтен кешедә дә булса, ул матурлык булудан туктар иде».

Драматург *Хәй Вәхит* матурлык турында менә нинди сүзләр язып калдырган: *«Сәнгать өчен матурлык урманда түгел, кеше күңелендә. Кешедәге матурлыктан көчлерәк матурлык юк дөньяда».*

Бөек рус язучысы *А.П. Чехов*: *«Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә».*

Бөек инглиз галиме *Бернард Шоу* мондый фикер язган*: «Матурлык – ул сәламәтлек».*

**3. С. Хәким «Әнкәй» шигырен уку, фикерләрен тыңлау.**

Кая барма, шунда әнкәй йөзе,
Кая барсам, әнкәй күңелдә.

Әни генә шулай синең өчен
Җанын биреп яши гомергә.
Авырсаң да янда тора ул.
Төн буе кефек какмый.
Ул саулыгын да кызганмый
Ул безне саклый-саклый.
Рәхмәт яусын безнең әнкәйләргә
Алargaдыр бөтен авырлык.
Әнкәйләргә якты йолдызлардан,
Я кояштан һәйкәл салырлык.
Җан җылысын тоя күңелебез,
Әнкәй көчен тоя кулыбыз.
Үпкәләмәсеннәр!
Әнкәйләргә гел изгелек кенә кылыгыз.

*Фикер алышу.* Әниләрегез турында уйладыгызмы?

**4. Мәкаль буенча эш.**

«Кул пычранса, су белән юарсың,
Су пычранса, ни белән юарсың?»

Нәрсә турында сүз барыр? (Табигать, су, чишмә.)

Слайдны ачам.

Чишмә рәсемнәре. Чишмәләр – яшәү чыганагы дигән сүзләр.

Матурмы, чистамы?

Ә безнең су буйлары, чишмә яннары нинди?

Без ничек ярдәм итә алабыз? Табигатьне чистартып яхшылык эшләдекме?

Безгә ничек булды? Күңелгә ничек?

*Фикер алышу.*

Нинди мәкальгә якынлаштык?

Киңәшемне ташлама.

**5. Рефлексия (Үзбәя).**

1. Дәрестә нинди яңа белемнәр алдыгыз?
2. Кешедәге иң гүзәл сыйфатлар итеп нинди сыйфатларны билгеләр идегез?
3. Кеше кайчан матур?

*Нәтиҗә:* Чын матурлыкны күңелгә рәхәтлек бирә торган күренешләрдән, эш-гамәлләрдән, тормыштан, кеше характерындагы хуплана торган матур сыйфатлардан, эчке дөньябызның сафлыгыннан, чисталыгыннан эзләргә кирәк. Матурлыкны күрү өчен күңел күзенә та-

яныйк. Чын матурлык тышкы һәм эчке хәләтнең берлегендә. Балалар, эшне кайдан башлаган булсак, шунда әйләнеп кайттык. Нинди сүзләр язылган?

*Укучы: Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт.*

**6. Өйгә эш**:

Кире кайта-кайта уйланыгыз, хаталар күрсәгез төзәтегез, төзәлегез.

***Сәләхетдинова Гөлзия,***
*Мамадыш шәһәре мәчете*
*каршындагы курслар мөгаллимәсе*

## КИЕМ ӘДӘБЕ

(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1. Киемнәрнең, кешеләрнең төрлелеге хакында аңлату.
2. Киемгә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.
3. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү.

*Җиһаз, әдәбият:*

– Вил Казыйханов «Әхлак дәресләре», Яр Чаллы, 1998.

– «Домоводство» китабы, «Өегез ямьле булсын», «Мәкальләр», плакат «Исендә тот» (укучыга киңәшләр).

– Плакат (А. Чехов сүзләре язылган) «Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә».

– С.П. Кожин «Укучы балаларның көндәлек режимы», «Милли киемнәр» дигән стенд, 60–80 нче елларда укыган балаларның мәктәп формалары (киемнәр).

– «Татар әдәбияты дәресләрендә сәламәтлеккә өйрәтү». Казан, 2005.

*Тәрбия сәгате барышы:*

Сыйныфта 20 укучы. Алар утырырлык итеп 3 төркемгә өстәл-урындыклар тезелгән. Укучылар сыйныф алдында бер рәткә тезелеп басалар.

**I. Оештыру.**

«Иртәнге комплемент» энергизаторы белән дәресне башлау.

Укытучы:

Ягез, балалар, кулларны кулларга тотындык, бер-беребезгә карап елмайдык, хәерле иртә теләдек. Мин сезгә каплап куелган кәгазьләр –

рәсемнәр тәкъдим итәм. Һәрберегез берне ала. (Ул рәсемнәрдә пальто, майка, свитер.) Ә хәзер I төркемгә – кулында майка рәсеме булганнар, II төркемгә – свитер, III төркемгә – пальто рәсеме булган укучылар урнаша.

**II. Рольләрне бүлешү.**

Группада беренче утырган кеше – җитәкче булыр. Ул барлык иптәшләренең дә катнашуын тәэмин итә. Икенче-өченчеләр – докладчылар эш тәмамлангач, чыгыш ясыйлар. Дүртенче-бишенчеләр – рәссамнар, алтынчылар – хронометристлар – вакытның әрәм ителмәвен тәэмин итүчеләр.

**III. Уку мәсьәләсе кую.**

Укытучы: Күз алдыгызга китерегез: сез моңа кадәр таныш булмаган, әмма танышырга тиешле булган кеше белән очраштыгыз, ди. Иң башлап бер-берегездә нәрсәгә игътибар итәсез?

Укучы: Тышкы кыяфәткә, киемгә, әлбәттә.

Укытучы: Икенче төрле әйткәндә?

Кешенең төсенә, битенә.

Укытучы: Тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк?

Укучы: Тышкы матурлыгына.

Укытучы: Бу уңайдан нинди мәкальне искә төшереп була?

Укучы: «Киемгә карап каршы алалар, акылга карап озаталар».

Укытучы: Димәк, бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләшү булучак?

Укучы: Кешенең кииеме, тышкы матурлыгы турында.

Үз-үзеңә бәя кую.

**IV. Уку мәсьәләсен чишү.**

***1 бирем.***

Укытучы: Нәрсә ул – тышкы матурлык?

Укучы: Берәр нәрсә яки күренешнең чын асылына кагылмыйча, чын асылын чагылдырмыйча, тыштан, беренче карашка гына күренә торган, үзенә нык җәлеп итә торган тышкы кыяфәт, чибәрлек.

Укытучы: Кыяфәт сүзен ничек аңлыйсыз?

Укучы: Кешенең тышкы күренеше, килбәте, төсе.

Укытучы: Нәрсә ул – кием?

Укучы: Тукымадан, күннән, мехтан һ.б. әйберләрдән тегелгән, эшләнгән, тәнне каплау өчен хезмәт итә торган предметлар җыелмасы.

Укытучы: Ничек уйлыйсыз: ни өчен кеше кием кияргә мәҗбүр булган?

Укучы: Кеше үзенең тәнен табигать стихиясе – суыктан, эсседән, судан, җилдән, тузаннан саклау өчен кием киеп йөри башлаган булырга кирәк.

Укытучы: Тагын?

Укучы: Бәрелүдән, сугылудан һ.б.

Укытучы: Икенче төрле әйткәндә, кием кеше тормышында нинди урын тота?

Укучы: Ул аның сәламәтлеген, саулыгын сакларга хезмәт итә. Моннан тыш, пөхтә кием кешене матурлый. «Җәй көне җиңел киен, кыш көне җылы киен», – диләр халыкта.

Укытучы: Бөтенләй диярлек кием кими торган халыклар да бар бит әле. Моны ничек аңлатасыз?

Укучы: Алар (мәсәлән, Африкадагы кабиләләр) яшәгән җирдә һава шартлары кешене кием киеп йөрергә мәҗбүр итми. Аннары аларның культура дәрәҗәләре дә түбән икәнлеген искә алырга кирәк.

Үз-үзеңә бәя кую.

***2 бирем.***

Укытучы: Кешенең киеме, тышкы кыяфәте белән бәйләнешле нинди мәкальләр һәм әйтемнәр беләсез?

Укучы: Агач күрке – яфрак, кеше күрке – чүпрәк.

Агач – җирнең, кием – ирнең бизәге.

Кием матур итә, ат батыр итә.

Үз-үзеңә бәя кую.

***3 бирем.***

Укытучы: Укучылар! Кием турында һәрбер милләтнең элек-электән үк үзенә генә хас үзенчәлекле зәвыгы булган. Игез әле, стендка игътибар итик, менә алар татар халкының милли киемнәре: түбәтәй, калфак, шәл, күлмәк, камзул, читек, изү, башмак, алъяпкыч. Сез аларның кайберләрен үзегез дә милли биюләр биегәндә киясез.

***4 бирем.***

Укытучы: Укучылар! Ә хәзер бераз ял итеп алабыз. Барыбыз да бастык. Уен – энергизатор. «Минем әбием сәяхәтче».

Минем әбием сәяхәтче һәм ул барган җиреннән истәлекләр алып кайта. Япониядән ул җилпәзә (веер) алып кайтты (куллары белән хәрәкәт күрсәтәләр). Италиядән кайчы (бу хәрәкәт өстәлә), Голландиядән башмаклар (тыпырдау өстәлә), Франциядән кыршау (бил белән әйләндерү хәрәкәте өстәлә). Ул безнең һәммәбезгә дә күп итеп (кулларны өскә күтәреп аска төшерү хәрәкәтләре өстәлә) бүләкләр алып кайтты.

Урыннарга утыралар.

***5 бирем.***

Укытучы: Ә хәзер акыл штурмы ясап алабыз.

Киемнәрнең нинди төрләрен беләсез? (Балалар әйтә тора, укытучы, тактага яза бара.)

Укучы: Эш киеме (һөнәр белән бәйләнгән), йортта кия торган кием, ихатада (бакчада, гаражда) эшләү киеме, спорт костюмы, дәүләт хезмәтен башкару өчен тегелгән кием (милиция, армия, суд, прокуратура, медицина, урман хуҗалыгы хезмәткәрләре һ.б.)

Укытучы: Мондый киемнәрнең әһәмияте нидә? Кеше тормышында алар нинди урын тота? Конкрет мисалларда исбат итегез.

Җаваплар.

Үз-үзеңә бәя кую.

***6 бирем.***

Укытучы: Ә хәзер һәр төркемгә кәгазь, фломастарлар бирелә. Укучылар өчен форма рәсемен үзегез теләгәнчә итеп ясагыз.

Аннан соң укучыларга 60–80 нче елларда кигән мәктәп формалары күрсәтелә. Рәсемнәр тактага эленә.

Үз-үзеңә бәя кую.

***7 бирем.***

Укытучы: Бөек рус язучысы А.П. Чеховның афоризмга әйләнгән шундый сүзләре бар (тактага плакат эленә): «Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә». Мондый билгеләмәсе белән язучы, барыннан да элек, нинди кешене күз алдында тота?

Укучы: Акыллы, үз-үзенә таләпчән, югары культуралы, зәвык белән киенүчән, хезмәт яратучан кеше генә үзен хөрмәткә лаек дип исәпли.

Үз-үзеңә бәя кую.

***8 бирем.***

Укытучы: Матур, зәвыклы итеп киенә белүне сез ничек аңлыйсыз?

Укучы: Сезонга карап, яшь үзенчәлекләрен, гәүдә төзелешен исәпкә алып, заман таләпләреннән чыгып эшләнгән модага ярашлы итеп.

Укытучы: Әгәр үзең кием сайлый белмәсәң?

Укучы: Якыннарыңа, дусларыңа мөрәҗәгать итәсең.

Укытучы: Киемгә, кием киюгә карата борын-борыннан нинди таләпләр куелган?

Укучы: Үзеңә охшаган киемне генә кияргә кирәк, югыйсә адәм көлкесенә калуың ихтимал.

Укытучы: Ни өчен?

Укучы: Тәнгә ятышлы кием кигәндә генә үзеңне иркен, рәхәт итеп сизәсең.

Укытучы: Бу уңайдан нинди мәкальләр, әйтемнәр беләсез?

Укучы: Пөхтә киенгән – матур кеше, шапшак киенгән – шапшак кеше. Пакь кием кадер арттырыр. Яман кием яшь кызны әби итә, әбине пәри итә. һ.б.

Укытучы: Киемнән тыш кешенең тышкы күренешен тагын нәрсә бизи?

Укучы: Төсе-бите, прическасы.

Үз-үзеңә бәя кую.

**9 бирем.**

Укытучы: «Кием киемне саклар» дигән әйтем нәрсә турында сөйли?

Укучы: Әйбернең кадерен белергә куша, киемгә карата сакчыл караш булырга тиеш.

Укытучы: Кешенең чын матурлыгын ничек аерып була?

Укучы: Эшенә, кыланышларына, үз-үзен тотышына карап. Вакыт – кеше өчен иң зур сынау.

Укытучы: Бу хакта нинди мәкальләр беләсез?

Укучы: Кием кешене бизәсә дә, гүзәл итмәс.

Киемгә карап каршы алалар, акылга карап озаталар.

**V. Рефлексия.**

Укытучы: Үзеңдә киемгә сакчыл, тышкы кыяфәтеңә җитди караш булдыру буенча үз-үзеңне тәрбияләү планын төзегез.

План

Матур итеп, зәвык белән киенергә өйрәнергә.

Киемне һәрвакыт пөхтә тотарга, пакь йөртергә.

Бәләкәйдән үк киемгә карата сакчыл караш тәрбияләргә.

Киемне эш, уен, ял төрләренә карап киенә белү сыйфатлары тәрбияләргә.

Үз-үзеңә бәя кую.

***Муллахмәтова Рәйсә,***
*Мамадыш районы Кече Сөн авылы*
*мәчете каршындагы курслар мөгаллимәсе*

# ТӘРТИП БУСАГАДАН БАШЛАНА

(Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен)

*Максат:*

1) тәртипле булу сыйфатларын тәрбияләү;

2) укучыларны кешеләр белән аралашу кагыйдәләренә өйрәтү, өйдә, мәктәптә, класста, урамда, җәмәгать урыннарында үз-үзеңне әдәпле тоту кагыйдәләрен кабатлау;

3) тәртипсезлекнең күңелсез хәлләр тудыруга сәбәп булуын ачыклау, әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

*Җиһазлар**:*** плакат, шигырьләр, табышмаклар, уку әсбаплары, яулык курчак, таяк, эшләпә.

*Кулланылган әдәбият:* Вил Казыйханов. «Әхлак дәресләре», «Көч һәм рух тамырлары», Ә.Н. Хуҗиәхмәтов. «Тәрбия дәресләре» дәреслекләре. «Мең дә бер хәдис», «Коръән сүрәләре», К. Вәлиуллин. «Ислам тәрбиясе дәресләрен укыту методикасы», Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи. «Балаларга иман дәресләре».

*Дәрес барышы:*

**1. Теманы ачу.**

– **Әссәләмегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ** кадерле укучылар. **Әгүүзү билләһи минәш-шайтаанир – раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.** Бүген без сезнең белән тәртип турында сөйләшербез. Безнең темабыз да бүген «Тәртип бусагадан башлана» дигән татар халкы мәкале белән атала.

– Укучылардан алдына: «Нәрсә соң ул тәртип? Сез аны ничек аңлыйсыз?» – дигән сорауларны кую һәм аларның җавапларын тыңлау.

– Җаваплардан соң, тәртип турында уртача фикергә килү: «Тәртип – үтә дә мөһим мәсьәлә. Чөнки ул ниндидер сукырларча буйсынуны, куркып-калтырап торуны яки ясалма тәртипне түгел, ә бәлки үз хокукларыңны һәм бурычларыңны аңлап, төшенеп яшәүне белдерә».

**2. Төп өлеш.**

**1) Сорау-җавап рәвешендә әңгәмә.**

*Укытучы сүзе*: Сүз башында без бит тәртип бусагадан башлана дигән идек. Тәртип турында без аңлатып уздык, ә менә бусага нәрсәне аңлата икән?

*Җаваплар*: Бусага – ишекнең яки тәрәзәнең аскы, яткырып салган борысы. Ишек бусагасын атлап керү (күрсәтү).

*Укытучы:* Бусага сүзенең башка төрле мәгънәләре дә бар укучылар, сез алар белән алга таба уку дәверендә танышырсыз, ә бүгенгә без шушы төшенчәдә тукталып торыйк. Ни өчен тәртип бусагадан башлана диләр соң? Чынлап та без кая гына барсак та бусага аша атлап чыгабыз.

Әйдәгез әле, укучылар, бусаганы атлап чыкканчы булырга тиешле тәртипне карап чыгыйк.

Тәртип бит ул шулай ук әйберләр, җансыз нәрсәләр куелышында, җыйнаклык, уңайлылык халәте дә. «Өйдәге тәртипне күреп телсез калдым», – диләр кайчагында. Өйдә шундый тәртипне булдыру үзебездән тора. Гомеребезнең яртысыннан артыгын Кеше үз өендә уздыра. Өегездә һәркайсыгызның үз почмагы бар.

Сез анда уйныйсыз, дәресләрегезне хәзерлисез. Хәзер әйтегез әле, уйнап арыгач уенчыкларны, дәрес хәзерләгәннән соң китап – дәфтәрләреңнең һәрберсен сез нишләтәсез?

**2) «Тәртипсез рәвештә яткан әйберләрне тәртипләп кую» уены.** *(Укытучы балалар сыйныфка кергәнче, кайбер әберләрне: китапларны, сумканы, ручка белән дәфтәрләрне, дөрес язылмаган кәгазь битен бөгәрләп, теләсә ничек урнаштырып куйган була.)*

*Бер укучы эшли, башкалар карап тора. Кирәк урында төзәтәләр.*

Тәртиплелек кагыйдәләрен балаларның үзләреннән әйттерү:

– Уенчыкларны үз урынына куй.
– Бүлмәне яки үз почмагыңны чиста тот.
– Кием-салымың аунап ятмасын.
– Өйгә кайтып керү белән өс-башыңны алыштыр.
– Урамнан кергәч, кулны юарга онытма.

*Укытучы:* Шушыларга өстәп тагы өч киңәш бирәсем килә: башкаларга комачаулама, кулыңнан килгән кадәр ярдәм ит һәм итагатьле бул. Шушы киңәшләргә колак салсаң сине беркем дә орышмас, битәрләмәс, һәркем тагын да ярата гына төшәр.

*Коръән Кәримдә дә: «Әйт: «Изге гамәлләр кылыгыз! Әлбәттә, Аллаһ вә Аның рәсүле һәм мөэминнәр сезнең гамәлләрегезне күрерләр», – диелә «Әт-Тәүбә» сурәсендә. (9/105)*

Менә шуңа да, кеше үз өендә тәртип кагыйдәләрен дөрес итеп башкара ала икән, башка җирдә дә үз-үзен тотышына, тәртип кагыйдәләрен дөрес итеп башкаруга игътибары булачак. «Тәртип бусагадан башлана» – дигән тәкъбир дә шуңа бәйле.

**3) Башка урыннарда тәртип кагыйдәләрен тоту турында әңгәмә.**

Без өйгә, мәктәпкә, стадионга, кинотеатрга, күршегә, кибеткә һ.б. шундый җәмәгать урыннарына да бусага аша атлап керәбез һәм бусаганы атлап керүгә без үзебезнең тәртиплеме – юкмы икәнлегебезне күрсәтәбез. Чөнки бусага аша атлап керүгә без нишләргә, нинди кагыйдәләрне үтәргә тиеш? (Укучылар җавабы тыңлана.)

***Мәктәптә:***

*Шигъри формада табышмакка җавап бирү:*

Укып, язып, рәсем ясап
Анда белем алалар.
Нинди бина икән соң ул,
Йә, әйтегез, балалар. (Мәктәп)

*Укучылар мәктәптә билгеле бер кагыйдәләрне үтәргә тиеш.*

– яхшы итеп укырга,
– формадан йөрергә,
– чиста, матур киенергә,
– дәресләрне һәрвакыт хәзерләп килергә,
– укытучы аңлатканны игътибар белән тыңларга,
– бирелгән биремнәрне тырышып үтәргә, дәресләрдә тәртипле булырга,
– соңга калмаска,
– укытучы рөхсәтеннән башка иртә китмәскә,
– класс тормышында, хезмәттә актив катнашырга,
– укуда һәм хезмәттә иптәшләреңә булышырга тиеш.

**Кыскасы, һәр укучы мәктәпнең эчке тәртип кагыйдәләрен төгәл үтәргә тиеш.**

***Урам, урамда йөрү турында:***

Иртә белән урын җыям,
Таслап куям юрганым.
Ә аннан соң өйдән чыгам,
Исәнме, дип, урамым.

Өйдә артыграк шаяра, сикерә, тавышлана башласаң, «Урамда түгел бит син!» – диячәкләр. Ләкин әле бу урамда нишләсәң дә ярый дигән сүз түгел, чөнки урамга чыгып сызгырырга, кычкырырга тотынсаң, шунда

ук «Урманда түгел бит син!» – дигән кисәтү ишетерсең. Әйе, урамның да үз кагыйдәләре, тәртипләре бар аның. Һәм алар бик гади. Урамның уртасы – машиналарныкы. Безнең өлеш – тротуар. Барлык илләрдә дә тротуарның уң ягыннан бару гадәт ителгән. Бездә дә шулай. Халык агымына ияреп атлаганда кинәт туктарга киңәш ителми. Югыйсә, башкалар сине урап узарга тиеш була.

Сез зур төркем булып барасыз икән, барыгыз бер рәткә тезелеп, стена ясамагыз. Өчәү икәнсез, рәттән барырга ярый. Инде дүртәү-бишәү икәнсез, икешәр-өчәргә бүленеп, ике рәт булып атлагыз.

Узган-барганнарның артыннан борылып карап калу, кемгәдер яки нәрсәгәдер бармак белән төртеп күрсәтү – бик ямьсез гадәт.

Урамнан барганда танышларың очраса, исәнләшергә кирәк, әлбәттә. Әмма аларны күреп алу белән кеше ташкынын ярып, шатлык авазлары чыгарып каршыларына ташланырга кирәкми. Шуның өстенә тәртипле, тәрбияле бала, урам буйлап авыз тутырып ашап йөрми.

(Физкультминут )

***Транспортта үз-үзеңне тоту турында:***

Кая да булса барырга кирәк булганда, без төрле транспортка утырабыз. Трамвайга, троллейбуска яки автобуска килеп керүгә син пассажирга әвереләсең. Син утырган автобус яки трамвай, троллейбус яки поездны кыска гына итеп транспорт дип атыйлар.

***«Без автобуста яки трамвайда» уены***

*Такта алдына 3 бала – 1 малай, 2 кыз чакырыла. Малайга эшләпә кидерелә һәм таякка таяндырыла. Бер кызга әбиләрчә яулык бәйләтелә һәм сумка тоттырыла. Икенче кызга төрелгән курчак бирелә.*

*Парта артында утыручы укучылар – пассажирлар.*

*Укытучы автобус тукталышы һәм ишекләр ачылу турында игълан итә.*

*Автобуска бала күтәргән ана, әби һәм бабай керә. Алар урын юкмы дип, карана-карана рәт арасыннан баралар.*

*Балалар бу вакытта нишләргә тиеш? (Балалар җавабы.)*

Транспортка кергәнче башта эчтәгеләрнең төшеп беткәнен көтәләр, юкса ишек төбендә шундый тамаша башлана! Автобус ишегеннән атылып кереп, күзләрен ялт-йолт китереп буш урын эзләүче бала нинди кызганыч!

Тәрбияле кешеләр хәзер аңа һәм аның әнисенә болай да урын бирәчәкләр, чөнки кечкенәләргә һәм инвалидларга бөтен кеше урын бирә. Әгәр кемдер моны белми икән, бу турыда син түгел, әниең әйтергә тиеш.

Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең хәдисендә: «Олы кешегә хөрмәт һәм ярдәм күрсәтүчегә Аллаһы Тәгалә үзе олыгайгач, аңа да шулай ук ярдәм итәрлек, кешене билгеләп куяр» (Тирмизи «Бирр»). Шуны онытмаска кирәк, Аллаһы Аның ризалыгы өчен хезмәт кылган кешене үз рәхмәтеннән ташламый, бу дөньяда ук бүләкли.

Бул тыңлаучан, бул әдәпле,
Олыларга бир урын.
Изгелегең үзеңә кайтыр,
Уң булыр барыр юлың.

**«Бу кагыйдәләрне онытма!»** плакатын уку.

*Кешеләр транспортка арткы яки урта ишектән кереп, алгысыннан чыгалар.*

*Транспортны махсус тукталышта көтегез.*

*Транспорт эчендә тыныч утырыгыз, кычкырып сөйләшмәгез.*

*Өлкәннәргә һәм кечкенәләргә урын бирергә онытмагыз.*

*Транспорт хәрәкәт иткәндә, салонда бер урыннан икенче урынга күчмәскә тырышыгыз.*

*Транспортка – ул туктагач кына утырырга һәм аннан төшәргә кирәк.*

**Истә тотыгыз!** Юл аша махсус билгеләр куелмаган урыннардан чыкканда сак булырга, якынлашып килүче транспортның узып киткәнен көтәргә кирәк.

***Кунакта үз-үзеңне тоту турында:***

Ә хәзер кыскача гына итеп бергәләп кунакка бару кагыйдәләрен дә искә алып кабатлап үтик. Иң беренче кунакка чакыргач, үзеңнең бара аласыңмы – юкмы икәнеңне белдерергә кирәк. Аннан соң, чакырган җиргә соңга калмыйча барыгыз. Матур, чиста итеп киенергә, барып кергәч тиешенчә әдәпле итеп исәнләшергә тиешсең. Шуннан соң гына, хуҗа күрсәткән урынга утыр. Кунакта сөйләшми утыруга караганда, сүзчән кешене күбрәк яраталар. Ләкин артык күп сөйләшү дә сезне бизәмәс.

Кунакта бүлмәдән – бүлмәгә йөрү, әйберләрне тотып карау, китап киштәсеннән рөхсәтсез китап алып актар башлау да, зур гадәтсезлек санала. Кунактан вакытында китә дә белергә кирәк.

**3. Йомгаклау:**

Укучылар, без бүген сезнең белән бик күп тәртип кагыйдәләре белән таныштык. Тәртипне булдыру өчен, иң беренче үзең тәртипле булырга тиеш икәнлегенә төшендегез дип ышанып калам. Амин.

«Мөселманнар – изге гамәлләр кылуда бер-берсе белән ярышучылар», ди Аллаһы Тәгалә Коръәндә («Әл-Гыймран» сүрәсе, 114 нче аять).

Сезнең дөрес итеп аңлавыгызны, фикерләвегезне белү өчен, тылсымлы сүзләрне «Кем тизрәк таба?» дигән, тагын бер ярыш үткәреп алыйк.

*(Сәлам, әссәләмегаләйкем, саумысез, исәнмесез, рәхмәт, нихәл, хушыгыз, кичерегез.)*

**4. Өйгә эш:**

Әдәплелек турында мәкальләр язып килегез.

Әти-әниләрегезнең, якыннарыгызның сезгә кайсы яклары ошый? Шул сорауга җавап әзерләгез.

***Зарипов Айназ,***
*преподаватель медресе «Шамиль»*
*при мечети «Казан нуры»*

## НРАВСТВЕННОЕ ПОВЕДЕНИЕ ВО ВРЕМЯ ЕДЫ И ПИТЬЯ

(лекция для учеников старших классов и взрослых)

Проблема духовно-нравственного воспитания в условиях современного общества приобрела особое значение. Потеря моральных ориентиров, обесценивание таких понятий, как совесть, честь, долг, привели к негативным последствиям в обществе: социальное сиротство, потеря позитивной мотивации к учению. В Концепции духовно-нравственного развития и воспитания гражданина России определен современный национальный воспитательный идеал. Это *высоконравственный, творческий, компетентный гражданин России, принимающий судьбу Отечества как свою личную, осознающий ответственность за настоящее и будущее своей страны, укорененный в духовных и культурных традициях многонационального народа Российской Федерации*.

**Актуальность** урока определена тем, что одной из важнейших задач образования в настоящее время является освоение, как детьми, так и взрослыми, духовных ценностей, накопленных человечеством. Уровень нравственности человека отражается на его поведении, которое контролируется его внутренними побуждениями, собственными взглядами и убеждениями. Выработка таких взглядов, убеждений и привычек составляет сущность нравственного воспитания.

**Новизна** данного урока в том, что он направлен на поддержку становления и развития высоконравственного, творческого, компетентного гражданина России. Урок обеспечивает реализацию одного из направлений духовно-нравственного воспитания и развития: воспитание нравственных чувств и этического сознания во время еды и питья.

*Цель урока:* воспитание культуры поведения во время еды и питья.

*Задачи:*

- познакомить шакирдов с основными правилами поведения мусульманина во время еды и питья;
- расширить знания о хадисах Пророка Мухаммеда (с. г. в.);
- повысить духовную этику.

*Ход урока*

Хвала Аллаху – Господу миров, мир и благословение Аллаха нашему пророку Мухаммаду, членам его семьи и всем его сподвижникам!

Одной из основных отличительных черт истинного мусульманина является его поведение за едой, и поэтому, если он окажется за столом, ты всегда сможешь узнать его по тому, как он ест и пьет, поскольку в этом он следует высоким наставлениям пророка, да благословит его Аллах и приветствует, побуждавшим придерживаться этого каждого мусульманина.

Так, он не приступает к еде, пока не произнесет слова ***«С именем Аллаха»***, ест правой рукой и берет со стола то, что находится рядом с ним, следуя указанию посланника Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, который сказал:

*«Скажи:* ***“С именем Аллаха”****, ешь правой рукой и бери то, что находится рядом с тобой».* Этот хадис передали **Аль-Бухари и Муслим.**

Если же он забудет помянуть имя Аллаха Всевышнего в начале еды, то потом исправляет упущенное и говорит: ***«С именем Аллаха в начале и в конце»***, на необходимость чего указывается в хадисе, передаваемом со слов госпожи Аиши, да будет доволен ею Аллах, которая сообщила, что посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, сказал:

*«Пусть каждый из вас помянет имя Аллаха Всевышнего, приступая к еде, если же он забудет сделать это в начале, пусть скажет:* ***“С именем Аллаха в начале и в конце”****»* Этот хадис передали **Абу Дауд и ат-Тирмизи.**

Посланник Аллаха придавал очень большое значение поминанию Аллаха Всевышнего перед едой и побуждал к этому своих сподвижников, так как подобное поминание приносит много блага приступающим к еде и удаляет шайтана и его вред от еды и тех, кто занят ею.

Сообщается, что Хузайфа, да будет доволен им Аллах, сказал:

*«Когда мы сидели за столом вместе с посланником Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, то никогда ничего не брали первыми, пока не брал что-нибудь посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует. Один раз, когда мы разделяли с ним трапезу, появилась какая-то девочка,* (спешившая так,) *будто ее подгоняли, сразу подошла к еде и протянула к ней руку, но посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, схватил ее за руку. Потом появился какой-то бедуин, также будто бы подгоняемый кем-то, и посланник Аллаха схватил за руку и его, сказав: «Поистине, шайтан считает дозволенной для себя ту пищу, над которой не поминают имя Аллаха Всевышнего, и он привел сюда эту девочку, чтобы с ее помощью сделать пищу дозволенной для себя, но я схватил ее за руку, а потом он привел сюда этого бедуина, чтобы с его помощью сделать пищу дозволенной для себя, но я схватил за руку и его! Клянусь Тем, в руках которого душа моя, поистине, рука* (шайтана была) *в моей руке, когда я брал этих двоих за руки!», после чего он помянул имя Аллаха Всевышнего и приступил к еде».* Этот хадис передал **Муслим.**

Теперь давайте запишем с вами первое правило, касающееся нравственного поведения во время еды и питья, это – **поминание Всевышнего Аллаха в начале еды и питья.**

Давайте теперь рассмотрим второй вопрос. Им является вопрос о необходимости есть правой рукой. Мусульманин, воспитанный в традициях ислама, ест правой рукой и никогда не использует для этого левую руку, так как известен целый ряд велений, в силу которых есть необходимо правой рукой, и запретов на использование для еды руки левой, о чем ясно говорится во многих хадисах.

Так, например, посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, сказал:

*«Когда кто-нибудь из вас станет есть, пусть пользуется правой рукой, и когда он станет пить, пусть пользуется правой рукой, ибо, поистине, шайтан использует для еды и питья левую руку».* Этот хадис передал **Муслим.**

Передают также, что пророк, да благословит его Аллах и приветствует, сказал:

*«Пусть никто из вас ни в коем случае не ест и не пьет левой рукой, ибо, поистине, шайтан ест левой рукой и пьет левой рукой!»*

Нафи‘ добавлял к этому следующее:

*«…и пусть никто ничего не берет и не дает ею!».* Этот хадис передал **Муслим.**

Когда благородный посланник, да благословит его Аллах и приветствует, видел, что кто-нибудь ест левой рукой, он запрещал такому человеку делать это, увещевал и наставлял его, и бывало так, что он проявлял к нему суровость и просил Аллаха наказать его, если тот делал это из гордости и упорствовал в своем заблуждении.

Салама бин аль-Аква‘, да будет доволен им Аллах, сообщил, что как-то раз один человек стал есть левой рукой в присутствии посланника Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, и он сказал ему: *«Ешь правой!»* Тот сказал: *«Я не могу!»*, – и тогда пророк, да благословит его Аллах и приветствует, сказал: *«Да не сможешь ты! Ничто не мешает ему, кроме гордости!»,* – и больше он уже не смог поднести ко рту левую руку. Этот хадис передал **Муслим.**

Известно, что благородный посланник, да благословит его Аллах и приветствует, вообще отдавал предпочтение правой стороне во всем и побуждал других все начинать справа. Об этом говорится в хадисе, который аль-Бухари, Муслим и имам Малик передают со слов Анаса, да будет доволен им Аллах. Он сообщил, что однажды посланнику Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, принесли молока, разбавленного водой из колодца. В это время справа от него находился один бедуин, а слева – Абу Бакр ас-Сиддик, да будет доволен им Аллах, и он отпил, а потом передал (сосуд с молоком) этому бедуину и сказал: *«Пусть каждый передает правому».* В другой раз, когда ему принесли питье, справа от него находился юноша, а слева – старцы, и пророк, да благословит его Аллах и приветствует, отпил, а потом сказал этому юноше: *«Сейчас твоя очередь пить, но не уступишь ли ты ее этим старцам?»* Юноша сказал: *«Клянусь Аллахом, нет! Того, что осталось после тебя, я не уступлю никому!»*

Другой хадис на эту же тему передается со слов Сухайля бин Са‘да, да будет доволен им Аллах, который сказал:

«*Однажды посланнику Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, принесли питье, и он отпил* (из сосуда). *В это время справа от*

*него сидел один юноша, а слева – старцы, и он сказал юноше: «Позволишь ли ты мне передать это им?» В ответ юноша сказал: «Клянусь Аллахом, нет! Я никому не уступлю того, что мне досталось от тебя!», – и посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, передал сосуд ему*». Этот хадис передали **Аль-Бухари и Муслим.**

Эти, а также и многие подобные им свидетельства и указания, недвусмысленно указывают на то, что предпочтение правой стороны является важной этической нормой ислама, которой истинный мусульманин придерживается неуклонно и без всяких послаблений. Так поступали сподвижники и последователи, и никто из них не отступал от этого. Известно, например, что большое значение соблюдению этой нормы этики придавал повелитель правоверных Умар бин аль-Хаттаб, да будет доволен им Аллах, не проходивший мимо тех, кто допускал в этом послабления.

Итак, давайте с вами запишем второе правило поведения во время еды и питья – **это есть и пить правой рукой**. А теперь **вопрос.** Давайте подумаем, в чем заключается польза от того, что мы едим и пьем правой рукой? Преподаватель делит учеников (шакирдов) на несколько групп и предлагает каждой группе обсудить данный вопрос. Ученики обсуждают и делятся своими ответами с преподавателем.

Третий вопрос касается необходимости брать то, что находится рядом, тем самым соблюдая этические нормы ислама. Веление пророка, да благословит его Аллах и приветствует, брать со стола то, что находится рядом, встречается во многих хадисах наряду с велениями произносить слова «С именем Алаха» и есть правой рукой. Так, например, сообщается, что Умар бин Абу Салама, да будет доволен им Аллах, сказал: «В детстве я находился под присмотром посланника Аллаха, и однажды, когда я стал протягивать руки к разным концам блюда, посланник Аллаха сказал мне:

«О мальчик, скажи “С именем Аллаха”, ешь правой рукой и бери то, что находится рядом с тобой!» Этот хадис передали **Аль-Бухари и Муслим**.

Когда мусульманин берет свою пищу руками, он делает это деликатно и осторожно, как поступал и посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, который брал куски (пищи) тремя пальцами и не погружал в пищу всю руку, на что неприятно смотреть и что производит неприятное впечатление на души людей. Об этом сообщает Ка‘б бин Малик, да будет доволен им Аллах, который сказал:

«Я видел, как посланник Аллаха ел тремя пальцами, которые он облизал, закончив есть». Этот хадис передал **Муслим**.

Пророк, да благословит его Аллах и приветствует, приказывал облизывать пальцы и вытирать блюдо после еды, о чем сообщает Джабир, да будет доволен им Аллах, который сказал, что однажды посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, велел им облизать пальцы и вытереть блюдо (после еды), сказав:

«Поистине, не знаете вы, в каком (куске) вашей пищи скрыта благодать». Этот хадис передал **Муслим**.

Сообщается, что Анас, да будет доволен им Аллах, сказал:

«Закончив есть, посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, облизывал три своих пальца и говорил: "Если у кого-нибудь из вас упадет кусок (еды), пусть он возьмет его, очистит от всего лишнего и съест, не оставляя его шайтану"». И он велел нам вытирать блюдо 143 и сказал: «Поистине, не знаете вы, в каком (куске) вашей пищи скрыта благодать»»». Этот хадис передал **Муслим.**

Закончив есть, мусульманин произносит прекрасные слова хвалы Аллаху Всемогущему и Великому, которым научил нас благородный посланник, да благословит его Аллах и приветствует, благодаря Аллаха за Его милость и надеясь снискать Его награду, уготованную для воздающих хвалу и благодарящих.

Передают со слов Абу Умамы, да будет доволен им Аллах, что, закончив есть, пророк, да благословит его Аллах и приветствует, говорил:

«Хвала Аллаху, хвала многая, благая и благословенная, хвала, которую следует произносить чаще, хвала непрерывная, хвала, в которой мы нуждаемся постоянно! Господь наш!» Этот хадис передал **Аль-Бухари**.

Передают со слов Му'аза бин Анаса, да будет доволен им Аллах, что посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, сказал:

«Тому, кто после еды скажет: "Хвала Аллаху, который накормил меня этим и наделил меня этим, тогда как сам я ни силой, ни мощью не обладаю!", будут прощены его предыдущие прегрешения». Этот хадис передали **Абу Дауд и ат-Тирмизи.**

Мусульманин, соблюдающий этические нормы ислама, не порицает еду, какой бы она ни была, следуя в этом наставлениям пророка, да благословит его Аллах и приветствует, и его личному примеру.

Сообщается, что Абу Хурайра, да будет доволен им Аллах, сказал:

«Посланник Аллаха никогда не порицал никакую еду: если он желал ее, то ел, а если она ему не нравилась, то он оставлял ее». Этот хадис передали **Аль-Бухари и Муслим.**

Таким образом третьим правилом, касающимся поведения за столом будет – **брать то, что находится рядом.**

Что же касается питья, то и здесь мусульманин следует этическим нормам ислама, который прекрасно научил человека всему тому, с чем он сталкивается в жизни. Он выпивает свое питье в два или три приема после произнесения слов ***«С именем Аллаха»***, не дышит в сосуд, не пьет из горлышка сосуда, если у него есть такая возможность, не дует на свое питье и по возможности пьет сидя.

Что касается питья в два или три приема, то так поступал благородный посланник, да благословит его Аллах и приветствует, как сообщил об этом Анас, да будет доволен им Аллах, который сказал:

*«Во время питья посланник Аллаха обычно делал три вдоха и выдоха».* Этот хадис передали **Аль-Бухари и Муслим.**

И благородный посланник, да благословит его Аллах и приветствует, запретил выпивать все разом, так как известно, что он сказал:

*«Не пейте все разом, подобно верблюду, но пейте в два или три приема, и произносите слова* ***«С именем Аллаха»*** *перед каждым глотком и воздавайте Ему хвалу после каждого глотка».* Этот хадис передал **Ат-Тирмизи.**

Кроме того, он запретил дуть на питье, о чем говорится в хадисе, переданном со слов Абу Са‘ида аль-Худри, да будет доволен им Аллах, котрый сообщил, что:

Пророк запретил дуть на питье, после чего один человек сказал: «(Бывает, ) *что я вижу в нем соринки».* Пророк сказал: *«Выплесни их».* Человек сказал: *«Поистине, я не напиваюсь, сделав только один вздох».* Тогда посланник Аллаха, да благословит его Аллах и приветствует, сказал: *«Тогда отведи кубок ото рта и вздохни».* Этот хадис передал **Ат-Тирмизи.**

Из обзора хадисов, в которых говорится, как следует пить, становится ясно, что по возможности лучше всего не пить из горлышка сосуда и делать это сидя. Как следует из содержания соответствующих хадисов, именно такой способ утоления жажды является наилучшим и самым совершенным, если же человек из горлышка напьется стоящий, то это допустимо, потому что так приходилось поступать и благородному посланнику, да благословит его Аллах и приветствует.

Теперь давайте вспомним основные правила, которые мы сегодня прошли и закрепим пройденный материал. Ученики (шакирды) перечисляют основные правила поведения во время еды и питья. Преподава-

тель: «Отлично. Все молодцы, МашаАллах! А теперь сделаем дуа». Преподаватель делает дуа, вознося всю хвалу Всевышнему Аллаху и делая салават пророку Мухаммаду (с. г. в.)

***Марданова Гөлсинә,***
*Балтач районы Куныр авылы мәктәбе*
*өстәмә белем бирү педагогы*

## ТОЛЕРАНТЛЫК НӘРСӘ УЛ?

*Максат:*

1. Укучыларда толерантлы шәхес турында күзаллау тәрбияләү һәм толерантлык сыйфатларын үзеңдә булдырырга теләк уяту. «Толерантлык» төшенчәсе һәм аңа хас булган төп сыйфатлар белән таныштыру.
2. Укучыларның үзләрен тотуларындагы кимчелекләрне бетерү, үзеңне тота белү матурлыгы булдыру.
3. Балаларда бер-берсенә игътибарлылык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү.
4. Ислам диненең толерантлыкка карашы белән танышу.

*Бурычлар:* кешеләр белән мөнәсәбәттә янәшәдәге кешеләргә тигез хокуклы, якын, тугандаш шәхес итеп карарга, ярдәмгә килергә әзер булырга, кеше хәленә керә белергә кирәклегенә төшендерү, үзеңне һәм үз хәлләреңне анализларга өйрәтү, бер-береңә карата хөрмәт һәм бердәмлек хисе тәрбияләү.

*Җиһазлау.* Ноутбук, проектор

*Ресурслар.* «Ачык дәрес», № 4, 2014 ел, Коръән тәфсире, хәдисләр җыентыгы.

**I . Оештыру өлеше. Мотивация.**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим.

Уңай психологик халәт тудыру.

Очрашканда кешеләр олылар һәм кечеләр бер-берсен сәламлиләр, «Исәннәрмесез!» – ди татарлар, «Әссәләмегаләйкем», ди мөселманнар, «Здравствуйте», диләр руслар. Хәерле иртә, укучылар һәм килгән кунаклар!

Иртәнге якта очрашканда, «Хәерле иртә!» дибез, көндез, кичен нинди матур сүзләр әйтерсез? (Укучылар җавабы.)

Барыбыз да, иптәшләребезгә карап, матур итеп елмаеп, бер-беребезгә яхшы кәеф теләп, дәресебезне башлыйбыз.

**КОНЭРС (почмаклар)**

Сез түбәндәге сыйфатларның кайсысын сайлар идегез?

1. Сабыр булу.
2. Ярдәмләшү.
3. Хөрмәт итү.
4. Мәрхәмәтлелек.

Үзегез сайлаган почмакка басыгыз? Ни өчен бу сыйфатны сайлаганыгызны иптәшегезгә сөйләгез. (Тиешле өстәл артына утыралар).

**II. Яңа материалны өйрәнүгә әзерлек.**

Инглиз язучысы Бернарда Шоу «Хәзер, без кош кебек һавада оча белгәндә, балык кебек суда йөзә белгәндә, безгә бары кеше кебек яшәргә өйрәнәсе генә кала», – дип яза. Кеше булып яшәү өчен матур сүзләр генә куллану җитәрме икән? (Фикер алышу.)

Кеше булып яшәү өчен аңлашып, бер-береңә булышып, кеше фикерен дөрес итеп кешегә җиткерә белү, кешеләрне милләтенә, яшенә, кигән киеменә, гаилә хәленә карамыйча кабул итә белергә дә өйрәнергә кирәк.

Сүзебезне мәңгелек мәхәббәт турында дәвам итик.

Көй яңгырый, әкият сөйләнә. (Укучы укый.)

Яшәгән ди, җирдә Мәхәббәт исемле кыз. Дусларсыз яшәү аңа бик күңелсез, моңсу була. Менә ул аксакаллы, йөз ел яшәгән карт кына тылсымчыга мөрәҗәгать иткән:

**Кыз:** Кадерле тылсымчы, миңа Ходай тарафыннан бирелгән тормышымда якын дус табарга ярдәм итсәгез икән, дигән.

**Тылсымчы** уйлап торган һәм әйткән:

– Иртәгә иртән кошлар сайраганда, чык тамчылары да кибәргә өлгермәгән вакытта минем янга килерсең.

Иртән сүз куешканча, кояш чыкканда Мәхәббәт билгеләнгән җиргә килә. Берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе гүзәл биш кызны күрә.

– Менә үзеңә ошаганын сайла, беренчесенең исеме <u>Шатлык,</u> икенчесенең исеме – <u>Уңыш,</u> өченчесенең исеме – <u>Матурлык</u>, дүртенчесенең исеме – <u>Сагыш</u>, бишенчесенең исеме – <u>Игелеклелек,</u> дип әйтә тылсымчы.

– Алар барсы да искитмәле, кайсын сайларга да белмим, – дип җавап бирә кыз.

Син дөрес әйтәсең, алар чыннан да барсы да гүзәл, син тормышта алар белән очрашырсың әле, әмма берсен үзеңә ныграк ошаганын сайларга тиешсең. Ул сиңа тормышыңда гомерлек дус булыр.

Мәхәббәт кызларга якынырак килде һәм һәрберсенең күзләренә карады.Ул уйга калды.

**– Сез кемне сайлар идегез? Ни өчен?**

Мәхәббәт Игелеклелек дип аталган кыз янына килде һәм үзенең кулын сузды.

**– Ни өчен Мәхәббәт Игелеклелекне сайлады?**

(Укучылар фикерләшәләр һәм җавап бирәләр.)

**Нәтиҗә:** Игелеклелек, изгелеклелек эшләп, кеше тагын да яхшыра. чистарына, сафлана. Әгәр дә без һәр кешегә игътибарлырак булсак, бу изгелеклелек күрсәтү булыр иде.

Хәзер сезнең игътибарга сыйфатлар тәкъдим итәм. Хор белән укырбыз, шул ук вакытта уйларбыз да кешене кайсы яктан сурәтли торган сыйфатлар икән алар? (Слайд 2) (Укучылар укый.)

1. Мәрхәмәтлелек.
2 Түземлелек.
3. Юмор хисе.
4. Сизгерлек.
5. Ышаныч.
6. Үзең белән идарә итә белү.
7. Яхшылык.
8. Башкаларны гаепләмәү.
9.Кешелеклелек.
10. Тыңлый белү.
11. Кызыксынучанлык.
12. Уртаклаша белү.

**III. Яңа материал белән эш.**

Бу сыйфатларны берләштергән тагын бер сыйфат бар. Нинди икән ул?

Дуслык, тынычлык, бердәмлекне бер сүз белән генә әйтеп буламы?

(Толерантлык, тактада сузык авазлары төшереп калдырып языла.) Димәк, бу сыйфат – толерантлык.

«Толерантлык» сүзенең мәгънәсен аңлату.

Төрле илләрдәге халыклар бу сүзнең мәгънәсен төрлечә аңлаталар. (Слайд 4) (Укучылар укый.)

Инглиз халкы – мәрхәмәтлелек, түземле була белү.

Испан халкы – башкаларныкыннан аермалы карар, фикерләрне кабул итә белү.

Гарәп халкы – мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек,башкаларны ничек бар, шулай кабул итә белү.

Француз халкы – башкаларның фикере синекеннән аермалы булырга мөмкинлекне аңлау.

Рус халкы – түзә белү.

Татар халкының толерант булуын без республикабызда күпмилләтле халыкның дус, тату яшәвендә күрәбез.

Гадиләштереп кенә әйткәндә, нәрсә инде ул ул толерант булу?

**Нәтиҗә:** Төрле булуларына карамастан кешене кабул итү, берберең ә игътибарлы булу. Толерантлылык – тынычлык нигезе. (Слайд 5) (Укучы укый.)

Бу тема ни өчен бүгенге көндә проблема булып тора икән?

Хәзерге заманда кешегә белемле булу гына җитми. Зур тизлек белән дөнья алга бара, техникасыз яшәүне күз алдына да китереп булмый. Тормыш җитеш кебек, тамак тук, өс бөтен. Ләкин куркыныч, ямьсез хәлләр турында телевизорлардан карап, газеталардан укып, ишетеп торабыз. Тәртип бозулар, җинаятьләр зурлар арасында гына түгел, балалар арасында да күзәтелә. Соңгы вакытларда җир шарында еш күзетелә торган күңелсез хәлләрне, сугыш-гаугаларны, төрле кимсетүләрне булдырмау өчен 16 ноябрьдә төрле илләрнең халыклары Дөньякүләм толерантлык көне (Международный день толерантности или День терпимости) билгеләп үтәләр, төрле чаралар үткәрәләр. Толерантлылыкның символы булып салават күпере төсендәге флаг санала. (Слайд № 6.)

Өстәлләрдәге конвертларны алып, сорауларны укыйк әле. (Һәр өстәл үз конвертын ачып укый, фикерләшәләр һәм җавап бирәләр.)

Безнең районның исеме ничек? (Слайд)

Балтач районында яшәүче милләт кешеләрен санагыз. (Слайд)

(Татарлар, руслар, марилар, керәшеннәр, удмуртлар).

Безнең авыл җирлегенә кергән авылларда нинди милләт кешеләре яши? (Татарлар, марилар, керәшеннәр, удмуртлар.)

Рәсемнәрдә кайсы милләт кешеләре сурәтләнгән, әйтеп карыйк әле. (Фикерләшәләр һәм бер укучы җавап бирә.)

Әйе, без күп милләтле районда дус, тату булып яшибез. Бәйрәмнәрне дә бергә-бергә үткәрәбез. Әйдәгез, берничәсен искә төшереп китик әле.

**Физкультминутка**

Сезнең бу бәйрәмнәрне ишеткәнегез бармы? Әгәр ишеткәнегез булса, хәрәкәтләр белән җавап бирегез. Сабантуй – кулларны артка куялар, Гырон-быддон – кул чабалар, Питрау – аяк дөбердәтәләр, Яфрак бәйрәме (День березки) – бер урында әйләнәләр, Ураза гаете – кулларны өскә күтәрәләр, Корбан гаете – кулларны селкиләр.

**IV. «Яңа белемнәр ачу».**

Ислам диненең мөселман булмаганнарның гадәтләренә һәм традицияләренә мөнәсәбәте нинди икән? Шушы сорауга җавап эзләп карыйк әле. Без җавапны изге китабыбыз Коръәннән һәм пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)нең хәдисләреннән табарбыз.

Кешеләргә теләсә нинди – мораль, физик, психологик зыян салудан качарга кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Үзеңә һәм башкаларга зыян салма», – дигән. Башкаларның мәнфәгатьләрен исәпкә алмыйча сөйләү яки нидер эшләү үзеңне исламча тотуга саналмый. Исламда үз-үзеңне яхшы тоту күп яктан башкаларга карата игътибарлылыктан тора. Менә берничә генә мисал: (*слайдтан укучылар укый.*)

1. Башка халыкларның динен мыскыл итү яки аннан көлү тыела.
2. Кем дә булса берәүгә карата әдәпсез сүзләр һәм җөмләләр кулланып шаярту тыела.
3. Ашаган вакытта башкаларны рәнҗетүе яки кимсетүе ихтимал булган сүзләр кулланырга ярамый.
4. Юлда вакытта кешенең үз-үзен тотышы белән идарә итүче төп принцип башка кешеләргә зыян салмау, каршылык яки борчылу тудырмау булырга тиеш. һ.б.

Шулай ук ислам дине, ислам илендә яшәүче теләсә нинди общинаның динен һәм мәдәниятен яклый. Исламны кабул итү ирекле һәм үз теләге белән генә булырга мөмкин. Шулай ук ислам теләсә кайсы мөселман булмаган кешенең тормышын, милеген, намусын саклый. Мөселман булмаган кешеләрнең түбәндәге хокуклары бар: (*слайдтан укучылар укый*)

1. Тулысынча дин тоту һәм гыйбадәт кылу.
2. Шәхси һәм гаилә кануннарына кагылышлы тулы автономия, моңа гәрчә алар Исламга каршы килсәләр дә, никахлашу һәм аерылышу кагыйдәләре.
3. Финанс, эшкуарлык һәм гражданлык эшләрендә тигез хокуклылык.

4. Иҗтимагый традицияләрдә (әгәр алар Ислам кануннарына каршы килмәсәләр) мөселман булмаган кешеләр үзләренең аерым сыйфатларын, мәсәлән, кием формаларын, ризык төрләрен саклый алалар.

**Нәтиҗә:** Ислам диненең мөселман булмаганнарның гадәтләренә һәм традицияләренә булган мөнәсәбәте сабыр булып, бер-береңне ихтирам итеп, башкаларга зыян салмыйча, тынычлыкта, мәрхәмәтлелек сыйфатлары белән яшәүдә һәм тәкәбберлек, мактану, көнчелек кебек начар сыйфатлардан тыелуда чагыла.

Бүгенге көндә без, шушы җирлектә күршеләребез христианнар, яһүдиләр, атеистлар, мөселманнар белән бергә яшибез.Тынычлыкта яшәү өчен берсен дә бүлмичә, аны хөрмәт итеп һәрбер бәндәгә йомшак сүзле булып, аңа карата күркәм холыклы булырга кирәк.

(*Слайдтан укучылар укый*)

**Бер аятьтә Аллаһы Тәгалә әйтә**: «Әйт минем колларыма, иң татлы сүзләр генә сөйләсеннәр, чөнки шайтан алар арасында гауга чыгаручыдыр, шайтан кешенең иң хәтәр дошманыдыр». Галимнәр әйтүенчә, бу аятьнең беренче иңү сәбәбе булып, Гомәр (р.г) белән бер гарәп арасында булган хәл була. Көннәрнең берендә бер гарәп Гомәр (р.г) янына килеп, аны нинди генә сүз белән сүкми, аңа нәрсә генә әйтми, шушы сүзгә каршы Аллаһы Тәгалә Гомәргә сабыр итәргә, бу кешене гафу итәргә кушкан аятьне иңдерә.

**Аллаһы тәгалә «Бүлмәләр» сүрәсе 13 аятьтә әйтә:** «Әй, кешеләр! Без (дип әйтә Аллаһы Тәгалә Үзенең күплегенә түгел, ә кодрәтенә һәм бөеклегенә күрсәтеп) сезне кабиләләр һәм халыклар итеп барлыкка китердек ( сезнең күп милләтле һәм мәдәниятле булуыгызда бер дә гаҗәп нәрсә юк. Бу – Аллаһның теләге. Сезнең «төрле һәм охшамаган булуыгыз») бер-берегезне танып белүегез өчен ( чит телләр, таныш булмаган мәдәниятләрне өйрәнүегез, моңарчы таныш булмаган кешеләр белән танышуыгыз өчен кирәк). Чынлыкта, сезнең арагызда иң күркәмегез – (милләте сәбәпле Аллаһ каршында дәрәҗәсе бөегрәк дип уйлап, үз милләте белән горурланып йөрүче түгел, ә галәмнәр Раббысы каршында) тәкълырак булганыгыз. Чынлыкта, Ул – бар нәрсәне Белүче һәм бар нәрсә турында тулысынча хәбәрдар», – ди.

**Нәтиҗә:** Аллаһы Тәгалә безне кабиләләр һәм халыклар итеп барлыкка китергән икән, димәк, безнең күп милләтле һәм мәдәниятле булуыбыз, бер-беребезгә охшамаган булуыбыз да (телебез, тән төсебез) Аллаһы Тәгаләнең теләге икән. Без сайлап ала торган әйбер түгел, ризалашырга кирәк икән. Әгәр без шуңа риза булмасак, бер-беребезне

кимсетсәк, үзебезне өстен күрсәтергә теләсәк, тәкәбберләнсәк, тынычлык югалачак, ахыры аяныч хәлләргә китерергә мөмкин. Хәтта сугышлар башлануга да сәбәп булырга мөмкин.

Кунак сөюче Ибраһим пәйгамбәр турында да сөйләшеп үтик. Дөньяда иң беренче мәртәбә кунакларны кунак итү Ибраһим галәйһиссәламнән башланган. Бу хакта пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән.

(*Укучы укый*:)

– Ибраһим пәйгамбәр бик кунаклар килгәнен яраткан, кунак килмәгән көнне ашын да ашамас булган. Өйләдә пешкән ашны да «кунак килмәсме?» дип саклаган. Әгәр ике-өч көн кунак килми торса:

– И, Раббым, Миңа ни булды, ни килде – миңа кунак бирмәдең, дия торган була.

Беркөнне аңа бер кунак килә. Ибраһим галәйһиссәлам сорады:

– Син нинди дин тотасың? – диде.

Ул әйтте:

– Мин мәҗүси яһүдмен, – диде.

Ибраһим галәйһиссәлам:

– Алай булса, сине кунак итү юк, синең динең башка икән, – диде.

Ул кунак өйдән чыгып барганда, Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңде, ягъни хәбәр килде.

– Йә. Ибраһим! Син ни өчен ул бәндәне кунак итмәдең? Мин бит аны, бу кяфер, дип, ризыгын киметмәдем, бу көн сиңа җибәреп, ризыгын синең кулыңда кылдым исә, син аңа һични бирмәдең! – дип ачуланды.

Ибраһим галәйһиссәлам торып, кунак артыннан йөгерде. Куып җитеп, кунакка:

– Зинһар, борыл! – диде, әмма кунак борылмады. – Ике дөя бирәм! – диде, кунак борылмады. – Өч дөя бирәм! – диде, кире килмәде. Ахырда: – Йөз дөя бирәм, зинһар, борыл! – диде.

Кунак әйтте:

– Бу ни хәл инде? Башта кунак итмәдең, инде хәзер йөз дөя бирмәкче буласың? – диде.

Ибраһим галәйһиссәлам:

– Аллаһы Тәгалә мине ачуланды, – диде.

Мәҗүси:

– Синең Тәңрең яхшы Алла икән, – диде. – Дошман мәҗүси өчен хәтта дустын да ачулана икән, – дип иман китерде. Шулай итеп, мөселман булды.

Нинди нәтиҗә чыгарабыз? Димәк, Аллаһы Тәгалә каршында бөтенебез дә бертигез, барыбыз да адәм балалары. Йортыбызга кем генә килсә дә, без аны кунак итәргә тиеш.

**Аллаһы Тәгалә «Әл-Хүҗурәт» сүрәсендә (11 нче аять) әйтә:**

– Бер кавемне – икенче кавемнән, бер кешене икенче кешедән өстен куймагыз. Сез түбәнсеткән, сез кимсеткән кешеләр, бәлки Аллаһы Тәгаләгә якынрактыр, ди.

Толерантлык пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) нең хәдисләрендә дә чагыла.

(*Укучылар укый*:)

– Пәйгамбәребез һәрвакыт ихлас күңелле булган һәм безгә дә шундый булырга әйтеп калдырган. Аны беренче мәртәбә күргән бер гарәп, аннан куркып, калтырый башлаган. Шулчак пәйгамбәребез: «Әй, иптәш, курыкма! Мин дә көрәеш тармагыннан арпа икмәге ашаган бер хатынның баласымын», – дигән.

– «Сүз йөртеп, кешеләр арасын бозудан сакланыгыз!», – дигән.

– «Бер кавемнең хөрмәтле кешесе сезне зиярат кылыр өчен килсә, сез аңа хөрмәт күрсәтегез!», – дигән.

**Нәтиҗә:** Башка кавемнән, башка милләттән булган кешене хөрмәт итү шул кавемне, шул милләтне хөрмәт итү билгесе ул. Кешеләрне хөрмәт итеп яшәсәк, тормышыбыз күңелле, араларыбыз да төзек, үзебез дә сәламәт булырбыз.

**V. Яңа белемнәрне һәм эш алымнарын куллану. Мөстәкыйль эш.**

Тест. Укучыларны толерантлыгын тикшерү.

Укучылар, бездә толерантлык бармы икән, шуны тикшереп карыйк.

Биремнәр өч варианттан тора. Беренче вариант белән килешсәгез – кызыл төс, икенче вариант белән килешсәгез – зәңгәр төс, өченче вариантны сайласагыз – яшел төс аласыз.

**Биремнәр:**

1. Сиңа син яратмаган кушамат белән эндәшәләр:
– син игътибар итмисең;
– аңа сугып җибәрәсең;
– башка фикер.
2. Син үзеңнең дустың белән ачуланыштың:
– татуланышырга җай эзлисең;
– үпкәлисең һәм үч аласың;
– башка фикер.

3. Сезнең сыйныфка яңа укучы килде һәм беренче көнне үк синең белән конфликтка керде:

– син аның белән аңлашырга телисең, аңа яңа коллективка кереп китәргә ярдәм итәсең;

– син аннан көләсең, калганнарны аның белән дуслашмаска өндисең;

– башка фикер.

4. Дустың тәмәке тарта, сиңа бу ошамый. Бу очракта нишләрсең?:

– үзе белән сөйләшәм;

– берни сизмәгәндәй, дуслыкны дәвам итәм;

– башка фикер.

Сиңа караганда дустыңны күбрәк яраталар, хөрмәт итәләр. Моңа ничек карыйсың?

– аңа охшарга тырышам;

– аның исемен тапларга тырышам;

– башка фикер.

Укучылар, кемнең кызыл түгәрәкләре күбрәк – шулар баса. Барыгызныкы да кызыл түгәрәк – яхшы! Димәк, сез толерант укучылар. Толерант укучылар нинди сыйфатларга ия булалар соң?

**Нәтиҗә:**

Тирә-юньдәгеләргә ихтирамлы һәм игътибарлы булу, бер-береңә ярдәм итү, игелекле эшләрне күрәк эшләргә тырышу.

**VI. Дәресне йомгаклау. Рефлексия.**

Димәк, укучылар, игелекле эшне һәркөнне, һәрвакыт эшләп була. Бүгенге дәресебезне ничек аңладык икән тикшереп карыйк әле. Әйдәгез, «Бүген мин аңладым, толерантлык ул – ...», – дигән җөмләне дәвам итик. (Һәр укучы җавап бирә.) (Җаваплар: сабырлык, юмартлык, мәрхәмәтлелек, түземлелек, юмор хисе, сизгерлек, ышаныч, үзең белән идарә итә белү, яхшылык, башкаларны гаепләмәү, кешелеклелек, тыңлый белү, кызыксынучанлык, тәкәббер булмау, хөрмәт итү, ярдәмчел булу...)

Кеше булу өчен кешегә нәрсә кирәк икәнен Фәнис Яруллинның «Сорау һәм җавап» шигыреннән табарбыз.

Кабатлыйм бер сорауны
Өнемдә һәм төшемдә:
«Кеше булып яшәргә
Нәрсә кирәк кешегә?»

Диңгез әйтә: – Тирәнлек.
Таулар әйтә: – Турылык.
Җир эндәшә: – Юмартлык.
Чык суы әйтә: – Сафлык.
Яшен әйтә: – Кыюлык.
Ипи әйтә: – Олылык.
– Гүзәллек, – диләр гөлләр.
– Иркенлек, – диләр җилләр.
– Нык канат, – ди бөркетләр.
– Биеклек, – диләр таулар,
Һәм шушылар өстенә
Кирәк тагын иң элек
Кешене кеше иткән
Бер нәрсә – Кешелеклелек.

Бик зур рәхмәт! Соңгы сүз итеп, шуны әйтәсе килә, безнең сыйныф ул – кечкенә бер гаилә. Гаиләбездә һәрвакыт гаделлек, дөреслек, бер-береңне аңлау хакимлек итсен. Дәресебез шуның белән тәмам.

## ЭЧТӘЛЕК

Кереш ........ 3

***Әхмәтҗанова Разия.*** Шөгыль конспектлары (Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен) ........ 5

***Сәхәбиева Люция.*** «Илләр гизик, гыйлем эзлик» сәяхәт дәрес (Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 24

***Хөсәенова Венера.*** Бал кортлары – эшчән халык (Кече яштәге мәктәп балалары өчен) ........ 29

***Вагизова Әлфия.*** Шәфкатьлелек бизи кешене (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 33

***Нургалиева Лилия.*** Ачу – агу, йотсаң – дару (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 40

***Мөхәммәтҗанова Әминә.*** Киемгә карап каршы алалар (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 46

***Мөхиярова Рәзинә.*** Вакытның кадерен белү әдәбе (Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен) ........ 54

***Муллахмәтова Рәйсә.*** Гаилә – кеше гомеренең бәхет күгендәге кояшы (Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен) ........ 62

***Муллахмәтова Рәйсә.*** Тәүбә (Югары сыйныф укучылары һәм зурлар өчен) ........ 69

***Фәхертдинова Сөмбелә.*** Дин – күркәм мөгамәлә (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 74

***Муллахмәтова Рәйсә.*** Акыл байлыгы тузмас байлык (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 78

***Сәхәбиева Люция.*** Ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 83

***Вагизова Әлфия.*** Агач – җимеше белән, кеше – хезмәте белән матур (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 86

***Вагизова Әлфия.*** Акыллы кеше ялгышамы? (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 92

***Хөсәенова Венера.*** Гаилә – бәхет ишеге (Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ........ 97

***Нургалиева Лилия.*** Гыйлем – нур, наданлык – караңгылык.......... 100
***Бариева Нурзидә.*** Изгелек кылып кал, яхшылык җирдә ятмас
(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ............................................. 105
***Фәхертдинова Сөмбелә.*** «Йосыф» сүрәсендә әхлак үрнәге
(Өлкән сыйныф укучылары һәм зурлар өчен)................................. 108
***Муллахмәтова Рәйсә.*** Ислам динендә ата-ана хакы
(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен) ............................................. 114
***Муллахмәтова Рәйсә.*** Кеше холкын күзәт, үзеңнекен төзәт
(Урта яшьтәге мәктәп балалары өчен ) ............................................ 118
***Сәләхетдинова Гөлзия.*** Кием әдәбе (Урта яшьтәге мәктәп
балалары өчен) ..................................................................................... 122
***Муллахмәтова Рәйсә.*** Тәртип бусагадан башлана
(Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен)............................................. 127
***Зарипов Айназ.*** Нравственное поведение во время еды
и питья (Лекция для учеников старших классов и взрослых)........ 132
***Мәрдәнова Гөлсинә.*** Толерантлык нәрсә ул?.................................. 139

*Уку әсбабы*

# ӘХЛАК – ИМАН КӨЗГЕСЕ

**Мәчетләр каршындагы курсларда
әхлак дәресләре эшкәртмәләре**

*Учебное издание*

# НРАВСТВЕННОСТЬ – ОТРАЖЕНИЕ ВЕРЫ

**Разработки уроков нравственности
на примечетских курсах**

Корректорлар:
***Ф.С. Гиниятуллина, А.Х. Яфизова***

Компьютерда битләргә салучы
***А.И. Галиуллина***

Тышлык бизәлеше
***М.А. Әхмәтов***

Басарга кул куелды 15.12.2015.
Офсет кәгазе. Цифрлы басма. Формат 60х84 1/16.
Гарнитура «Таймс». Шартлы басма табагы 8,84.
Шартлы нәшр. табагы 7,39.
Тираж 100. Заказ 8/12.

Казан университеты нәшрияты
типографиясендә басылды

420008 Казан, Проф. Нужин ур., 1/37
Тел. (843) 233-73-59, 233-73-28